ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 12 (359)
ДЕКАБРЬ 2021

СОВЕТ ЧЫРШЫСЫНДА КУНАКТА

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Чыгарылыш мөхәррире: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Ксения Семина
Фотографлар: Александр Ефремов, Илнар Өметбаев
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Лайсән Һадиева
Тышлыкта Лилилана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-4101
Басарга кул куелды: 17.12.2021
Басмадан чыкты: 23.12.2021

Коммерция директоры: Рәшит Хәйретдинов, тел.: (843)222-09-76, +7 9600 487 900

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

СССР – ШУНДЫЙ ИЛ БАР ИДЕ

30 ел элек, 1991 елның 26 декабрендә, Совет Социалистик Республикалар Союзы – СССР таркалды. Һәм үзен шул илдә бәхетле итеп тойган буын аны шунда ук сагына да башлады. Әлеге сагыну бүгенчәгә басылмый, дәвам итә. Бу кешеләр совет фильмнарын карый, совет җырларын тыңлый, совет көнкүреше музеена барып, йөрәккә якын экспонатларны карый…

Советлар Союзында яшәүне рәхәт дип санамаган кешеләр дә бар, әмма алар да вакыт-вакыт ул заманны сагынып куя. Чөнки анда аларның иң матур вакытлары – бала чаклары, яшьлекләре калган. Яшь, матур, сәламәт чаклары, кеше тормышында башка кабатланмый торган гүзәл мизгелләр калган.

Бүгенге психологлар мондый күренешкә исем дә уйлап тапкан – ретромания. Алар сагынучыларны, үткәннәргә ябышып, бүгенгенең сорылыгыннан качарга тырышуда гаепли. Ә «Татарстан» исә укучылары белән бергә үткәннәрне искә төшерергә бик шат, шуңа күрә сезгә совет тормышына багышланган декабрь санын тәкъдим итә.

Сезнең совет редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

«КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ТАТАРСТАННЫҢ» ЗУР БАЙЛЫГЫ

АКШ, Согуд Гарәбстаны, Иран, Венесуэла һәм Гыйрак. Җитмешенче еллар башында бары тик әлеге биш ил генә Татарстаннан күбрәк нефть таба. Җиде ел дәвамында (1970 елдан 1976 елга кадәр) биредә ел саен җир куеныннан 100 млн тоннадан артык кара алтын чыгарыла. Иң биек ноктага 1975 елда ирешәләр – 103,7 млн тонна. 1981 елга республика инде ике миллиард тонна нефть чыгара. Ике дистә ел дәвамында СССР Дәүләт планын җитәкләгән Николай Байбаков соңрак болай диячәк: «Бер кечкенә Татарстан бөтен нәрсәне тотып торды, 35 ел дәвамында Советлар Союзының бөтен икътисады татар нефтенә бәйле булды».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

4. Бәхетле балачак
Сталин һәм Брежнев чорында ул нинди булган

6. Фатир мәсьәләсе
Ул нинди юллар белән хәл ителгән

10. Талонга яшәү
Балдак 8 сум торган чак

12. Коммунистик идеология
Биографиядә чит ил музыкасы калдырган таплар

14. Тимер пәрдә
Ни өчен чит илгә сайлап кына чыгарганнар

16. Алты сутый
Дачалар өчен нинди тыюлар уйлап тапканнар

18. Лаеклы ял
Пенсия акчасына яшәп булганмы

20. Юллар, юллар...
Мунчага дип самолетта очкан вакытлар

22. Түләүсез медицина
Алтын куллы хирурглар һәм булдыксыз дантистлар турында

24. Мәңгелек дефицит
Кара уылдыкны кашыклап ашаган заман

26. Студентлар отрядлары
Чирәм җирләрдәге көтелмәгән хәлләр

28. Хакимият коридорлары
Татар олимпы аксакалы

32. Редакция кухнясы
Гөлнара Габдрахмановадан Яңа ел пилмәне

40. Балачак чыршысы
Совет балалары Яңа елны ничек каршылаган

42. Хезмәт фидакарьлеге
Бөтенсоюз төзелешләре нәрсә белән истә калган

44. СССРда эшләнгән
Кукмарада танылган брендны ничек саклап калганнар

48. Җиде катлы тарих
Социализм принциплары кайда яши

52. Бер, ике, өч! Безнең кулда - көч!
Ни өчен ГТО значогы дистә еллардан соң да тутыкмаган

54. Ял ит, ахирәт...
Ни өчен айныткычларны кире кайтарганнар

68. Тарих сәхифәләре
Галимҗан Баруди язмышы

72. Китап киштәсе
Разил Вәлиев. «Манара биеклеге»

76. Укытучылар халык театры
Көндез – укытырга, кичен – репетициягә!

82. Татар авыллары
Олы йөрәкле Түбән Әлки

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!

КОММУНИСТ Татарии

12

ДЕКАБРЬ

1962

«ТУГАН ИЛКӘЕМ, СӨЙГӘН ҖИРКӘЕМ...»*

30 ел элек, декабрь аенда, безнең күбебез туып-үскән ил – Советлар Союзы юкка чыкты. Һәм менә 30 ел дәвамында сәясәтчеләр, галимнәр арасында бәхәсләр тынмый, һәркем «Нәрсә булды? Ник алай булды?» дигән сорауларга җавап табарга тырыша. «Татарстан» журналы исә, бу бәхәсләргә кушылмыйча гына, ул чактагы тормышның асылына төшенергә булды. СССРда яшәү рәхәт идеме яисә кыенмы? Төрле буын кешеләренә әлеге соравыбызны биреп, без бер шарт куйдык: җавап узганыбызда булган чын тарихлар аша бирелергә тиеш.

* «Иртәнге нур» җырыннан. С. Садыйкова музыкасы. З. Вәли сүзләре .

«БАЛАЧАГЫМ ХЫЯЛЛАРЫ КАНАТЛАР КУЯР ӘЛЕ»*

Балачактагы хыяллар һәм дуслык, туйганчы уйнау һәм пионер лагерьларындагы күңелле яллар... «Волга-Волга» ВИА сәнгать җитәкчесе Антон Салакаев гаджетларсыз балачак турында хатирәләре белән уртаклаша.

– Без көннәр буе урамнан кайтып кермәдек, гаджетларны исә иксез-чиксез хыяллар алыштыра иде. Мин туып-үскән Чистайда «Циферблат» уенын яратып уйный идек. Иң башта «Восток» сәгать заводының гаять зур территориясен урап үтәргә һәм, каравылчы күрмәгәндә, предприятиедә бракка чыгарылган нәрсәләр ташлана торган «сәгать чүплегенә» эләгергә кирәк. Нәрсә эзлибезме? Әлбәттә инде, атаклы «Командирские» сәгатьләренең циферблатларын! Аларның бизәлү төрлелеге шаккатыргыч иде. Араларында еш очрый торган сурәтләр дә, бик сирәкләре дә очрый. Без аларны сәгатьләр буе карарга әзер – һәр рәсемнең үзенчәлеген һәм бик вак хәрефләр белән язылган сүзләрне җентекләп өйрәнәбез. Уен үзе исә бик күп кагыйдәле гольфны хәтерләтә – комда чокыр казыйбыз да шунда төрле ысуллар белән циферблатны төртеп төшерергә тырышабыз. Чүплеккә бик сирәк эләгеп булганга, без үзебезнең циферблатлар тупланмасын нәкъ менә шул уен вакытында гына баета ала идек.

Һәрберебезнең тагын бер хыялы бар иде әле. Велосипед! Бабам миңа башта өч тәгәрмәчлесен алып бирде, аннары шуны ике тәгәрмәчлегә әйләндерде. Әмма бик тиздән минем сөенечем көенечкә әйләнде – дусларым күптән инде «Школьник» велосипедына күчте, ә мин әле һаман үземнең кечкенә сәпидтә йөрергә мәҗбүр идем. Ләкин бабама рәхмәт: ул туган көнемә инде зурлар өчен тәгаенләнгән «Кама» бүләк итте. Бу инде бөтенләй башка дәрәҗә иде! Җыелмалы рамлы зур велосипед. Дусларым арасында мин чын корольгә әйләндем. Өлкәннәр безнең балачак хыялларын менә шулай тормышка ашырды.

Пионер лагеренда ял итү дә совет балалары хыялларыннан берсе иде. Юлламаны әти-әниләргә эшләреннән бушка яки бик арзанга гына бирәләр. Анда иң көтеп алганыбыз – «Аҗаган» уены, Нептун көнендә туйганчы су коену һәм бер-беребез белән су сибешү. Һәм, әлбәттә инде, соңгы дискотека – «пионерларча романтика» һәм саубуллашу кичәсе. Тәүге тапкыр пионер лагерена мин бик кечкенә вакытта ук бардым. Чулман елгасы буендагы Лиза Чайкина исемендәге лагерь иде ул. Аннары исә без Казанга күчендек, һәм әтиәни мине Коры Елгадагы «Чайка» лагерена җибәрде. Барысы да бик шәп иде, әмма Нептун көнендә су сибешкәндә мин кадакка бастым. Һәм минем өчен «Чайка»дагы смена шуның белән тәмамланды, аягымда әлеге шатлыклы көннәр хатирәсе булып җөй генә калды. Ә менә «Мечта» дигән матур исемле лагерьда ялым искиткеч булды! Ул җәйдәге күп хатирәләр әле һаман күңелдә саклана. Иң мөһиме – андагы мохит. Искиткеч җылы. Бәхетле совет балачагының маркерлары менә шулар. Ә безнең балаларның шундый сөенечле хатирәләре булырмы икән? Т

* «Балачак хыяллары» җырыннан. Ф. Әхмәтов музыкасы. И.Юзеев сүзләре.

«АТАСЫ ӨЧЕН УЛЫ ҖАВАПКА ТАРТЫЛМЫЙ...»

Балачак сасы баланда исен хәтерләтергә дә мөмкин икән. Әгәр сиңа дүрт яшьлек чагыңда ук «халык дошманы улы» мөһерен таксалар... һәм «тоткыннар сабыйлары өчен тәгаенләнгән балалар йортына җибәрергә» дигән хөкем карары чыгарсалар...

Ул үзенең әнисеннән ничек аерылуын хәтерләми диярлек. Бернинди кара машина да килми – НКВДга гына «чакырталар» әнисен. Гадәттә «халык дошманнарының» беренче булып әтисе кулга алына. Әмма нәни Вася башта әнисез кала. Казандагы Черек күл янындагы куркыныч бинага үзен озата килгән иренә ул: «Без бүтән күрешмәячәкбез», – ди.

Аннары исә Васяның тормышыннан әтисе дә югала. Соңрак ул үзләренә тентү белән килгәннәрен, биш бүлмәне (әтисе шәһәр советы рәисе бит, фатир зур була) дә ябып, пичәтләп куйганнарын искә ала. Ул чакта әле дүрт яшьлек сабый фаҗиганең никадәр тирәнлеген аңламый. Фатирдан әйберләрне һәм китапханәне төяп китәләр. Китаплар бик күп, ә менә өй кирәк-яраклары бик аз була. «Патефоннан кала бернәрсәләре дә юк». Аларга иң кечкенә бер бүлмәне калдыралар. Бәләкәй Вася анда әбисе, караучысы һәм ике авыл хатыны белән яши. Нибары бер ай, аннары исә аны да алып китәләр.

Күн курткалы түтәй аны халыкта «эмка» дип йөртелгән ГАЗ М-1 машинасына утырта. «Әтиең белән әниең янына барабыз», – дип, кәнфит суза. Васяны кулга алынучыларның балалары тупланган коллекторга китерәләр. Анда ул башка балаларның мендәр атышып уйнаганын тыныч кына караватта карап ята. Үзләрен нәрсә көткәнне белми шул әле ул сабыйлар...

Хәтерендә калган чираттагы сурәт – койма эчендәге борынгы зур кирпеч йорт. Аның артында исә әбисе елый – «шундый бәләкәй генә карчык...» Юлга чыгалар, аннары малай ярты ел буе үзе кебек сабыйлар белән Костромадагы махсус балалар йортында яши...

Әгәр абзасы Андриан Васильевич килеп тавыш куптармаса, атаклы язучы Василий Аксёновның язмышы ничек булыр иде, билгесез. Тарихчы доцент ул вакытта Сталинобадтагы университеттан куылган һәм Казанда үзен кулга алуларын көтеп ята торган була. Бернәрсәдән дә курыкмый инде. Үзенең балалар йортыннан ничек котылуын Аксёнов болай сурәтли:

«...Һәм ул (Андриан Васильевич), бераз салып, НКВДга килә һәм йодрыгы белән ишекне дөбердәтә башлый: «Бирегез малайны!» – ди. Һәм аңа кинәт: «Ярар, алып китегез», – диләр. Дилбегә бераз бушаган чак була бу – Сталинның: «Атасы өчен улы җавапка тартылмый», – дигән вакытына туры килә.

Әнисе Евгения Гинзбург белән Аксёнов тагын ун елдан соң гына күрешәчәк. Һәм бу инде бөтенләй башка тормышның башы булачак.



«СӨЙЛӘШСӘК ТӘ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ, БЕЗ ЯШИБЕЗ СОВЕТ ИЛЕНДӘ...»*

– Һәр совет кешесе бушлай торакка исәп тота ала, әмма аны алу бик катлаулы иде. Яр Чаллыга хатыным белән авылдан күченеп килдек, – дип искә төшерә Фиргать Шәйхетдинов. – Яшь белгечләргә фатирга чиратта ун елдан да ким торырга туры килми иде. Ләкин безнең гөрләп торган чак – КАМАЗда комсомол-яшьләр бригадасында эшлибез. Тулай торакта яшибез.

Безгә фатир мәсьәләсен үзебезгә чишәргә тәкъдим иттеләр. Моның өчен яшьләр-торак комплексы (МЖК) төзелешендә катнашырга кирәк иде. Әлбәттә, без бик теләп ризалаштык. Безнең кебекләр беренче вакытларда шактый иде, тора-бара кайберәүләр китте. Йорт төзелешендә булачак хуҗалар күпмедер сәгать эшләргә тиеш иде. Мин үзем бөтен ялларымны диярлек төзелеш мәйданында уздырдым, үз фатирымны үз кулларым белән төзедем дияргә була. Кайчак күңелгә шик тә кергәләде: төзелеш материалларына кытлык булган заманда йортны салып бетерә алырбызмы? Ләкин иң авыр вакытларда ярдәмгә һәрвакытта да предприятиебез килде. Йортны төзеп бетерә алдык без. Моның өчен бер ел вакыт китте.

Балалар бакчасы да, мәктәп тә салдык. Ишегалдында чын күршелек атмосферасы урнашты. Чөнки яшьләр-торак комплексын төзү ул бирелгән квадрат метрлар гына түгел. Ул эш барышында дуслар, күршеләр белән дуслашу, хәтта туганлашу диярлгә дә була. Инде күптән ул йортта яшәмәсәк тә, әле бүген дә бер-беребез белән аралашып яшибез.

Асылда бу киң күләмле яшьләр эксперименты булды, ул безнең күңелләргә хуш килде. Без аннан соңгы үзгәрешләргә дә ышанып яшәдек. Әмма базар икътисадына күчүгә, МЖК системасы җимерелеп төште. Без «соңгы вагонга» әлгеп калдык булып чыга.

Яшьләр-торак комплекслары хәрәкәте Мәскәү янындагы Калининград шәһәрендә (бүген – Королёв) башлана, анда 1971 елда әлеге комплекска караган беренче торак йорт нигезенә субай сугыла. 1985–1986 елларда МЖКны хуплап чыгарылган хөкүмәт карарыннан соң, яшьләрнең әлеге башлангычы бөтен төбәкләргә диярлек тарала. Ул яшьләр өчен фатир мәсьәләсен хәл итүнең иң нәтиҗәле ысулы санала. Моннан тыш яшь гаиләләр өчен торак комплекслары эчендә социаль инфраструктураны мөстәкыйль формалаштыру мөмкинлеге дә туа.

КАЗАНДА МЖК БУЕНЧА 1500 ЯШЬ ГАИЛӘ ҮЗЕНӘ ТОРАК ТӨЗИ.

* «Дуслык турында җыр». Салих Сәйдәшев музыкасы. Әхмәт Ерикәй сүзләре.

«КЕШЕНЕ ЙОРТЫННАН, ИЛЕННӘН АЕРЫП ЙӨРТКӘН КҮП ЮЛЛАР БАР...»*

Көнбатыш Себергә нефть-газ чыганакларын үзләштерергә дип килгән татарстанлылар өчен аерым фатирларны вакытлыча төзелгән корылмалар – балоклар алыштыра.

– 1977 елның маенда кызым белән Уренгойга ирем янына килеп төшкәч, аптырап калдым: кая эләктек без? – дип искә төшерә Сәҗидә Зыятдинова. – Кайда монда бәдрәф, су, суыткыч? Балок янында нинди этләр ул? Ут шулай гел сүнеп торамы? Пыяла арасында нигә мүк, анда нинди нарат җиләге? Монда ничек юынырбыз икән?

Ирем сабыр гына аңлата:

– Бәдрәф салкын якта... Суны атнасына өч мәртәбә китерәләр... Ут көчле җил булганда гына сүнә, әмма генератор бар. Бу болан мүге, мин аны җылы булсын дип, рам арасына салдым, нарат җиләге матурлык өчен – үзем уйлап таптым, сиңа ошыймы? Күчмә мунчада юыначакбыз, бу атнада килергә тиеш. Соңрак мунча төзербез. Этләрме? Ну, хатын, төньякта этләрсез булмый инде...

Ә аннан соң тыныч кына өстәп куя:

– Әйдә, болай сөйләшәбез. Әгәр сез бер ай эчендә мондагы тормышка ияләшә алмасагыз, мин сезне кире кайтарып куям.

Беркемгә дә кире кайтырга туры килмәде. Беренче курку, шик-шөбһәләр үтте. Без көн-күрештәге кыенлыкларга ияләшә төштек. Әйе, нәкъ шулай. Мунчаны да салдык. Алай гына да түгел, монда Әлмәттән килеп эшләүче күпме якташыбыз, дусларыбыз безнең мунчага юынырга йөрде әле! Бик күңелле яшәдек!

Бездә Байкал-Амур магистрален төзегәндә кулланылган «БАМ» сериясендәге җыела-сүтелә торган күчмә йортлар да бар иде. Без аны «бамныкы» дип кенә йөртә идек. Вагон-йортлар, вакытлыча төзелгән корылмалар – балоклар, цилиндр (мичкә) йортлар да булды. Шундыйлардан Поляр түгәрәге аръягында алардан тулы бер шәһәрчекләр үсеп чыкты. Алар нефтьчеләр һәм газчылар өчен «өй» сыйфатында гына түгел, тулай торак, ашханә, кибет, медпункт буларак та кулланылалар иде. Гадәти вагон-йорт – зур булмаган пространство яратучылар өчен менә дигән яшәү урыны. Кечкенә генә тамбур һәм ике торак бүлмә. Әлбәттә, гаиләлеләр аларга өстәп тагын юыну, йокы бүлмәләре һәм хәтта мунча да салалар иде – барысы да хуҗаларның теләгеннән һәм фантазиясеннән тора.

Берничә елдан соң без үзебез төзегән корылмалардан барлык уңайлыклары булган фатирга күчендек. Әмма шунысын төгәл әйтә алам: ул елларда Көнбатыш Себергә эшкә килгән нефтьче татарстанлылар өчен вагоннарда, балокларда, мичкәләрдә яшәү беркайчан да тормышның төбен аңлатмады. Чөнки коммуналкаларда, «хрущевкаларда» яшәү кебек үк, бу да миллионлаган совет кешеләре өчен гомерләренең иң мөһим, күңелле һәм матур чоры – бала чагы һәм яшьлеге белән бәйләнгән иде.

* «Туган як» җыры. Мансур Мозаффаров музыкасы. Мөнир Мазунов сүзләре.

«ҖИРДӘ КЕШЕ БУЛУ ӨЧЕН, КЕШЕ КҮПМЕ ЮЛЛАР ҮТӘ»*

– Студентлар никадәр генә каһәрләмәсен, фәнни коммунизм дәресләре аларны, ягъни безне, укырга өйрәтә иде. Мин хәзер шулай уйлыйм. Узган гасырның 80 нче еллар азагы – 90 нчы еллар башында исә мин бу фәнне күралмый идем, – дип искә ала шул дәвер студенты Анжела Алексеева.



Никадәр генә тырышсам да: «Диалектик һәм тарихи материализмнан аермалы буларак, фәнни коммунизм барлык яки күп иҗтимагый-икътисадый формацияләрдә гамәлдә булган гомумсоциология законнарын түгел, бәлки коммунистик формациянең үзгә, специфик законнарын, аның барлыкка килүен, аякка басуын һәм үсешен өйрәнә. Сәяси экономиядән аермалы буларак, фәнни коммунизмның игътибар үзәгендә социализм белән коммунизмның икътисадый түгел, бәлки социаль-сәяси мөнәсәбәтләре һәм аларның үсеш закончалыклары тора», – кебек гыйбарәләрне мин аңлый да, ятлый да алмадым.

Фәнни коммунизмнан имтиханны профессор Комаров ала. Өлкән курслар әйтүенчә, бер генә өмет бар: имтихан башлангач ук, әгәр кем дә булса шундук билет алып, әзерлексез җавап бирсә, Комаров аның билгесен бер баллга арттырырга вәгъдә итә.

Шулай булды да. Мөгаллим авызыннан әлеге сүзләр чыгуы булды, мин ризалыгымны белдердем. Профессор кыюларны хөрмәтли икән, миңа җылы караш ташлады. Мин исә, ничек тә булса өчлегә сөйләп, аның дүртле куюына өметләндем. Алайса стипендиядән колак кагачак идем бит.

Билет алып, капитализмның һәлакәте котылгысыз булачак, җәмгыятьтә коммунизм тантана итәчәк кебек ике-өч җөмлә әйттем дә, көймәм комга терәлде, белгәнем шуның белән бетте.

Профессор тантаналы рәвештә минем берлегә җавап бирүемне, әмма вәгъдәсендә торачагын һәм миңа икеле куячагын хәбәр итте! Көзгә имтиханны кабат биреп карарга мөмкин булачак иде.

Имтиханнарны дүртледән ким билгегә бирүчеләр стипендиядән колак какты, мин әле ул елны тулай тораксыз да калдым. Акчасыз да, тораксыз да яшәргә туры киләчәк иде.

Җәй буе фәнни коммунизм өйрәндем. Яттан! Ә аны, сәяси строй алышынгач, уку программасыннан төшереп калдырдылар. Булмаган фәннән ничек имтихан бирәсе инде?

Деканатта билгемне өчлегә үзгәрттеләр, әмма стипендия дә, тулай торак та бирмәделәр – янәсе, сессиядән сессиягә кадәр рәхәт чигәргә түгел, укырга кирәк иде.

Ничек тә тартып-сузып җиткерү өчен, төнге сменага икмәк заводына эшкә урнаштым. Төнлә эшләдем, көндез төркемдәш кызларым булмәсендә йокладым. Буш вакытым булган саен китапка ябыша идем – киләсе елда да стипендиясез һәм тулай тораксыз калмас өчен тырышып укырга туры килде. Шул рәвешле, фәнни коммунизм миңа укуга куәтле этәргеч бирде.

Инде күп еллар үтте, әмма әле хәзер дә мине профессор Комаров (яки аның өрәге) төнлә йокымнан уятып: «Нәрсә ул фәнни коммунизм?» – дип сораса, мин бер сулышта: «Бу – пролетариатның сыйнфый көрәше һәм социалистик революция, социализм һәм коммунизм төзелешенең социаль-сәяси закончалыклары, тулаем дөньядагы революцион процесс турында фән», – дип җавап бирәчәкмен. Аның диалектик һәм тарихи материализмнан нәрсә белән аерылуын да тәфсилләп аңлатачакмын. Ә сез шулай булдыра аласызмы?

* «Дуслык турында җыр». Салих Сәйдәшев музыкасы. Әхмәт Ерикәй сүзләре.

«ТИПСЕН ЙӨРӘК, СҮНМӘСЕН ДӘРТ»*

Совет югары уку йортларында яхшы белем бирелә. Әмма фәннәрне үзләштерү әле ул арты эш кенә. Дипломында белгечлегең буенча «бик яхшы» билгеләре генә торса да, «дөрес» инануың һәм идеологик карашың булмау якты киләчәктән мәхрүм итәргә дә күп сорамый...

– Университетта фәнни коммунизмны безгә Комаров фамилияле мөгаллим укытты, – дип сөйли 1981 елда КДУ ның филология факультетын тәмамлаган Наилә Хәйретдинова. – Аңардан «бик яхшы» билгесен алу мөмкин түгел диярлек иде. Студент имтиханда билетына бик шәп җавап бирсә дә, мөгаллим аңардан ялагай тавыш белән сорамый калмый:

– Әйтик, сезнең бик якын кешегез вафат, ул сезгә үзен башка шәһәрдә җирләргә васыять иткән. Сез аның әлеге ихтыярын үтәрсезме? – ди Комаров. Студент бер кызара, бер агара, әмма гадел җавап бирә:

– Әлбәттә үтим! – ди.

– Ә менә бу инде дөрес түгел! – дип тантана итә имтихан алучы. – Кеше үлгән, димәк, ул мәет. Мәетнең исә соңгы теләге була алмый...

Комаровның әлеге капкыны хакында тарихны студентлар курстан курска мирас итеп тапшыра, әмма бу беркемне дә диярлек коткармый: имтиханда нигәдер барысы да сорауга намуслары кушканча җавап бирә.

Фәнни атеизм догмаларына ышанмаучыны күп дигәндә стипендиядән мәхрүм итәргә мөмкиннәр. Ә менә уку процессына шыплап тутырылган беркемгә дә кирәкмәгән предметлар, идеологик чүп-чарның безнең бәхетле киләчәккә тулаем тәэсире исә бик зур иде. Курс, диплом эшләрен язганда, тарихи вакыйгаларга бәя биргәндә һичшиксез Октябрь революциясенең «дөньякүләм тарихи әһәмиятен» искә алу мәҗбүри. Сүз хәтта Себернең Ермак тарафыннан яулануы турында барса да...

КПСС, фәнни коммунизм һәм тулаем марксизм-ленинизм тарихыннан чыгарылган «дөньяда иң дөрес» фикер һәм нәтиҗәләрне нормаль аек башлар ничек кабул итәргә мөмкин соң? Әмма әлеге «иң мөһим» предметларны укытучылар белән бәхәсләшү мәгънәсез һәм куркыныч иде. Буш сүзләрне ятлыйсы гына кала, моның исә шәхеснең үсешенә дә, чын белем алуга да бернинди катнашы юк. Аның каравы, җәмгыятькә «кирәкле» билгеләр дипломга төшә, бу исә эшкә урнашканда бик зур роль уйный.

Бервакыт без Кубадан килгән студентлар белән бергә этикадан имтихан бирдек. Параллель төркем старостасы, «батуын» сизеп, Куба кызыннан шпаргалка сорады.

– Син нәрсә, үзең этикадан имтихан бирәсең, үзең шпаргалка сорыйсыңмы?! – дип ачуланды идеяле Куба кызы.

Бездәге ике яклы мораль тормышта бөтенләй башкача булган чакта үзеңнең коммунизм идеяләренә инанганлыгыңны күрсәтү зарурлыгына реакция иде ул. Кемгәдер әлеге ике яклы мораль бик шәп карьера ясарга булышты. Үзеңне җәмәгать эшендә күрсәтү, партиягә керү... – аяныч, ул заманда әлеге казанышлар белемнән артыграк бәяләнә иде шул. Вуз тәмамлаучы коммунистларны һәм җәмәгать эшендә актив катнашучыларны шәһәрдәге абруйлы вазыйфалар, гади яшь белгечләрне исә – әллә кайдагы эш урыннары көтте... Т

* «Кара урман» җырыннан. Татар халык җыры.

«ПАР БАЛДАКЛАР АЛАР – ВӘГЪДӘЛӘШКӘН ПАРЛАР...»*

СССРда өйләнешкә кертелгән талоннар дефицит товарлар, әйтик, кухня җиһазлары, суыткыч, хәтта автомобиль алырга мөмкинлек бирә. Ә кайчак гаилә бәхетенә ачкыч табарга да форсат тудыра.



– Суфия белән өйләнешергә карар кылганда сиксәненче еллар уртасы иде, – дип искә ала Владимир Пшенистов. – Икебез дә студент, нәкъ шул вакыт илдә алтынга бәяләр күтәрелде. Балдакның иң арзан дигәне, әле бүгенгедәй хәтерлим, 108 сум булды – өч айлык стипендия дигән сүз. Инде туйны да кичектерергә уйлаган идек...

Безнең бәхеткәдер, дәүләт, туучылар санын кайгыртып, бер документ кабул итте. Загска гариза биргән һәр кешегә туй балдагы сатып алырга 100 сум күләмендә компенсация бирелә башлады. Безгә бу бик зур ярдәм булды.

Менә ул балдак, беркая да китмәде, дәүләт биргән акчаны кушкач, ул миңа нәкъ сигез сумга төште. Хатынымныкы – кыйммәтрәк, үзебездән унбиш сум түләдек. Һәм әле загста Казанның Бауман урамында урнашкан яңа өйләнешүчеләр салонына (хәзер анда «Сувенирлар» кибете) талон да бирделәр. Без анда туй өчен кирәк булган бар нәрсәне дә ала алдык. Миңа – Польшада тегелгән костюм, Чехословакиянең «Цебо» фирмасында эшләнгән аяк киеме, кәләшемә – ГДРның үзеннән китерелгән туй күлмәге, Югославия итекләре... Боларның барысына да коточкыч кытлык иде, бары тик спекулянтлардан зур бәягә генә табып була. Ә монда – хөкүмәт куйган бәядән!

Пшенистовлар телгә алган яңа өйләнешүчеләр өчен талоннар, ихтимал, чыннан да туучылар санын арттыруга этәргеч биргәндер, гәрчә барысы да талоннарны турыдан-туры – ләкләкләрне чакыру максатында кулланмаса да. Кайбер елгыррак парлар, кайчак импорт әйберләргә ия булу өчен загска барып, махсус гариза тапшыралар иде. Аннан соң, әлеге дә баягы талоннарны алгач, язылышмыйча һәркайсы үз юлы белән китеп бара.

Ә инде дефицит товарлар алырга дип кайбер, бигрәк тә зур предприятиеләрдә бирелә торган талоннарга килгәндә, аларга чыннан да 80 нче елларда румын стенкасы, Яшел Үзәндә эшләнгән «Дубровчанка» кухня җиһазлары, «Ока» яисә «Мир» суыткычлары алырга мөмкин иде. Әмма мондый талонга ия булу лотереяда отуга тиң шул.

Сүз уңаеннан, чыннан да аларны кайчак лотереяга уйнаталар: йөз кешегә бер суыткыч... Товар бүлүнең гаделрәк вариантлары да бар иде. Талон алганда сугыш ветераннары, әфганчылар, алдынгы хезмәткәрләр һәм җәмәгать активистлары өстенлеккә ия була.

Әмма, һәрхәлдә, кухня җиһазлары, төсле телевизор, бигрәк тә «Жигули» автомобиле сатып алу өчен айлар, еллар буе чиратта торырга туры килә. Әмма сез партия өлкә комитетында, башкарма комитетта һичьюгы вахтер яисә машина йөртүче булып эшлисез яисә аеруча сирәк белгечлеккә ия икәнсез, чиратыгызны тизрәк тә итәргә мөмкин.

* «Пар балдаклар» җырыннан. Фирзәр Мортазин музыкасы, Зөлфия Валиахматова сүзләре.

«ТОМЫРЫЛЫП, ЗӘҢГӘР ЯУЛЫК ИЗӘП, ПОЕЗД ЧАБА...»*

-Хөрмәтле пассажирлар, очкычыбыз Татарстан башкаласы герой-шәһәр Казанга төшеп утырды! – дип тантаналы төстә игълан итә стюардесса.
– Ничек герой-шәһәр, дөрес түгел бит?! Казанга – герой исеме, ни өчен? – дип аптырый пассажирлар.
– Ничек нәрсә өчен? Ит юк, май юк, бәрәңге – талонга, ә КАМАЗны төзибез!..

Татарстанда җитмешенче еллар уртасында әнә шундый кызык та, кызганыч та мәзәк киң тарала. Безгә аны Нәзирә Бикмөхәммәтова сөйләде. Талонга яшәүне ул үз җилкәсендә татыган. Бервакыт хәтта Яңа елны да поездда каршы алырга туры килгән аларга...

– 1974 елның декабрь ахыры иде. Ул елны Казанда ит белән май гына түгел, бәрәңге дә талон буенча гына бүленде. Яшелчә кибетендә сатучылар ярымчерек бәрәңгене юеш пычрак арасыннан сөзеп алып үлчәүгә тондыра – анысы да бары тик лимит буенча гына. Уңыш түбән булганга, ул елны бәрәңгене Польшадан сатып алдылар, колорадо коңгызы да шул вакытта ияреп кайтты – элек ул безнең илдә юк иде...

Тик менә талонга бирелгән продуктлар бер айга җитми – ничек кенә бәрәкәтле итеп тотарга тырышсаң да. Ә минем 29 декабрьдә кайнатам үлеп китте. Мөселман кануннары буенча өчесен, җидесен һәм кырыгын үткәрергә кирәк. Суыткыч – буп-буш. Нишләргә? Билет алдык та, 31 декабрь кичендә «Татарстан» поездында ирем белән икәү Мәскәүгә, ашамлыклар алырга киттек. Анда май, тавык, бәрәңге, фил төшерелгән каптагы һинд чәе җыйдык һәм шул ук көнне кире ач Казанга кайтып киттек! Бу четерекле хәлдән әнә шулай чыктык: шөкер, ашларны җиренә җиткереп уздырдык.

Совет тәэминаты мохитендә яшәгән Мәскәү безнең өчен зур ярдәм иде. Ул заманнарда май, венгр тавыклары алып кайтырга Мәскәүгә ялкау гына йөрмәде. Бу турыда тагын бер анекдот бар. Татарстан өлкә комитеты беренче секретарен КПСС ҮКна чакыралар да:

– Фикрәт Әхмәтҗанович, сездә, Татарстанда, тагын бер Бөтенсоюз төзелешен башлап җибәрүгә ничек карыйсыз, булдырырсызмы? – диләр.

– Булдырырбыз, Леонид Ильич, шикләнмәгез!!!

– Ә азык-төлек мәсьәләсен ничек хәл итәргә уйлыйсыз?

– Борчылмагыз, Леонид Ильич, барысы да исәпләнгән, уйланылган! Мәскәүгә тагын бер «Татарстан» поездын җибәрербез...

СССРда товарларны талон буенча бүлү дистә еллар дәвамында бер кертелә, бер юкка чыгарыла, яңадан кертелә. Соңгы талон «эпоха»сы Горбачев идарәсе вакытында, ил таркалыр һәм планлаштырылган совет икътисады җимерелер алдыннан кертелә. Ул чакта барлык төп продуктлар диярлек ирекле сатудан юкка чыга. Ит, май, колбаса, сыр, карабодай, чәй, аракы, шәраб... – бу очракта катгый граммнар буенча. Хәер, санап бетерү мөмкин түгел: җан башыннан талонга үлчәп сатыла торган продуктларга караганда, сатуда иркен булганнарын санап чыгу җиңелрәк булыр иде.

Соңгы кытлык заманы икътисадта барган кыенлыкларның нәтиҗәсе булдымы, әллә инде Горбачевның дошманнары тарафыннан ясалма китереп чыгарылдымы? Бу турыда сәясәтчеләр һәм икътисадчылар әлегә кадәр бәхәсләшә. Ⓣ

* «Саубуллашу» җырыннан. Илгиз Закиров музыкасы, Шарига Таһирова сүзләре.

«ЯШИК БУ ИЛЛӘРДӘ САЙРАП КЫНА...»*

Совет идеологиясе илдә күпмиллионлык кардәшлек булдырды, һәркем әлеге туганлыкны тоеп горурлана иде.

– Кызыл галстук бәйләгәч, пионер икәнне күрсеннәр өчен пәлтәне төймәләмичә йөри идек бит! Билгеле, кемдер яхшы пионер була, кемдер бик үк яхшы да түгел, әмма барыбер бу берләштерә иде. Бу бик куәтле идеологик вазгыять. Минемчә, киләчәктә моңа охшаш нәрсә кабат пәйда булачак әле, – дип сөйли Казандагы Социалистик көнкүреш музеен оештыручы Рөстәм Вәлиәхмәтов.

– Мин «Аҗаган» хәрби-спорт уенында катнаштым. Безнең хәрби-патриотик сыйныф башкаларга караганда спорт белән күбрәк шөгыльләнә иде. Без бассейнга йөрдек, хәрби фәннәр, мылтыктан атарга өйрәндек, пионер галстугы тагып йөрдек һәм моның белән горурландык. Үзебезнең ярышларга баруыбызны, аларның бик яхшы оештырылган булуын мин һаман бер җылылык хисе белән искә алам. Бу – илгә кирәк, безгә исә кызык иде.

Мин мәктәптән соң университетка укырга кердем, КДУның юридик факультетын тәмамладым. Минем өчен мөмкин булмаган нәрсәләр очрамады. Иң мөһиме, минем джинс чалбарым, катушкалы магнитофоным, анда яздырылган үзем яраткан җырлар һәм миннән куркып читкә тайпылмый торган ике-өч таныш кызым бар иде. Тагын нәрсә кирәк инде? Рәхәтләнеп яшә генә!

Сәясәттә бернәрсә дә аңламаганга, тыкшынмадым, ә болай миңа ирек, бәйсезлек җитәрлек иде. Матди нәрсәләр, тормышны җетерәк итә торган ялтыравык җитмәсә генә инде. Әгәр коммунистлар безгә джинс кием, рок-н-ролл, банкалы сыра да бирсә, СССРны саклап калып булыр иде кебек тоела хәтта.

Аның каравы бездә күмәклек, бердәмлек рухы бар иде, ул нык булышты. Макулатура җыю, өмәләр, көзен бәрәңгегә бару – болар барысы да файдалы һәм кирәкле. Бәйрәмнәр чын бәйрәм булды. Беренче май демонстрациясенә рухланып, язгы табигатькә, чәчәкләргә сөенеп, үзеңнең хезмәттәшләрең һәм иптәшләрең арасында булуыңа куанып чыга идек. Иманым камил, күпләр хәзер дә бу демонстрацияләрне, күмәк чараларны юксынадыр.

Вак-төяккә дә шатлана белгәнгә, халык бәхетле иде шул. Аларның ничек кредит түлисе дип баш ватасы юк. Ул заман фотосурәтләрендәге кешеләрнең йөзләренә карагыз әле сез – һич кайгы-хәсрәт чалымнарын күрмәссез. Халык ышана: яхшы эшләсәң – джинс кием аласың, тагын да тырышыбрак хезмәт куйсаң – башта «Жигули» машинасы, аннары дача сатып аласың, аннары балалар институтка укырга керәчәк. Фатирны 20 ел эшләгәннән соң эштә бирәчәкләр. Менә шулай әкренләп тормыш гел алга барды. Яшисе килгән кеше яшәде. Мин ачларны хәтерләмим.



* Очрашу җыры. Илһам Шакиров музыкасы. Гөлшат Зәйнашева сүзләре.

«ҖЫРЛАРЫМ – КАНАТЛАРЫМ МИНЕМ, ҖЫРЛАРЫМ – ХЫЯЛЛАРЫМ...»*

Мәдәният һәм сәнгать совет идеологиясенең катгый кысаларына гел-гел сыешып бетә алмаган. Мондый әсәрләрнең автор һәм башкаручыларына хәтта СССР таркалуга санаулы көннәр калган вакытта да шактый кыенга туры килгән.

Казан егете Максим Журавлев 11 нче сыйныфны 1980 нче еллар уртасында тәмамлаган. Көнбатыш музыкасына гашыйк егеткә озын чәче өчен дә, «дөрес булмаган» идеологиясе өчен дә мәктәптә әледән-әле эләккәләгән.

Укучының әхлагын каты контрольдә тоткан мөгаллимнәр Максимның музыкаль коллективы нәрсә белән шөгыльләнүгә әллә ни игътибар бирмәгән. Шунлыктан аның рок-төркеме рәхәтләнеп мәктәптә репетицияләр үткәргән һәм хәтта бәйрәм чараларында да чыгыш ясаган.

Әмма кичәләрнең берсендә педагоглардан берсе ниһаять яшьләрнең хәйләсенә төшенгән. Максим һәм аның төркеме СССРның коммунистик дусларыныкы (Чили шагыйре Виктор Хара, Че Гевара һәм башка революционерлар) дип башкарган җырлар чынлыкта «Битлз», Боб Дилан һәм капитализм мәдәниятенең башка күренекле вәкилләренеке икән бит! Шау-шу купкан.

Комсомол җыелышында Максимны тикшергәннәр. Сыйныфташларыннан берсе Максим өендәге рок-йолдызлар плакатларын искә алган. Мәктәп җитәкчелегенә бу җитә калган. Максимны мәктәптән генә түгел, комсомолдан да чыгармакчы булганнар.

– Уен коралларымны җыеп, мин күршедәге мәктәпкә күчтем һәм, тыелган музыка уйнап, «совет яшьләрен таркатуымны» дәвам иттем, – ди Макс. – Өч елдан соң Казандагы фәнни-тикшеренү институтларыннан берсенә рәссам-бизәүче булып урнаштым. Бәйрәм кичендә берничә үз җырымны русча башкарганнан соң, мине эштән кудылар. Идеология бүлеге үзгәртеп кору елларында да яхшы эшли иде әле.

Гопниклар да, иминлек органнары да рокерларга тыныч яшәү мөмкинлеге бирми. Шуңа да карамастан, Макс та, дуслары да күңелле яши. Чөнки янәшәдә һәрвакыт фикердәшләре һәм Максның иҗатын яратучылар була.

– Илдә ул чакта рок-н-роллдан шулкадәр куркулары хәзер көлке тоела. Шул ук «Битлз» сөенеч һәм мәхәббәт турында гына җырлый бит инде югыйсә. Әмма хакимиятне ирек рухы куркыта. Алар нәкъ менә шуннан сакланырга тырыша, – ди Максим. – Әмма азатлык һәрвакыт җиңә. Чөнки – All You Need Is Love!



* «Җырларым – хыялларым!» җырыннан. Зөлфәт Хаким сүзләре һәм музыкасы

«КАЯ ГЫНА КИТЕП, КАЙЛАРГА БАРМАДЫМ...»*

1982 елның ноябрь бәйрәмен казанлы Шәүкәт Рахманкулов Яңа Афонда мандарин агачлары арасында каршы ала. Аннары Тбилисига юл тота, шуннан – таулардагы турбазага, Степанаванга, соңыннан – Ереванга... – Кавказ аръягы буйлап әнә шундый үзенә күрә дөнья тирәли сәяхәт. Һәм болар барысы да бик арзан хакка.

– Ял ноябрьгә туры килде, димәк, диңгезгә барып булмый. Шуңа күрә без иптәшем белән туристлык юлламасы буенча кая да булса чыгып китәргә булдык, – дип искә ала Шәүкәт Морат улы. – Предприятиеләрдә юлламалар белән проблема юк иде. Грузия һәм Әрмәнстан буйлап ике атналык сәфәрне сайладык. Һәркайсыбыз нибары 38әр сум түләдек – бу юллама бәясенең 10 процентын тәшкил итә. Калган 90 процентны предприятиенең профкомы күтәрде. Без нинди дә булса кәттә хезмәткәр булган өчен түгел ул – барлык туристик юлламалар өчен дә ун процент кына түлисе иде. Эшчеләр өчен дә, инженер-техник хезмәткәрләр өчен дә бертөрле. Һәм бу – һәр предприятиедә шулай.

Сәфәр искиткеч шәп булды. Абхазиядә, дип искә ала Шәүкәт Рахманкулов, дүрт көн йөрдек. Мандарин җыю сезоны иде, үз бакчаларында үскән җимешләрне җирле халык почмак саен сата – килограммы бер сумга. Моны астыртын

эшлиләр, чөнки уңышны арзан бәягә дәүләткә тапшырырга мәҗбүр итәләр. Шуңа күрә дәүләт кибетләрендә килосы ике сум илле тиенгә вак, шиңгән мандариннар өелеп ята...

Ашау, яшәү, экскурсияләр, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрүләр – барысы да бәягә кертелгән. Дөрес, биш йолдызлы кунакханәләргә урнаштырмадылар – андыйлар юк иде. Яңа Афонда, элеккеге монастырьда (хәзер янә үз вазыйфасын башкара – ред. иск.), монах хөҗрәләрендә яшәдек. Һәр шундый номерда сиртмәле дүрт-биш карават тора. Бәдрәф – коридор башында. Ашханә – шул совет чорындагыча: агуланмагансың икән, инде яхшы дигән сүз. Аның каравы Тбилисида күп катлы «Ваке» кунакханәсендә туктадык, Степанавандагы турбаза бөтенләй чит ил булып тоелды. Ереванда да кунакханә шактый заманча иде.

– Ә нинди экскурсияләр булды! Яңа Афон мәгарәләренә, борынгы Тбилисига, Мцхетага, Эчмиадзин – бөтен әрмәннәр католикосы резиденциясенә... Кырык елга якын вакыт үтте, ә мин һаман барысын да бөтен ваклыкларына кадәр хәтерлим, – ди Шәүкәт Рахманкулов. – Бәлки, бүген мондый сәфәр минем теш үтәрлек булмагангадыр...

Чаллыдан Галина Николаева да җитмешенче-сиксәненче елларда ялларын гел туристлык сәфәрләрендә үткәргән. Ул сәяхәт кылган калалар исемлегендә Алтын боҗрага кергән шәһәрләр, Таллин, Ленинград, Ташкент, Светлогорск һәм хәтта Владивосток та бар. Бөтен юлламалар да ташламалы, ун процентын гына түли идек, дип искә ала ул. Сәфәрне һәркем үз кызыксынуына карап сайлый. Кемгәдер төрле шәһәрләргә экскурсия турлары ошый, икенчеләре, актив туризмны яратучылар, тауларга юл тота – Домбайга, Грузиядәге Бакурианига, Башкортостанга.

– СССРда әле ял көне сәфәрләре дә оештырыла, андый сәяхәткә бөтен коллектив белән чыга идек, – дип искә ала ул. – Без, гадәттә, Казаннан Ульяновскига, Горькийга (Түбән Новгород), Куйбышевка (Самара) теплоходта бара идек. Хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары өчен мондый сәфәр хакын тулысынча предприятие түләде. Кайчагында моның өчен хәтта бөтен теплоходны яллыйлар иде.

* «Туган җирем – Татарстан» җырыннан. А. Ключарев музыкасы. Г. Зәйнашева сүзләре.

«ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ЧЫКСАҢ...»*

1975 ел. СССР иркен тормышлы Брежнев чорында. Казаннан ирле-хатынлы Шакировлар ялларын искиткеч шәп итеп уздырырга ниятли. Чит илгә, Болгариягә барып кайтырга! Балалар белән бергә! Ул вакыт өчен бу сәфәр хәзер Төньяк полюска бару кебек буй җитмәс хыял тоела!

Советлар илендә шаян әйтем йөри: «Тавык кош түгел, Болгария чит ил түгел...» Социалистик Болгарияне, түбәнсетеп, союзның уналтынчы республикасы дип атыйлар – анда тормыш Совет илендәгедән әллә ни аерылмый янәсе. Тик ул шаян төрттерүне Болгариядә булмаган кешеләр уйлап тапкан. Шакировлар моннан ике ел элек юллама белән икәүләп барып кайта һәм сокланып туя алмый. «Слынчев Бряг» курорты, кунакханә (безнең көньяктагы кебек тәүлегенә бер сумлык, һич уңайлыклары булмаган бүлмә түгел инде), җиләк-җимешләр, рөхсәт ителгән дәрәҗәдә алмаштырылган валюта бәрабәренә исә хәтта модалы «джерси» пальтосы һәм башка бик күп нәрсә сатып алалар...

Бергәләп бару мөмкинлеге башка булмаячак: балалар тиздән мәктәпне тәмамлый. Партия райкомында үткәрелгән әңгәмәдә ир белән хатын бу хакта дөресен сөйли. Гаять җаваплы иптәшләр утырган өстәл артындагы кырыс ханым, үтәли тишәрдәй итеп карап, сорау бирә: «Нинди максатта әле сезнең чит илгә барасыгыз килә, ни өчен бөтен гаилә белән?»

Җавап биргәндә, Шакировлар бик дулкынлана, югыйсә моңа сәбәп тә юк. Икесе дә – ышанычлы кеше, һөнәри-техник училище укытучылары, гаилә башлыгы – КПСС әгъзасы. Анкета да, эш урынынннан характеристикалары да (аны тапшыру мәҗбүри) – тел тидererлек түгел! Әңгәмә тәмамлана һәм чит илгә бару өчен кандидатларга коридорда көтеп торырга кушалар. Алар язмышын хәл итәчәк хөкемдарлар киңәшмәгә кереп китә.

– Сезгә сәфәр чыгарга рөхсәт бирелми, – ди боздай салкын чырайлы ханым. – Үз илебез буйлап күбрәк сәяхәт кылырга киңәш итәбез...

Барып чыкмаган ул сәфәр турында бүген сөйләгәндә дә, Галия апаның нәкъ кырык алты ел элеккедәй кәефе кырыла. Куштан партия түрәләренең кирелеге аркасында ул вакытта аларга Болгария тарафын ябып куялар. Ә чит илгә бөтен гаилә белән бару бәхете, алар инде көзаллаганча, бүтән тәтеми дә.

Хәер, совет гражданнарының күпчелеге өчен чит илгә бару бөтенләй чынга ашмаслык хыял була. Берәүләренә – ышанычсыз зат дип саналганга күрә, икенчеләренә – яшерен производствода эшләгәнлектән, өченчеләренә – партия райкомында уздырыла торган мәҗбүри әңгәмәдә Чили коммунистлар партиясен кем җитәкли, дигән сорауга җавап бирә алмаганлыктан...

Сирәк булса да бәхет елмайган затлар – партия түрәләре һәм активистлары, предприятие директорлары һәм җитештерү алдынгылары – чит илгә, нигездә социалистик дәүләтләргә, егерме биш кешедән гыйбарәт оешкан төркемнәр составында гына бара ала. Иң әүвәл мәҗбүри инструктаж көтә: анда үзеңне ничек тотарга кирәк, кем белән аралашырга мөмкин һәм кем белән аралашырга ярамый – барысы да Высоцкийның атаклы җырындагы кебек...

Һәр төркемгә үз кул астындагы туристларның тәртибен күзәтеп йөриячәк җитәкче (ул казна хисабына сәяхәт итә) билгеләнә. Туристлар арасында, һичшиксез, КГБдан бер күзәтче бара– бер-бер хәл килеп чыкмасын өчен. Ә чит илдәге истәлекле, матур урыннарга сокланып йөрү расланган маршрут буенча гына рөхсәт ителә, төркемдәгеләр бөтенесе бергә йөрергә тиеш, программадан бер адым да тайпылырга, үзбаш каядыр барырга ярамый.

Шундый очрак билгеле: ГДРга барган Казан төркеменнән өч турист, башкалардан аерылып, немец эшчеләре белән дуслык кичәсенә бармый кала. Җитәкче аларның «коточкыч» гамәле турында шунда ук эш урынына хәбәр итәргә һәм алар өчен чит илгә чыгу мөмкинлеген мәңгегә ябып куярга вәгъдә бирә. Бәхеткә, бу хәл инде үзгәртеп кору җилләре исә башлаган 80 нче еллар тирәсендә була... Ⓣ

* «Чит илләргә чыксаң...» җырыннан. Сара Садыйкова музыкасы. Илдар Юзеев сүзләре.

«БАКЧАМ ГАДИ, ҮСМИ АНДА, КИПАРИСЛАР, ХӨРМӘЛӘР...»*

Советлар Союзы идеологиясе хосусый милекне санламый. Тик шуңа карамастан, ул чакта да һәркемнең мөлкәте булуны икърар итү мәгънәсез, ә дачалар исә моңа иң зур дәлил булып тора. Өстен катлам өчен генә зиннәт объекты булудан туктап, шәһәр читендәге җир кишәрлекләре әкренләп гавам өчен дә ләззәт чыганагына әверелә.

Өлкән яшьтәге немец яшел чирәмдәге шезлонгта утыра һәм газета укый. Германиягә сәфәре вакытында Никита Хрущевның күз алдында пәйда булган нәкъ менә шул манзара КПСС ҮК Беренче секретарен дача кампаниясен башлауга этәргән диләр: янәсе, без кемнән ким әле, ни өчен совет халкы да шулай ял итмәскә тиеш!? Һәрхәлдә, «Хрущев җепшеклеге» вакытында дачалар төзелешенә яңа сулыш өрелә.

Кишәрлекләр бушлай бүленә. Еш кына – социализм төзү эшендәге һәм ил файдасына башка казанышлар өчен бүләк сыйфатында бирелә. Менә дигән бүләк бит!

– Безнең гаилә хыялы 1971 елда тормышка ашты, – дип сөйли Нина Архипова. – Әтиебез, отставкадагы офицер, сугыш һәм социалистик хезмәт ветераннары җәмгыятенең ял базасы территориясендә дача йортын төзү мөмкинлеген алды. Бик сөендек, чөнки әлеге база Казан янындагы гаҗәеп матур нарат урманында урнашкан иде.

Дачада йорт кына гаилә милке була. Дүрт сутыйлы кишәрлек озак вакытлы арендага бирелә. Дача тормышы күршеләр белән якын аралашусыз була алмый. Гаиләләр дуслаша, бергәләп Иделгә төшәләр, бадминтон уйныйлар, бәйрәм итәләр...

Бигрәк тә 1980 елның җәе Нина Александровнаның хәтерендә калган. Мәскәүдә Олимпиада барган көннәр. Ул чакта дачада телевизор зур байлык саналган, шулай да күрше ял базасында бер булган. Аны көн саен урамга алып чыгып куйганнар, һәм урман зур тамаша залына әйләнгән. Барысы бергә совет спортчылары өчен җан аткан. Спорт бәйрәме тәгәлләнгәндә күккә очкан аю баласына карап та бергәләшеп елаганнар.

Авырлыкларны да бергә җиңгәннәр.

– Бервакыт күршеләребезнең түбәсе тишелде. Без, күрше-тирә, ярдәм итәргә ниятләдек, – дип искә ала Нина Архипова. – Дача сезоны вакытында теләсә нинди төзелеш тыела, әмма нишләмәк кирәк? Үч иткәндәй, чүкеч тавышына янәшәдәге ял базалары җитәкчелеге шундук килеп җитте һәм, штраф белән куркытып, эшне туктатуны таләп итте. Без алардан хәлгә керүләрен үтендек, әмма «зур түрәләр» үз сүзендә нык торды. Туктарга туры килде.

Аннары исә кемдер уйлап тапты: күршедәге бөтен йортларда радионы бер дулкынга көйләделәр дә, каты итеп ачтылар. Музыка чүкеч тавышын басты. Түбәне тиз арада төзәтеп тә куйдылар.

* «Үз илемдә» җырыннан. С. Садыйкова музыкасы. Г. Зәйнашева сүзләре.

ТЫРЫШКАН – ТАБАР...

СССР тыю һәм чикләүләр иле була. Дача төзелешенә караганнары да байтакка җыела. Шунлыктан совет кешесенә хыялына ирешү өчен шактый тырышырга туры килә.

– Дачадагы йортыбызны эти-әни үз куллары белән төзеде, яз көнне башлаганнар иде, көзгә тәмамладылар. Совет законнары «ял итүчеләрнең тынычлыгын» кайгырта һәм төзү эшләре вакытын төгәл билгеләгән иде, – ди Нина Архипова. – Регламентлар бөтен нәрсәгә диярлек кагыла. Мәсәлән, урман зонасында койма тоту катгый тыела. Йортларның үлчәме дә билгеле бер нормадан артмаска тиеш. Әлбәттә, катгый кысалардан чыгучы кыю кешеләр дә бар иде. Әмма юкка! Алардан барыбер йортларын законлы үлчәмгә кадәр кечерәйтүне таләп итәләр. Дөрес, йортның үзен ишмиләр, ә «тиешле үлчәмгә» генә китерәләр.

– Бервакыт күрше йорт түбәсенең очын кисеп төшерделәр, – дип искә ала Нина Архипова. – Төзелеш техникасы тавышына базадагы бөтен кеше диярлек йөгереп килде. Без әлеге «закон үтәлешен» яшьле күз белән күзәттек. Әлеге матур йорт барыбызга да бик кызганыч иде!

Тагын бер чикләү урманга кагыла – агач кисү катгый тыела. Ничек булдыра аласың, шулай төзе, тик бөтен наратлар исәптә – кагыласы булма! Шунлыктан күп кишәрлектә

гасырлык ылыслы агачлар ирексездән дача интерьерының бер өлешенә әйләнә.

– Нарат безнең веранда түбәсе аша «үсеп чыккан» иде, – дип сөйли Нина Архипова. – Төгәлрәге, киресенчә, веранда агачны урап алган – чөнки башкача төзергә ярамаган.

Төзелеш материалларын табу да җиңел түгел, алар сатылмый диярлек. Күп кеше кул астындагы материалдан, хәтта агач тартма такталарыннан да төзергә мәҗбүр була. Кайберәүләргә бәхет елмая – эшләреннән нәрсә дә булса эләгә. Күпчелек очракта исә такта, фанера, кирпеч табу өчен шактый тир түгәргә туры килә. Туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәдә дә, чөнки әлеге байлыкны кишәрлеккә кадәр кайтарып җиткерү дә шактый матавыклы. Урамда туктатып, төзелеш материалларына документ таптырулары да бик мөмкин. Кем ничек булдыра ала, шулай җаен тапкан инде ул чакта.

Совет дачаларының тагын бер уңайсызлыгы – чит күзләрдән яшеренә алмау. Бер-берсенә якын урнашкан киртәсез кишәрлекләр коммуналь фатирда яшәүне хәтерләткән. Көн иртән урамда бергәләп юынудан башланып, кич шулай ук тәмамланган да.

– Нәкъ юл өстенә куелган телефон будкасы бөтен күршеләрнең очрашу урыны иде, – дип искә ала Нина Архипова. – Кич саен аның янында галәмәт озын чират тезелә, һәм: «Шикәр һәм печенье алырга онытма!» яки «Әни, җылы кофта алып кил!» – кебек сөйләшүләр бөтен урманга яңгырый. Гомумән, күршеләр тыңлап торганда авызыңны чамалап кына ачарга туры килә. Әлеге будка исә СССР таркалганнан соң да унбиш ел сүтелмәде әле, һәм безгә совет чорындагы бәхетле җәй көннәрен хәтерләтеп торды. Бернәрсәгә дә карамастан!

«БЕР-БЕР АРТЛЫ ЕЛЛАР УЗА, КӨМЕШ ӨСТӘП ЧӘЧЛӘРЕМӘ»*

– Бүген, миллионнарча россияленең пенсиясе яшәү минимумына да җитмәгән, ә пенсиягә чыгу яше берничә елга арттырылган дәвердә, мин совет чорын сагынып искә алам, – ди Венера Зыятдинова.

– Әлбәттә, бөтенләй башка төрле ике чынбарлыкны чагыштыру бәлки урынлы да түгелдер, әмма мин үземә бәхет елмайды, дип саныйм. Предприятиебезнең кадрлар бүлегендә пенсиягә чыгучылар исемлегендә үз фамилиямне дә ишеткәч, баштарак куркып калган идем: пенсионер статусында ничек яшәрмен икән? Диңгезгә дә бара алмам, яңа кием дә сатып алып булмаячак, балаларга да ярдәм итеп булмас инде...

Әмма мин үз гомеремдә эштән шулкадәр туйган идем, пенсиягә чыккач, бер генә көн дә эшләмәскә карар кылдым. Нервлар һәм сәламәтлек теләсә нинди акчадан да кыйммәтрәк. Өзлексез 20 еллык стаж өчен 10 процент өстәмә белән пенсиямнең 132 сум буласын ишеткәч исә сөенечемнән нишләргә белмәдем. Кайбер кешенең хезмәт хакы да моның кадәр булмый әле!

Ура, пенсия! Мин 55 яшемдә кинәт үземне сабый итеп тойдым. Мультфильмдагы кебек: «Телим икән – кәтлит ашыйм, телим икән – кисель эчәм. Теләсәм – тәрәзәгә карап утырам... Теләсәм – караватта ауныйм!» Тәүге эш итеп оныгым белән Анапага диңгезгә китеп бардык. Иртүк сикереп торып эшкә барырга кирәкмәгәнгә куанычым чиксез иде! Пенсиям исә хезмәт хакымнан беразга гына ким булып чыкты...

Сүз уңаенда, 132 сум пенсиягә өстәп мин әле социализмның башка казанышларыннан – арзанлы дарулар һәм транспорт, түләүсез медицина ярдәме, торакка һәм коммуналь хезмәтләргә дотацияләрдән, арзанлы азык-төлектән дә файдалана башладым.

– СССРда халык тормыштан зарланмый, төгәлрәге, киләчәге өчен борчылмый иде, – ди элек Татарстанның Кукмара районында пенсия фонды идарәсе җитәкчесе булган **Әлфинур Сабитова**.

– Ир-атларның хезмәт стажы – 25 ел, хатын-кызныкы 20 ел булса, ул лаеклы пенсиягә өметләнә ала. Эштән туктаганчы 130 сум хезмәт хакы алган кеше шуннан бик азга гына кимрәк пенсия билгеләнгәч, әлбәттә инде, акчасызлыктан интекмәячәк һәм үз киләчәге өчен хафаланмаячак.

Бервакыт минем авылдагы туганым: «Әлфинур, мин 70 сум пенсия алам. Бу бик күп бит! Кая туздырыйм мин аны?» – дип «зарланган» иде хәтта. Әйтик, ул вакыттагы 70 сумга өлкән яшьтәге кешеләр хәзерге 12 мең сумга караганда күпкә яхшырак яши ала иде, дип саныйм.

* «Китмим әле яшьлегемнән» җырыннан. Л. Батыркаева музыкасы. Ф. Зыятдинова сүзләре.

«ӘКРЕН ГЕНӘ, СИЗДЕРМИЧӘ, ЯШЬЛЕК ГОМЕРЕ ҮТӘ...»*

–СССРдагы пенсияләр турында йә елмаеп, йә моңаеп искә алалар, – ди Александр Гайнетдинов. – Минем әбием, Анна Жилина, гомере буе эшләсә дә, 20 сум гына пенсия ала иде. Тик мин беркайчан да аның тормыштан зарланганын ишетмәдем.

Әти белән әни эшли, без оныкларны исә әби карый. Күп кенә совет гаиләләрендәге кебек үк, безнең барыбызны да нәкъ менә ул бер йодрыкка төйнәп тота. Өч буынның бер түбә астында яшәве – ул дәвер өчен гадәти хәл. Балалар киендерелгән, ашатылган, йоклатылган. Ата-ананың күңеле тыныч, алар эштә. Әбиләр һәм бабайлар исә пенсия тиеннәрен санап кайгырып утырмый. Минемчә, пенсиясенең аз саналуы әбиемнең башына да килмәгәндер.

Аның язмышы ул чактагы күп хатын-кызныкыннан әллә ни аерылмый. Ирен сугышта югалткан. Дүрт баласын берүзе аякка бастырган. Әмма язмыш сынауларын һәм тормыш мохтаҗлыкларын һәрвакыт бик сабыр кичергән.

Бервакыт безгә кунакка әбиемнең туганы килде. Пенсиясенең шундый аз булуын белгәч, гаҗәпкә калды. Шул көннән соң өйдә: «Зинаида юллап йөри», – дигән сүзләр ишетелгәләде. Күпмедер вакыттан соң гаделлек торгызылды, һәм, бик азга гына булса да, әбинең пенсиясен арттырдылар.

Мин университетка укырга кергәч, өйгә кайткан саен ул шыпырт кына учыма 45 сум акча сала иде: «Улым, менә сиңа бераз акча. Ач йөрисеңдер инде», – дип. Бик сагынам мин аны хәзер...

1930 ЕЛДА ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН «СОЦИАЛЬ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА ПЕНСИЯ ҺӘМ ПОСОБИЕЛӘР ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ»НЕҢ 12 НЧЕ МАДДӘСЕ СССРДА ПЕНСИЯ СИСТЕМАСЫ ТӨЗЕЛҮДӘ МӨҺИМ АДЫМ БУЛА. Барлык дәүләт предприятиеләрендә эшләүчеләргә картайгач пенсия алу хокукы бирелә. Гәрчә ул чакта СССР күбесенчә аграр ил булса да, колхозчы һәм крестьяннарга дәүләт пенсиясе бирү каралмый.

1936 елгы Совет Конституциясе гражданнарның картлык яки хезмәткә яраксызлык буенча пенсиягә хокукын игълан итә. Бу ни рәвешле гамәлгә ашырыла соң? Ул чакта илдә бернинди пенсия фонды да булмый. Һәр предприятиегә үз социаль фондын булдыру йөкләнә. Колхозларда авыл хуҗалыгы артеле идарәсе гомуми карар буенча социаль фонд һәм үзара ярдәм кассасын төзергә тиеш була. Колхоз бюджеты исә иң әүвәл шул мизгелдәге хаҗәтләргә тәгаенләнә, һәм күп очракта колхозчы пенсионерларга бернинди акча да тәтеми.

Бары тик 1956 елгы дәүләт пенсияләре турында закон гына аларга хокукы булучылар даирәсен киңәйтә һәм күләмен арттыра. Әмма ул да пенсияне нигездә эшче һәм хезмәткәрләр өчен билгели. Һәм бары тик 1964 елгы закон гына колхозчыларны дәүләт пенсиясе белән тәэмин итүнең бердәм системасын кертә.


СВЕДЕНИЯ О РАБОТЕ

* «Картаямыни соң йөрәк?» җырыннан. С. Ибраһимов музыкасы. Г. Нуруллин сүзләре.

«СӘФӘР ЧЫКСАМ ЕРАК ЮЛГА..!»*

Яшел биплан, калтыранып-калтыранып ала да, Тәмте өстенә күтәрелеп, җәйрәп яткан кыр-болыннар, бормалы юллар, киң Идел өстеннән һавада юл ала. Яулыклы әбиләр идәндәге җиләк-җимеш, яшелчә тутырылган кәрзиннәрен кысыбрак тота. Ир-атлар сырага бәяләр турында гәпләшеп ала. Кулларында – каен себеркесенең очы күренеп торган портфель...

15 минуттан Ан-2 Казан уртасына ук диярлек төшеп утырачак. Аның пассажирлары кайсы кая таралыша – кемдер эшкә, кемдер оныкларын күрергә, кемдер исә мунчага һәм салкын сыра эчәргә. Ә кичкә шул ук Ан-2 очкычына утырып кире өйләренә кайтасы...

1960–1980 нче елларда мондый рейслар могҗиза түгел, ә авылдан шәһәргә тиз арада килеп җитүнең чагыштырмача арзан ысулы була. Патрис Лумумба урамында урнашкан Казан аэропортыннан көн саен 20–25 очкыч республика шәһәрләренә, авыл-салаларына оча, дип искә ала Казан авиапредприятиесе генераль директоры Мөхәммәт Зәкәрҗаев. Казаннан Тәмтегә, Кама Тамагы, Тәтеш, Тархан, Буа, Чүпрәле, Алабуга, Мамадыш, Биләр, Аксубай, Чирмешән, Бөгелмә, Зәй, Әгерҗе һәм тагын дистәләгән торак пунктка самолетта очарга мөмкин.

Ан-2 очкычында башкаладан Актанышка кадәр – ике сәгатьтә, Тәмтегә 15 минутта барып җитәргә була. Билет бәясе кыйммәт түгел. Чистайга, мәсәлән, 1970 нче еллар ахырында билетны якынча 3 сумга сатып алалар (шәһәрдә уртача хезмәт хакы 100-120 сум санала).

Ан-2 очкычы зур тизлек белән артык биектә очарга исәпләнмәгән. Ул иң күп дигәндә дә 100-200 метр биеклеккә күтәрелә ала.

Бервакыт, 1976 елда, очкыч Казан аэропортыннан Чирмешәнгә юл тота. Һавага күтәрелүгә үк, аның бер двигателе эшләми башлый. Очучылар самолетны биналардан еракка-рак алып китәргә карар кыла. Машинаны утыртканда электр тапшыру баганасына бәреләләр. Бәрелүдән беренче пилот аңын җуя. Янгын башлана, икенче пилот һәм пассажирлар салоннан чыгарга өлгерә, тик беренче пилотны гына коткара алмый калалар.

– Бу республикада әлеге очкычларны 40 ел эксплуатацияләү дәвамында үлем-җитем булган бердәнбер очрак. Гомумән алганда алар яхшы идарә ителешле, ышанычлы самолетлар, гәрчә бик арзанлы салонлы саналсалар да, – дип аңлата Мөхәммәт Зәкәрҗаев. – 1980 нче еллар башында без Чехословакиянең ике моторлы L-410 самолетларында оча башладык. Бу инде бөтенләй башка дәрәҗәдәге уңайлылык иде.

Әмма тормыш алга бара, республикада юллар төзелә. Автомобильләр авиацияне акрынлап кысрыклап чыгара. Дөрес, Актанышка юл бүген дә алты сәгатькә якын вакытны ала. 1980 нче елларда исә Як-40 очкычында – 45 минутта, L-410 самолетында 1 сәгать 40 минутта очып барып җитеп була иде...

* *«Сәфәр» җырыннан. Татар халык көе. Гөлшат Зәйнашева сүзләре.*

«ОФЫКЛАРГА СУЗЫЛЫП КИТКӘН АВЫЛ ЮЛЛАРЫ МИКӘН?..»*

Бүген без заманча юл һәм транспорт инфраструктурасының уңайлылыгы аркасында республиканың бер башыннан икенчесенә берничә сәгатьтә барып җитәргә күнеккән инде. Ә бит әле кайчан гына Казаннан Яр Чаллыга яисә Кама аръягы төбәгенә барып җитү өчен бер көнгә якын вакыт таләп ителә иде.

– ТАССРда 70–80 нче елларда юллар начар иде. Юл дип аталудан бигрәк хәрәкәт юнәлешен аңлата иде алар. Юлларның ел фасылына бәйлелеге табигать күренеше буларак, тиеш кебек кабул ителә. Язын һәм көзен юлга чыкканда вакытны берничә сәгатькә артыграк булачагын чамалап чыгасың, чөнки пычракта һәм чокыр-чакырлы юлда тизлекне әкренәйтергә туры килә, – дип искә төшерә «Связьинвестнефтехим» АҖ генераль директорының төзелеш секторы мәсьәләләре буенча урынбасары Тәлгать Абдуллин. – Бервакыт без Минзәлә ягына балыкка җыендык. Безнең белән бергә «Уазикта» хәрби комиссар да барды. Шәһәргә кире әйләнеп кайтканда ул батты, көпчәген югалтты, пычрактан чыга алмады. Ә без чыктык, чөнки йөк машинасында идек.

Автомобильдә Чаллыдан Казанга килгәндә үзең белән өч запас көпчәк алырга туры килә: юллар шулкадәр начар була.

Ул заманнарда авиация ярдәмгә килә, әмма аның да үз үзенчәлеге була.

– 1979 елда миңа эш буенча Казаннан Нурлатка очарга туры килде. Һава температурасы -40 градуска төшкән кыш иде. Без 10 урынлы Ан-2 самолеты белән очтык. Яшь вакытым, салкынга ис китми. Һай, ничек ялгышканмын булып чыкты! Самолетның тизлеге зур түгел. Ике сәгать ярым вакыт эчендә катып үлә яздым. Пилотларның үзләренең кабина ишеген ачып, салонга азрак җылы һава чыгарулары гына коткарып калды, – дип сөйли Тәлгать Абдуллин.

Башка юнәлешләрдә сәфәргә чыкканнарны да юл маҗаралары көтеп тора. 80-90 нчы елларда Кама аркылы паромда чыгар өчен иртәнге 4–5тә инде урында – Саескан Тавында булырга кирәк иде. Өлгермәсәң, чиратың җитмичә, кунача калырга туры килә. Соңга калганнар, вакытны үткәрү өчен, гадәттә төнгә балык тотарга китә торган булганнар, дип сөйлиләр.

Моңа охшаш хәлләр Казаннан Югары Осланга Идел аркылы чыгу өчен паром көткәндә дә була. Идел елгасы аша автомобиль күпере 1990 нчы елда ачыла. Әмма Югары Ослангa кадәр нормаль юлны ел ахырына гына эшләп бетерәләр. Ульяновскига машинада бару бары тик 1993 елда гына мөмкин була, чөнки Буадан Ульяновск өлкәсенә юл салына. Мәскәүгә трасса 1996 елда ачыла – Зөя аркылы күпернең икенче чиратын кулланугa тапшырганнан соң. Ә Саескан Тавы янында Кама аша күпернең беренче чираты 2002 елда гына ачыла.

* «Нилэр җитмидер күңелгә?» җырыннан. Л. Батыркаева музыкасы. Ш. Җиһангирова сүзләре.

«ӘФГАН ҖИЛЕ ИСӘ, ӘФГАН ҖИЛЕ, ИСӘ ЙӨРӘКЛӘРНЕ ТЕЛГӘЛӘП!..»*

Әфган сугышы аның тормышын икегә бүлә. 19 яшендә үзе теләп Әфганстанга хезмәт итәргә китеп, аннан сугышның ачысын-төчесен татыган, дусларын югалту газабын кичергән ир-ат булып кайта.



Ильяс Сафин (Дауди) өчен соңгы бәрелеш 1986 елның 23 августында була. Ул каты яралана, әмма куелган сугышчан бурычын үти. Нәтиҗәдә Әфганстанның көнбатышындагы Шинданда госпитальгә илтәләр, анда авыр операция кичерә: сул аягын кисәләр һәм уң аягындагы ядрә кыйпылчыкларын чүпләү буенча беренче табиб ярдәмен күрсәтәләр.

Әлеге госпитальдә җиде көн ятканнан соң, аны Кабулдагы 40 нчы армиянең Үзәк хәрби госпиталенә күчерәләр. Монда ул 1985 елдан 1987 елга кадәр Кабулдагы Үзәк хәрби гопитальдә өлкән ординатор булып хезмәт иткән Бурденко исемендәге Хәрби-клиник госпиталь хирург-травматологларының берсе Александр Теплов кулына эләгә. Икенче аякны коткарып калу өчен көрәш башлана. Теплов егеткә биш (!) операция ясый һәм, бәхеткә, аякны ампутацияләүдән саклап кала.

Ильяс яралангаңнан соң иң беренче авырлыкларны җиңәргә хәрби медикларның ярдәм кулы сузуы турында искә ала: «Кабул госпиталендә аерым бер атмосфера хөкем сөрә иде: чыннан да ихтирамлы, игътибарлы мөнәсәбәт сизелеп тора, вазыйфаи бурыч буенча гына түгел. Бөтенесе бер-берсенә хәрби звание буенча мөрәҗәгать итә, бүлектә дисциплина кушылганга түгел, табигый рәвештә саклана. Без – авыр яралар алган солдатлар өчен болар барысы да бик мөһим иде. Бигрәк тә башкаларның сафта калып, үзебезнең кинәт кенә сугышчан гаиләдән аерылуыбыз газаплый.

Безгә шәфкать туташлары нинди җылы мөнәсәбәттә иде! Болар барысы да яшәргә көч бирде. Безгә, егетләргә, алар дөньяда иң матур кызлар булып тоелды! Иң авыр, иң кискен мизгел: солдатның госпитальдән чыгып, кайтып китүе. Шәфкать туташлары инвалид калган яшь-яшь егетләргә бу чорның авырлыгын җиңеләйтергә булышты».

Ильяс Дауди тыныч тормышка югалтуларсыз әйләнеп кайта ала. Гәрчә бу юл бик сикәлтәле булса да. Бик күп дәвалау учреждениеләре аша уза ул. И.М. Губкин исемендәге Россия дәүләт газ һәм нефть университетында яңадан укый башлый, контузиядән соңгы авырлыкларга карамастан, аны кызыл дипломга тәмамлый.

1986 елның 23 августында кылган батырлыгы өчен Россия Героеның Алтын Йолдызын Ильяс Даудига Кремльнең Георгий залында 2010 елның 19 февралендә тапшыралар.

Ә хәрби хирург-травматолог Александр Теплов, Әфганстаннан Бурденко исемендәге госпитальгә әйләнеп кайтканнан соң, травматология бүлегенең өлкән ординаторыннан госпитальнең травматология һәм ортопедия үзәгендәге бүлекләрнең берсенең башлыгына кадәр хезмәт баскычы уза.

– КӨЙЛӘНГӘН, ТӨГӘЛ ЭШЛИ ТОРГАН СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ СИСТЕМАСЫ СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ ТӨП, БӘХӘССЕЗ КАЗАНЫШЛАРЫННАН БЕРСЕ, – ДИП СӨЙЛИ РФ ҺӘМ ТРНЫҢ АТКАЗАНГАН ТАБИБЫ РОСТИСЛАВ ТУИШЕВ. – Ул елларда алдынгы, заманча җиһазларның булмавы, күп кенә препаратларның, шул исәптән авыртуны баса торганнарының да, җитмәве – болар барысы да табибларның компетентлыгы, тәҗрибәсе, аларның уйлый, үзара хезмәттәшлек итә белүе белән компенсацияләнә иде.

* «Әфган җиле» җырыннан.

«КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ...»*

– 1976 елда, армия сафларына чакырылыр алдыннан, медицина тикшерүе узу өчен төрле белгечләргә күренергә кирәк иде. Мәҗбүри тикшерүләр арасында, әлбәттә, стоматология кабинеты аша да узасы бар, – дип сөйли Әсгать Сафиуллин. – Авызымны ачуга, стоматологның соравын ишеттем: «Кайсы мәктәптә укыдың? Бишенче? Ә-әә-ә, аңлашылды...»

Күрәсең, мәктәп теш табибының «профессиональ имзасы» шулкадәр аерылып торган, хәрби комиссариаттагы коллегасы аны шундук танып алган. Хәер, бу гомумән мәктәп теш табибларына хас күренеш булгандыр, мөгаен.

Чыннан да, Советлар Союзының барлык мәктәпләрендә теш табибы кабинеты булган. Тешләре белән интеккәннәргә анда әллә ничә мәртәбә керергә туры килгән. Ә инде теше «тишек»сез, авыртмаган-сызламаган бәхетлеләр бик сирәк очраган. Беренчеләр икенчеләреннән ак көнләшү белән көнләшкән. Чыннан да, ул елларда стоматология кабинеты аша үткәннәр – героик, «какшамас сугышчан рухка» ия һәм батыр йөрәкле кешеләр. Бер сүз белән әйткәндә, чын совет кешеләре.

Бормашинаның тавышы ук йөрәктә шомкурку уята, бигрәк тә балаларда. Аның тавышы мәктәп коридорында ук ишетелә. Ә теш кабинетына совет балалары котлары очып керә. Монда исә бормашина тавышыннан куркуга төрле исләр катнашмасы өстәлә – канәфер мае, йодоформ һәм тагын әллә ниндиләр стоматология «химиясе» исләре.

Ихтимал, стоматологларның үзләренә дә мондый «газаплау эшләре» ошап бетмәгәндер, чөнки алар моны бик тиз эшли иде. Урт тешләрен суырып алу өчен новокаин кадыйлар, сөт тешләрен исә бернинди даруларсыз, тартып кына алалар. Теш эчендә нәрсә булганны күрмичә, аны тулысынча диярлек бораулап бетерәләр. Черек тешләрне дәвалаганда, озак уйлап тормыйча, ике тешкә бер пломба куярга мөмкиннәр. Тешләрнең хәрәкәтчәнлеге? Бу турында ишеткәннәре дә юк. Әлбәттә, бер-ике айдан цемент төсендәге ямау кубып, коелып та бетә.

Теш куйдыру шулай ук төрлелеге белән аерылып тормый. Бер яисә берничә тешне алыштырыргамы? Тимер коронкалар. Тешләр бөтенләй юкмы? Рәхим ит – протез!

Алтын яисә алтын йөгертелгән металлдан коронкалар – аерым тема. Инде 1960 нчы елларда ук металл керамикасыннан теш куела торган чит илләрдә безнең ватандашларны шул исәптән ялтырап торган алтын тешләреннән дә таныганнар, дип сөйлиләр.

Түләүсез совет стоматологиясе хезмәте коточкыч, ләкин бөтен кеше өчен тигез була. Ә инде сыйфатлырак дәва алырга теләүчеләр шәхси дантистларга мөрәҗәгать итә. Аларның айлык кереме мең сумнар белән исәпләнә, әмма бу турында күп сөйләп йөрмиләр.

Әлеге бизнес бик табышлы, ләкин закон буенча тыелган була. Ә хезмәттән тыш керем өчен шактый зур срок та чәпи алганнар. Т



* «Кыңгыраулы мәктәп еллары» җырыннан. Рим Хәсәнов музыкасы, Шәүкәт Галиев сүзләре.

«ТОЗЛЫЙМ КЫЯР, КАКЛЫЙМ КАЗ...»*

Роза Хөснетдинова, бүген АКШ гражданкасы:
– Балачактан исемдә калган: өстәлдә – бер литрлы банка белән кара уылдык. Өйдәгеләр аны аш кашыгы белән алып, май сыланган ипи телеменә калын итеп ягып ашый...

Уылдыкны башта дәү әни белән дәү әти, соңрак әни белән әти Әстерханнан, Идел буенча сәяхәттән алып кайталар. Әстерхан базарында ул тулып ята, сату итүне тыючы юк. Без ашаган уылдык өйдә ясалган һәм, әлбәттә, заводта чыгарылганына караганда күпкә арзанрак, ләкин уртак фикеребез буенча күпкә тәмлерәк тә. Уылдыкны Казанда да сатып алып була – аны «заказ» буенча, навигация чоры дәвамында алып кайтып торалар.

Ә менә алтмышынчы елларда заводта ясалган кара уылдыкка ихтыяҗ зур булмый. Аның килограммы 400 сумнан алып (алтмышынчы еллар башында) уналты сумга кадәр (алтмышынчы еллар ахырына) тора. 60-100 сум хезмәт хакы алганнар өчен кыйммәтрәк. Әмма берәр чәркә коньяк астына утыз тиенлек кара уылдыклы бутербродны һәркем тәмләп карый ала, чөнки ул теләсә кайсы театр буфетында стандарт, гадәти кабымлык санала. Кайнар ысул белән ысланган мәрсин балыгы кабымлыгы белән дә шул ук хәл.

Мәрсин балыгын балык кибетләрендә һәм базарларда иркен саталар. Мәрсин балыгыннан уханы һәрвакыт Казан рестораннарында бирәләр. Ул көндәлек ризык саналмаса да, хакы сатып ала алырлык. Ә менә чөгә балыгын һәрвакыт Свияжскидан Кама Тамагына һәм Лаештан Красный Ключка кадәр – Идел яисә Чулман яры буенда урнашкан теләсә кайсы авыл балыкчысыннан арзан бәягә генә сатып алып була. Судак, корбан яисә чуртан балыгы турында әйтеп тә торасы юк – алар һәрвакыт мулдан.

Шулай да СССРда 60-70 нче елларда иң арзаны, минемчә, диңгез продуктлары һәм диңгез балыгы булгандыр. Камбала, кальмарларны аена 20-30 сум пенсия алып яшәгән авыл әби-бабайларының да, үз акчаларын тулысы белән диярлек хәмергә сарыф итәргә күнеккән сәрхүшләрнең дә сатып алырга мөмкинлеге бар. Тиен генә торган диңгез кысласын һәрвакыт ярлы студентлар яратып ала – сыра белән яхшы бара. Минтай һәм вак балыкларны хуҗабикәләр песиләренә сатып ала. Һәм алар барысы да кибетләрдә иркен сатыла.

Алтмышынчы еллар азагында кибет киштәләрен моңарчы күрелмәгән «простипома» дигән диңгез балыгы белән тутыралар. Халыкта шунда ук: «Яхшы балыкны простипома дип атамаслар», – дигән мәзәк тә йөри башлый. Әмма балык бөтен кешегә ошый. Сусыл, майлы, бәясе дә кыйбат түгел. Аны бик яратып ашыйлар. Ә бүген ул балык кайда? Кайнар ысул белән ыслана торган «нототения» балыгы да юкка чыкты. Шулай ук халык яратып ашый торган балык иде.

Бездә тагын дөньяның бер генә илендә дә сатылмаган арзанлы ризыклар күп иде. Бала чакта вак-төяккә дип бирелгән унбишегерме тиенгә үзебезнең тәм-томнарны рәхәтләнеп сатып алып була. Катырылган какао шакмаклары бик ошый – рәхәтләнеп кимерә идек. Даруханәләрдә гел сатыла торган өч тиенлек гематоген, ул кыйммәтле конфетлардан бер дә ким түгел. Шикәр комыннан ясалган «помадка» – шикәр конфет – аны кибеттән дә сатып алып була, әниләр, керосинкага куеп, үзләре дә кайната.

Совет үткәнен хәтерләткән иң шәп продуктлар арасында бүген, мөгаен, куас кына калгандыр. Хәер, анысының да тәме үзгә инде. Ә тегесе – безнең бала чактагысыннан чыннан да хуш ис, икмәк исе килеп тора иде. Стаканын – өч тиенгә, кружкасын алты тиенгә алып, туйганчы эчәргә була иде.

* «Ярап булмый хатынга» җырыннан. Ренат Еникиев музыкасы. Махмут Хөсәен сүзләре.

«НИК АК БУЛА ИКӘН ТАШ ПУЛАТ, МАЛЛАР КЫЙБАТ ТҮГЕЛ, БАШ КЫЙБАТ»*

Казанның Вишневский урамында яшәүче калын гәүдәле, каты холыклы Хәдичә апаны ярты шәһәр белә. Кемнәрдер аңа табына. Икенчеләре астыртын гына күралмый. Хәдичә апада кибеттә булмаганны табып була. Хатын-кыз фин итекләре, чех туфлиләре, Австрия пальтолары, төрек кайры туннары, Польшада тегелгән костюмнар, чәшке мехыннан башлыклар... – бөтен нәрсәне! Һәм боларның барысын да ул өеннән сатып ята. Дөрес, аның биек койма артына посып утырган ныклы агач йортына урамнан гына, туп-туры әләгү мөмкин түгел. Моның өчен яхшы танышлык һәм җитди кешеләрнең үтемле сүзе кирәк.

Хәтта дошманнарының да Хәдичә апаны спекулянт дип атарга теле әйләнми. Спекулянтлар, милициядән куркып, базарның аулаграк урыннарында кача-поса, кулларына очраклы рәвештә эләккән товарны сата. Ә Хәдичә апа базарга яңа сауган сөткә дип кенә йөри. Дефицит товарны аның өенә капларга тутырып алып киләләр. Даими сатып алучылар арасында бик җаваплы иптәшләр дә бар. Хәдичә апа җитди элемтәләре булган ханым иде шул.

Бервакыт аның ишеген шакыйлар. Килешенгәнчә шартлы «өч озын – ике кыска шакылдату» түгел – шактый каты, таләпчән шакылдату була ул. Капка ярыгыннан күрсәтелгән ОБХСС таныклыгы куркытмый Хәдичә апаны. Ул капкасын ачып, килгән иптәшләрне кертә. Кыядай нык Хәдичә апа үзенең шкаф, тумбочка һәм сандыкларында актарынганнарын тыныч кына күзәтеп, анда нәрсәләр ятканын аңлатып тора. Аннан соң килүчеләргә ияреп, тыныч кына машинага кереп утыра да сак астында «Черек күлгә» китә.

Тикшерүче сорау алырга чакырганда да ул үзен нык, тыныч тота, әйтерсең лә бернәрсә дә булмаган. Тикшерүче кәгазь капларда аңа дефицит товар җибәреп яткан зур кешеләрнең исемнәрен атавын сораганда бары тик көлемсерәп кенә куя. Зур кешеләрнең тиздән шалтыратачакларына, шуннан соң үзен кайтарып җибәрәчәкләренә ышана ул.

Вакыт бара. Хәдичә апаны җибәрмиләр. Тикшерү дәвам итә. Алай гына да түгел, берничә атнадан камерага аның ирен кертәләр. Тимер ишекләр шапылдап ябылуга, ире усал итеп:

– Нәрсә, тыгынып туйдыңмы инде хәзер? – ди.

– Ярар инде, – дип кулын гына селти Хәдичә апа. – Мунча астында безнең ике гомергә җитәрлек бар әле!

Шул ук кичне оперативниклар мунча астыннан бер чиләк алтын казып чыгара...

Тикшерүче кабинетында Хәдичә апа инде, сабырлыгын җуеп, вулкандай кайный. Исемнәрне атамый, әмма яный:

– Чыгармасагыз, судта барысын да сөйләп бирәм. Күрмәгәннәрен күрсәтәм...

Аны чыгармыйлар. Хәер, күрәсең, кемдер шалтыраткандыр: Хәдичә апаны тиз арада төрмә хастаханәсенә алып китәләр.

Төрмә хирургы ясаган операция гади генә була анысы – бүсергә. Ә аннан соң кемдер палатадагы форточканы ябарга оныткан, дип сөйлиләр...

Судта барысын да сөйләрлек кеше калмый инде.

* «Казан сөлгесе» җырыннан Татар халык җыры.

«АВЫРЛЫКЛАРГА ТҮЗӘРБЕЗ, БЕЗ ЯУЛЫЙБЫЗ ЯҢАНЫ»*

1963 ел. Мәскәү дәүләт университеты студентларының чирәм җирләрне үзләштерүдә ярдәм итү өчен махсус төзелеш отряды булдыру идеясен Татарстан да күтәреп ала һәм Казан инженер-төзелеш институтыннан ике йөз студент Казахстан далаларына юл тота. Беркемне дә үгетләргә туры килми – җитештерү алдынгыларының батырлыгы яшьләр өчен иң шәп илһам-көч чыганагы булып тора.

Беренче ел ук шуны раслый: чирәм җирләрдә эшләү өчен төзелеш өлкәсендә махсус белем мәҗбүри түгел икән. Һәм махсус отряд сафына башка югары уку йортлары – КДУ, КАИ, медицина институты студентлары кушыла. Иң мөһиме – куркынычсызлык техникасы һәм төп төзелеш белгечлекләре буенча тизләтелгән әзерлек курсын узу. Әлбәттә, укуга бәйле таләп тә куела – имтиханнарда бернинди койрык та булмаска тиеш! Шулай итеп студентлар төзелеш отрядларына иң яхшылар – романтик-энтузиастлар җыела.

Татарстанның әлеге җыелма студентлар отряды командиры итеп Анатолий Котвицкий билгеләнә. Бик зур җаваплылык! Һәрнәрсәне бөтен вак-төягенә кадәр уйлап бетерергә кирәк була. Эш урынына студентлар «армия»се килгәнче үк барып, Котвицкий проблемаларның муеннан икәнен аңлый. Иң мөһиме – эшләргә бернинди эш коралы да, бернәрсә дә юк. Коралларны, бәлки, барысына да җиткереп тә булыр, ә транспорт бөтенләй баш бәласе.

Өйгә кайткач, ул киң колачлы әзерлек эшләре оештыра. Татарстанның төзелеш оешмалары белән килешәләр, алар отряд «сугышчы»ларына эш кораллары һәм перчаткалар бирә. Эш киеме тектерәләр. Транспорт мәсьәләсен бөтенләй катлаулы юл белән хәл итәләр: Котвицкий ватылган машиналарны ремонтларга тәкъдим итә. Һәм ремонтлап чыгалар да! Ә шуларга өстәп, машина йөртү хокукы булган 40 студент та табалар. Котвицкий хәтта Казаннан автокран да алып килә! Нәтиҗәдә, егетләр һәм кызлар Казахстанның чирәм җирләрен яуларга кирәгенчә коралланып бара.

Ә энтузиазм һәм студентларга хас дәртлелек анда бик ярап куя. Ул вакытта биналарны бут ташыннан, нигездә, кул көче белән төзиләр. Бу ташны исә карьердан чыгаралар, анда да кул белән эшлиләр. Казу эшләре дә кул көче белән башкарыла! Тик ике ай да узмый, чирәм җирләр урынында берничә торак йорт, авыл хуҗалыгы техникасы өчен остаханә, җылылык үзәге, сыер абзарлары һәм хәтта балалар комбинаты да үсеп чыга. Яңа урамны Казан урамы дип атарга карар кылалар. Яшь төзүчеләр хөрмәтенә.

1965 елда Казан төзелеш отряды югары бүләккә лаек була – аңа ВЛКСМ Үзәк Комитетының Кызыл Байрагы күчә. Бу бик зур җиңү була – Союз байрагы автономияле республикага китеп бара!

* «Тургайлар килде», Галимҗан Латыйп сүзләре.

«КЫРЫС ДАЛА СӨРҮЧЕ, ЯҢА КАЛА ТӨЗҮЧЕ ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР КЕМ СОҢ УЛ?»*

«Иң яхшысы – юлга спорт костюмы кию һәм берничә «ковбой» күлмәге алу. Чирәм җирләрдә итек һәм ботинкасыз булмый, әмма башмак та алырга кирәк. Комбайнда да, ындыр табагында да, ашлык чыгаруда да башмак киеп эшләү уңайлы. Ә тагын үзең белән матрас тышлыклары алырга кирәк. Шуларга яңа чабылган печән тутырасың да ястыкка яткандай рәхәтләнеп йоклыйсың. Һәм тагын туп, волейбол сеткасы, аккордеон, гитара, балалайка, берәр гади радиоалгыч та эләктерергә онытмаска кирәк, чөнки газеталар кайвакыт соңарып килә».

Казан университетында чыгарылган «Ленинец» газетасы чирәм җирләргә барачак студентларга әнә шундый киңәшләр бастырып чыгара. Моннан аңлашылганча, төзелеш отрядлары сугышчыларын авыр эшләр көткәнлеге бер хәл, әле шактый катлаулы шартларда да яшәргә туры киләчәк икән. «Көнкүреш мәсьәләләрен үзегез хәл итегез!» – дәүләт тарафыннан студентлар хәрәкәтенә мөнәсәбәт әнә шундый була. Югыйсә республика отряды төзелеш-монтаж эшләрен, мәсәлән, беренче (югары) категорияле төзелеш тресты күләмендә башкара. Өстәвенә, трест бу эшләрне бер ел дәвамында, ә егетләр ике ай эчендә эшләп чыга иде, дип искә ала өлкә студентлар төзелеш отрядының 1974–1976 еллардагы командиры Владимир Соколов.

1970 елда Татарстан студентлары Себерне яуларга юл тота. Томск өлкәсенең төньягындагы Стрежевой шәһәрчегендә шартлар күпләрне аяктан егарлык була. Тирә-якта сазлыклар, дымлылык бик зур, кигәвене, вак чебене, черкие җанга тия! Кайвакыт билдән сазда эшләргә туры килә. Чып-чын каторга – башка сүз юк! Шул ук вакытта бу отрядка эләгү бер дә җиңел булмый. Конкурс – бер урынга җиде кеше! Аңлагансыздыр, прагматиклар анда озак тоткарланмый.

Яңа эш көнен бөтен ихтыяр көчен җыеп башлап җибәрә идек, дип искә ала «БКД-Север» махсус төзелеш отряды вәкиле, ә аннары 1970 елда Кама аръягы зона студентлар төзелеш отрядының беренче комиссары Валерий Герасимов. Әмма төнлә дә уятырга мөмкиннәр – баржа бушатырга кирәк. Табигате һәм климат шартлары белән ерак Себергә тиңләшә алырлык Стрежевойга ул вакытта бөтен нәрсә җәен баржа белән китерелә. Шул исәптән спиртлы эчемлекләр дә. Шуңа күрә җирле халыкны бушату эшенә җәлеп итү куркыныч була. Баржалар төнлә бушатыла. Җирле халык йоклый, ә студентлар эшли.

* «Комсомол» җырынан. З. Гыйбадуллин музыкасы. Ф. Сафин сүзләре.

ТАТАР ОЛИМПЫ АКСАКАЛЫ

Ярты гасыр буе республика җитәкчелегендә. Салих Батыевның тормыш юлы Совет Татарстаны тарихының зур өлешен колачлый.

Автор:
Нияз Әхмәдуллин

Инкыйлаб чорындагы тетрәнүләр һәм күмәкләшү, Сталин репрессияләре һәм Хрущев «җепшеклеге», татар теле өчен көрәш һәм «милләтчелек» дип исемләнгән нәрсәгә каршы көрәш, Брежневның торгынлык еллары һәм Горбачев үзгәртеп коруларының башлангыч этабы. Җитәкчелектә илле ел – ике төкереп бер сикерү генә түгел, шуңа күрә әлеге сәясәт аксакалының язмышында ил тарихының төрле чорлары чагылыш тапканлыгы аңлашыла – агы да, карасы да, кайгылысы да, шатлыклысы да...

1911 елда Башкортостанда туган һәм рәсми рәвештә башкорт милләтеннән булган Салих Батыев гомере буе Татарстанда эшли һәм сүздә генә түгел, документларда да татарга әйләнә – паспортта милләтен алыштыра. Партия, комсомол һәм дәүләт җитәкчелегендәге төрле югары вазыйфаларда Батыев, гомумән алганда, 50 ел эшли.

1931 елда Казанга килеп, ул финанс-икътисад институтына укырга керә, ләкин аңа укуын тәмамларга ирек бирмиләр. Авылны механикалаштыруның иң алгы фронтына – Акташ МТСының сәяси бүлегенә җибәрәләр. Тиздән ул республиканың Арча районында комсомол җитәкчесе итеп куела, ә 1936 елда актив егетне комсомол өлкә комитетының оештыру бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Бу инде булачак карьера үсешенә җитди адым дигән сүз, югарыга менү өчен юл шуннан ачыла. Һәм Батыев та, төрлечә инициатива белдереп, үзенең оештыру талантын күрсәтә-күрсәтә, булдыра алганча тырыша.

Урамда 1937 ел. Илдә массакүләм репрессияләр бара, йөзләгән-меңләгән «халык дошманы» фаш ителә. Батыев та, гомуми агымга ияреп (ә аның вазыйфасында башкача ярамый да), «дошманнар»ны эзли һәм фаш итә, җыелышларда һәм митингларда чыгыш ясый, «сатлыкҗаннар һәм шпионнар»ның гөнаһларын ачып күрсәткән коллектив мәкаләләр, хатлар язуны оештыра.

Кинәт (бәлки, шулай тиеш булгандыр да) язмыш таягының башка очы үз «сыртына төшә»: 1937 елда аның өстеннән шикаять килә. Салих Батыевны партия өлкә комитетына чакыралар һәм берничә кәгазь күрсәтәләр. «Бу материал синең хакта, халык дошманнары белән элемтәңне ачыклаячакбыз. Әгәр син дошманнарның зур эшләренә катнашмыйча, уяулыгыңны киметкән генә булсаң, ярый да...», – дип белдерәләр аңа. Баксаң, кулга алынган берничә «халык дошманы» үз күрсәтмәләрендә шуны хәбәр иткән икән: аларның юлдашы – партиядән чыгарылган Еникеев («Кызыл Татарстан» республика газетасының элекке баш мөхәррире) – Батыевның дусты, һәм алар, әле туганнар да буларак, «тыгыз элемтәдә торган».

Аннары Батыевны комсомол өлкә комитетындагы эшеннән чыгаралар. Шул көннән башлап Батыев үзен кулга алганнарын көтә, тик... юкка. 1937 елның ноябрендә аны партиядән чыгаралар, партия билетын алалар. «Болай булгач, беттем», – дип уйлый Батыев. Тагын кулга алырга килмиләр. Бу еллар өчен сирәк могҗиза – ул иректә кала. Әмма хәвефле хәбәрне көтү дә искиткеч авыр. Ишек каккаиннарын көтеп, төннәрен ничек үткәргәнен күз алдына китерүе дә кыен.

Соңрак Батыев төрмә газапларыннан үзенең котылып калуын: «Бәлки, республикада кулга алулар буенча план үтәлгәндер, шуңа күрә мине

алып китмәгәннәрдер», – дип аңлата. Шул ук вакытта ул көн саен өлкә комитетына барып йөри һәм үзенең гаепсезлеге турында гаризалар яза. Һәм кинәт 1938 елның 25 гыйнварында, аның чираттагы гаризасын караганнан соң, Татарстан АССР буенча ВКП (б) ҮК каршындагы Партия контроле комиссиясе партколлегиясендә «Батыев Салих Гыйлемхан улының ВКП (б) әгъзалыгын кайтарырга» булалар, шул ук вакытта аның большевик сизгерлеген югалтканын да искә алалар. Шунда ук комиссия: «Шелтә белдерергә һәм моны шәхси исәп карточкасына теркәп куярга», – дигән карар да чыгара. Шул рәвешле ул бәхетле язмыш билетын тартып чыгара һәм киләчәктә гыйнварның бу көнен беркайчан да онытмый, ел саен аны икенче туган көне буларак билгеләп үтә. Бу көнне Салих Батыев аеруча киң күңелле була. Моны белүчеләр еш кына әлеге киң күңеллелектән файдаланып калырга тырыша.

Ә аннары исә кичерелгән Батыев хезмәт баскычы буйлап югары менә башлый, дөрес, шунда ук түгел, күпмедер вакыт ул «күзгә бәрелеп тормаган» вазыйфалар белән канәгатьләнә. Репрессияләр бик күп вакантлы вазыйфалар барлыкка килүгә китерә.

1943 елда, 32 яшендә, ул – ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары. 1950 елда Батыев, ниһаять, югары белем ала һәм берничә ел Мәскәүдә партия ҮК инструкторы булып эшли. Аннары Казанга әйләнеп кайта һәм идеология буенча секретарь, партиянең Татарстан өлкә комитетына икенче секретарь итеп билгеләнә. 1960 елда хәтта «беренче» вазыйфасына дәгъва кыла, ләкин барып чыкмый.

Шул ук елны Батыев ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе итеп сайлана. Моның өчен аңа рәсми рәвештә «татар»га әйләнергә туры килә.

Биредә ул 1983 елның җәенә кадәр – 23 ел эшли. Республикада кайберәүләр шаяртып «батыевчылык» дип атаган тулы бер чор бу.

ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе – асылда да, Конституция буенча да – республикада иң югары дәүләт вазыйфасы. Сүз уңаеннан, Батыев кайвакыт үзен «безнең президент» дип атаганнарын яраткан. Әмма хакимиятнең чын куәте, әлбәттә, партия өлкә комитеты кулында була. Шуңа да карамастан, Батыев бу вазыйфасында кул кушырып утырмый. Аның абруе закон чыгару органының да авторитетын саклап калырга ярдәм итә. Республиканың авыл районнары башкарма комитетлары рәисләре Батыевка ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә мөмкин икәнлеген һәрвакыт белеп тора: аларны еш кына партия район комитетларының артык бәйләнчек секретарьларыннан якларга туры килә.

1956 елда ул ТАССРда һәм күрше республикаларда реабилитация буенча СССР Югары Советы комиссиясе рәисе итеп билгеләнә. Бу елларда да, соңрак та Батыев законсыз репрессияләнүчеләрне аклау белән актив шөгыльләнә, аларның эшләрен игътибар белән өйрәнә, илнең иң югары инстанцияләренә тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итә. Лагерьлардан кайткан сәяси тоткыннарга ярдәм итәргә тырыша. Ул Муса Җәлилнең исемен аклауда мөһим роль уйный. Шәхсән Мәскәүгә шалтыратып, документларның тикшерелүен тизләтүне сорый. 1937 елда кичергәннәрен ул беркайчан да хәтереннән чыгармый, репрессия корбаннарының намуслы исемнәрен кире кайтаруда актив катнашып, Батыев, һичшиксез, гаепнең үзенә туры килгән өлешен юарга тырыша.

Ул җитмеш яшьтән узгач кына пенсиягә чыга. Ә ике елдан соң, 1985 елның декабрендә, бакыйлыкка да күчә. 2021 елның ноябрендә Салих Батыевка 110 яшь тулган булыр иде.

УСПЕШНО ПРЕТВОРИМ В ЖИЗНЬ
РЕШЕНИЯ XXV СЪЕЗДА КПСС!
ПОВЫШАЙ
ЭФФЕКТИВНОСТЬ
ПРОИЗВОДСТВА!
БОЛЬШЕ ПРОДУКЦИИ
ВЫСШЕГО КАЧЕСТВА!
РЕЗЕРВЫ-В ДЕЙСТВИЕ!

«ГАСЫРЛАРНЫ ЕЛДА ҮТӘБЕЗ...»*

СССР инде күптән юк. Ләкин Совет иленнән мирас булып калган шактый нәрсәләр бүген дә кулланыла, үсә, файда китерүен, шатландыруын яисә көендерүен дәвам итә. «Союзларны» – галәмгә, стратегик Ту-160 очкычларын һавага күтәрү идеяләре... Авырлыкларны җиңү аша казанышларга ирешә алу сәләтебез... Килбәтсез «хрущёвкалар» һәм архитектура җәүһәрләре... Уртак казанышлар өчен риясыз тырышлык, энтузиазм һәм башкаларның уңышына карата көнчел битарафлык... Болар барысы да шул заманнан – СССР дип аталган бөек илдән килә.

* *«Кандыр буе» пьесасы, «Без кабызган утлар» җырыннан. Салих Сәйдәшев музыкасы. Кәрим Тинчурин сүзләре.*

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ГӨЛНАРА ГАБДРАХМАНОВАДАН ЯҢА ЕЛ ПИЛМӘНЕ

Автор: Татьяна Вафина

Мандарин исе килә, кибетләрдә ыгы-зыгы: халык гипермаркетлардан ясалма чыршы ташый, бүләк сайлый, күпләп азык-төлек сатып ала, хуҗабикәләр бәйрәм табынына куясы сый-нигъмәтләрен барлый... Шулай булган һәм булачак! Бәйрәм алдыннан гомер-гомергә шулай мәш килгәннәр. Ә иң хәтердә калганы – совет чоры, ул чакта да Яңа ел алды кәефе шундый ук көчле, тик менә сатып аласы әйберләргә кытлык иде – дефицит товар йә әшнәләр аша табыла, йә күпчакрымлы чиратта торганнан соң гына бәхет елмая, яисә поезд белән барып Мәскәүдән кадәр алып кайтасы була. Әмма совет кытлыгы китереп чыгарган шундый киртәләргә карамастан, һәр гаиләдә Яңа ел табыны тансык сый-нигъмәттән сыгылып тора. Без аларның һәркайсын хәзер дә исемләп санап чыга алабыз: оливье, «шуба», пилмән, шпротлы бутерброд һәм совет кинематографы данлыклаган дерелдәвекле балык... Совет чоры табыны турында Яңа ел алды хатирәләрен кем белән барлау яхшырак икән? Әлбәттә инде, Архив эше буенча ТР дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова белән. Аның «архивында» мондый хатирәләр байтак.

Фото: Александр Ефремов

«АРХИВ КҮСЕЛӘРЕ» ҺӘМ «АССОРТИ»

– Бик тиздән өлкәннәр дә, балалар да зарыгып көтеп алган Яңа ел бәйрәме җитәчәк.

2022 елны без яхшы кәеф белән каршылыйбыз. Татарстан архивчылары инде 100 елдан артык күпмиллионлы архив байлыгын саклау буенча үзләренең һөнәри бурычын фидакарьлек белән башкара.

Архивчылар командасы тырышып эшләп кенә калмый, күңелле ял да итә белә. Совет чорындагы Яңа ел каршылаулар хакында кызыклы тарихларны шактый беләм мин. Ул чакта хезмәткәрләр КВНнар, «Йәгез әле,

1
– Оливьены ирем дә, балалар да ярата. Без аны болай да еш әзерлибез, ә менә Яңа ел бәйрәмендә ул туплау вазыйфасын үти – барыбызны да бер үк вакытта бер табын тирәли җыя.

кызлар!» бәйгеләре үткәргән. Мәсәлән, бервакыт КВНда «Архив күселәре» (исәп-хисап бүлеге кызлары) һәм «Ассорти» (башка бүлекләрнең җыелма командасы) уйнаган. Конкурсларда һөнәри күнекмәләрне, импровизацияләү осталыгын күрсәтү соралган. Яңа елга һәр бүлек үзенең оливье салатын әзерләгән. Шпротлы бутербродлар ясаганнар, үзләре тозлаган кыяр-кәбестә алып килгәннәр...

ПИЛМӘННЕ ГАИЛӘ БЕЛӘН БӨГӘ ИДЕК

Болар барысы да таныш һәм күңелгә бик якын. Минем балачагымда, безнең совет гаиләсендә, Яңа елны шулай ук күңелле каршылый идек. Һәрвакыт бик күп кунак җыела. Үзебезнең кая да булса баруыбызны хәтерләмим, бөтенесе безгә килә иде. Минем әти-әнием бик кунакчыл кешеләр. Бәйрәм табынындагы сый-хөрмәт исә – аларның гаять зур хезмәт җимеше. Без бик күп тавык, сарык, бозау асрый идек. Бакчабызда исә нинди генә яшелчә һәм җиләк-җимеш үстермәдек!

Мин бик күп кунаксыз бер генә бәйрәмне дә хәтерләмим. Без өч бала үстек: мин – иң өлкәне һәм Олег, Эдик исемле энеләрем. Гел бик күп ризык әзерләргә, энигә булышырга туры килә иде. Яңа елны иң күркәм бәйрәм итеп үткәрү традициясен исә этиемнең энисе Мәйшәрәф әбием керткән. Мин аны бик-бик яраттым. Әбием 84 ел яшәде. Аның бөтен гомере безне кайгыртуга багышланган иде. Аның сөйләгәннәрен әле дә хәтерлим – элек Яңа елдан кала бер бәйрәмне дә белмәгән алар, шуңа һәр елны бик зурлап әзерләнгәннәр. Без әнә шул традицияләрдә тәрбияләндек. Минем әнием – рус, әтием – татар. Шунлыктан Яңа ел табынында нигъмәтләр хәзер дә «күпмилләтле» булып кала. Анда һичшиксез пилмән булырга тиеш – без аны гаиләбез белән бергәләп, рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә бөгәбез. Бүген исә безнең пилмән поши итеннән булачак, чөнки минем ирем дә, улларым да, алар белән мин дә – барыбыз да аучы. Миңа ауга әзерләнү, җыену, барыбыз бергә урманда йөрү бик ошый...

ОЛИВЬЕ – МӘҖБҮРИ!

– Ә оливье салаты?

– Анысы – һичшиксез булырга тиеш! Бу салатны ирем дә, балалар да ярата. Без аны болай да еш әзерлибез, ә менә Яңа ел бәйрәмендә ул туплау вазыйфасын үти – барыбызны да бер үк вакытта бер табын тирәли җыя. Безнең оливье бик тәмле булып чыга, чөнки аңа кирәкле бөтен нәрсә – бәрәңгесе дә, йомыркасы да, суганы да, кишере дә, кыяры да – сатып алынган түгел, ә үзебезнеке.

ҮРДӘК КЫЙССАСЫ

1984 елдан бирле Яңа ел табыныбызда һәрвакыт үрдәк була. Ул чакта без Сабада яшәдек, әни үрдәкләр асрады, шунлыктан Яңа ел табыныбыз алма, курагә һәм мандарин тутырып пешерелгән үрдәксез була да алмый иде! Алма да үзебезнеке – әнием алма бакчасын да үзе үстерде. Аның туган җирендә. Алексеевскоеда, бабамның бик зур алма бакчасы булган. Кызганыч ки, 1973 елгы каты суыкта алмагачлар туңган. Бабам сугышта катнашкан, күп үлем күргән кеше, әмма шулай да алма бакчасы өчен йөрәге бик әрнегән. Соңрак без, оныклары, алмагачларны кабат утырттык. Бабамның оныклары исә бик күп – 24 кеше, аларның балалары исә тагын да күбрәк... Без ярты җәйне бабамда, Чулман ярында, икенче яртысын Сабада, әбием янында үткәрә идек. Шунлыктан минем балачагым бик бәхетле булды. Хәер, барлык совет чоры балаларыныкы да шундый сөенечле иде ул.

КАБАТ СССРГАМЫ?

Үткәннәргә әйләнеп карап, шуны гына әйтә алам: Советлар Союзында бер генә кимчелек бар иде – кибет киштәләренең бушлыгы. Хәтерлим, әтием мине база һәм ярминкәләргә гел утыртып йөрде, мин аның «УАЗ» машинасында үстем, дияргә дә була. Ул һәрвакыт Саба кибетләренә ашамлыклар, хуҗалык товарлары кайтартуны кайгыртты.

Минем СССР турында бер генә начар хатирәм дә юк. Минем өчен Советлар Союзы ул – киләчәк бүгенгегә караганда да яхшырак булачак, дип инану. Бүген исә киләчәктә мондый ышаныч юк. Җитмәсә әле пандемия дә хафаландыра...

Юк, мин әлеге сәяси стройның кире кайтуын теләмәс идем. Тарихның һәр чорына үз вакыты бирелгән. Ул чакта яхшы булган нәрсә хәзер исә начар булырга мөмкин. Моны хәтта безнең архив эшендә дә күреп була. Совет чорында, мәсәлән, мәгълүмат хезмәтендә документларны идеология максатларында файдалануга басым ясалды: документаль экспозицияләр, архив документлары буенча радио- һәм телетапшырулар оештыру, фәнни-популяр һәм фәнни материаллар бастыру – болар барысы да социалистик төзелеш казанышларын мактауга юнәлтелгән иде. Күргәзмәләр КПССның Татарстан өлкә комитетының Сәяси агарту йортында, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Казан университетының тарих музеенда үткәрелде. Күчергеч техника булмаганга, экспозицияләргә чын документлар куела иде.

Бүген исә архив эшчәнлеген цифрлаштыру күргәзмәләр үткәрү форматын киңәйтү мөмкинлеген бирә. Мультимедиа һәм интернет-күргәзмәләр белән дә кызыксыну зур. Уку залындагы документлар белән еракtan торып танышу мөмкинлеге бар – бу да алга таба зур адым.

Барлык бу глобаль, һөнәри үзгәрешләр әлбәттә бик шәп. Мин аларны хуплыйм. Әмма СССРда нәрсә яхшы булды дигән сорауга әйләнеп кайтсак, утыз ел стажлы педагог буларак миңа шунысы бик кызганыч: ул чакта без идеология белән бергә балаларны да – октябрят, пионер, комсомолларны югалттык. Без аларга алмаш таба алмадык. Һәм әлеге аралыкта югалган буын үсеп җитте. Ә менә хәзер инде аларның балалары мәктәпкә укырга керде. Нәтиҗәдә без нәрсә күрәбез соң? Нигә бүген бөтен кеше мәктәптән зарлана? Чөнки бүгенге мәктәп балаларының да, аларның ата-анасының да идеологиясе юк. Алар нишләгәннәрен үзләре дә белми: укытучыны мәсхәрәләргә, мәктәпкә килеп тавыш куптарырга мөмкин, дип саныйлар – элегрәк исә бу рөхсәт ителмәде. Без зыялырак балалар идек, ничек тә яхшы белем алырга тырыштык. Гәрчә безнең мөмкинлекләребез хәзергегә караганда күпкә азрак иде – халыкара конкурслар да, грантлар да булмады. Совет чоры баласы бары тик үзенең белеменә генә таяна алды. Ә хәзер студентларга игътибар нинди! Мин архивка эшкә килгәндә, анда ун практикант бар иде, хәзер исә 428 студент бездә практика үтә: КДУның Тарих институтыннан, энергоуниверситеттан, мәдәният институтыннан, төзелеш колледжыннан... Алар документларны өйрәнә, фәнни-тикшеренү эшләре яза. Иң яхшы хезмәтләр өчен стипендия билгеләнә. Безнең вакытта мондый ярдәм юк иде, ә балаларга рәхәт заман килде. Укы гына, эшлә генә, камилләш кенә – бөтен мөмкинлекләр дә бар.

2

– Әтием, үзе дә аңламыйча, миннән лидер тәрбияләгән. Сигезенче сыйныфта укыганда, Пионерлар йортында район штабы белән җитәкчелек иттем. Бөтен пионер оешмасы миңа буйсына иде.

МИН ҮЗЕМ!

Мин һәрвакыт бик көчле кыз булдым. Әтием, үзе дә аңламыйча, миннән лидер тәрбияләгән ул. Сигезенче сыйныфта укыганда, Пионерлар йортында район штабы белән җитәкчелек иттем. Бөтен пионер оешмасы миңа буйсына иде. Мин дружина советлары, пленар утырышлар үткәрдем, Ленин мәйданында демонстрациядә трибунада микрофон белән берүзем басып тора һәм парад белән җитәкчелек итә идем. Моннан тыш, мин әле спортчы да – хәзергә кадәр чаңгы шуам, ярышларда призлы урыннар алам. Хореография белән шөгыльләндем – Сабада хореографлар бик көчле иде. Без төрле балет «па»ларын өйрәндек, республиканың бөтен сәхнәсендә биеп чыктык. Ягъни безнең белән – совет балалары белән – шөгыльләнәләр иде. Мин пионер дружинасы җитәкчесе буларак партиянең район комитеты беренче секретарена балаларның бөтен теләген җиткерә алам. Без кирәк идек, партия җитәкчеләре безнең белән очраша, безне тыңлыйлар иде. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та хәзер яшьләр белән үзен шулай тота – очраша, аралаша, хуплый, бөтен кирәкле шартларны тудыра.

ЯЗМЫШ ИРОНИЯСЕ ҺӘМ ДӨРЕС ТӘРБИЯ

– Совет чорындагы кебек Яңа ел төнендә «Ирония судьбы...» фильмын карау традициясе сезнең гаиләдә дә сакланамы?

– Юк. Мин бу фильмны яратмыйм. Анда ясалмалык күп. Тормышта алай була алмый. Мин икейөзлелекне кўралмыйм. Без ирем белән Джулия Робертс уйнаган «Чибәркәй» фильмын карарга яратабыз.

3

– Мин унынчы сыйныфта укыганда, авыл мәктәпләрендә укучы кызлар сыер саварга тиеш, дигән карар чыкты, һәркайсыбызга берәр төркем сыер бирделәр. Иртәнге сәгать дүрттә һәм төш вакытында барып саварга тиеш идек. Көн саен.

4

– Игътибар иткән булсагыз, безнең өйдә табын һәрвакыт матур итеп бизәлгән.

– Кызык икән!

– Минем ирем бик кызык кеше. Ул беркайчан да тик утырмый. Аның белән яшәү – даими хәрәкәттә булу, дигән сүз. Без балалар бик кечкенә чактан ук бергәләп 2-3 көнгә балыкка бара идек – палаткалар белән, җәй дә, кыш та. Ирем – тәмлетамак, үзе дә бик оста пешерә. Без аның белән бөтен Европа илләре кухнясыннан авыз иттек инде. Ризык ошаса, ул һәрвакыт пешекчедән рецептын сорый, аннары өйдә пешереп карый, үзеннән нәрсәдер өсти, пропорцияләрен үзгәртә... Һәм бөтен ризыгы да бик тәмле килеп чыга. Бер генә проблема бар – мондый гурманга ярау бик кыен. Ә ирләр йөрәгенә юл һәрвакыт ашказаны аша салына, диләр бит. Тик мин аны торт пешереп гашыйк иттем. Һәм моның өчен тагын әтиемә рәхмәтлемен.

– Ул сезне торт пешерергә өйрәттемени?

– Шулай дияргә дә була. Мин унынчы сыйныфта укыганда, авыл мәктәпләрендә укучы кызлар сыер саварга тиеш, дигән карар чыкты, һәркайсыбызга берәр төркем сыер бирделәр. Иртәнге сәгать дүрттә һәм төш вакытында барып саварга тиеш идек. Көн саен. Хәтерлим әле, иртән фермага йөгерәм, аннан кайтып энем Эдикны ашатам, чөнки әни дә эшкә чыкты. Олег энемне мәктәпкә озатам. Фермадан соң никадәр яхшылап юынсаң да, мәктәптә утырганда тирес исе килгәндәй тоела иде.

Фермага исә кыр аша барасы. Һәм бервакыт буранда мин адаштым. Әтием бик курыккан. «УАЗ»ы белән бөтен кырны буйлап, мине көчкә тапкан. Һәм ул шул көнне беренче секретарь белән ачуланышты, мин ишек артында барысын да ишетеп тордым. Әтием безнең сыйныф кызларын башка фермага җибәрмәячәген әйтте, барыбызны да кулинариягә күчерде. Һәм без хезмәт дәресендә практикага кондитер цехына йөрдек. Анда безне табын бизәрләргә, кунак каршыларга, торт, гөбәдия, бәлешләр пешерергә өйрәттеләр. Минем барлык сыйныфташ кызларым да бик тәмле итеп ашарга пешерә, чөнки безне үз эшләренең осталары өйрәтте. Игътибар иткән булсагыз, безнең өйдә табын һәрвакыт матур итеп бизәлгән. Минем таләбем шундый, барысы да аны үти.

– Димәк, сезнең гаиләдә ашарга пешерү белән дә, табын бизәрләү белән дә бернинди проблема да юк?

– Кем беренче кайта, алъяпкыч – шуныкы. Безнең гаиләдә эшләр ирләрнеке һәм хатыннарныкына бүленми. Шунлыктан улларым өйне дә җыештыра, ашарга да пешерә белә. Безнең гаиләдә хезмәт хөрмәттә. Улларым балачактан ук тәмле пешерә. Мин еш кына

өйдә булмыйм бит. Баштарак аларга әзер ризыкны гына җылытырга кирәк иде. Соңрак үзләре дә пешерә башлады. Безнең кагыйдә бар иде: ашыйсың килә икән – әниеңә булыш. Җитәкче-әнинең тагын бер кагыйдәсе: бик кирәк вакытта гына миңа шалтыратырга ярый, юк-бар белән борчымау мәслихәт. Улларыма кирәк чагымда исә мин һәрвакыт элемтәдә, тыңларга, проблеманы хәл итәргә әзер. Шуңа алар миңа һәрвакытта таяна ала. Безнең гаиләдә ир-ат халкы күбрәк: бертуганнар, абзыйлар, уллар...

Бервакыт менә бу өстәл тирәсендәгеләрне санап караган идем, 17 ир заты булып чыкты – барысы да үзебезнекеләр, һәм мин аларны берүзем сыйладым!

АРХИВНЫ КҮЧЕРҮ КЫЙССАСЫ

– Соңгы арада Дәүләт архивын күчендерү тирәсендә шактый ыгы-зыгы купты. Кемдер моны акылга муафыйк дип саный, кемгәдер исә бөтенләй ошамый. Нигә һәм ни өчен күченгәнегезне аңлата аласызмы? Һәм бу архив эшен ни рәвешле җиңеләйтәчәк?

– Архив хезмәтенең миссиясе тарихи хәтерне саклаудан; документаль күргәзмәләр, архив чыганакларын нәшер итү, тарихи тикшеренүләр, уку заллары, сорауларга җавап бирү аша тарихи үткәнне популярлаштырудан; гражданнарның социаль хокукларын раслаудан; кирәкле архив белешмәләрен бирүдән гыйбарәт...

Моннан алты ел элек без милли, тарихи-документаль, аудиовизуаль архивларны бердәм дәүләт архивына берләштердек. Әмма ул хәзер, кызганычка, биш бинада урнашкан. Берсе Кремль урамында – анда беркайчан да капиталь ремонт үткәрелмәгән, шунлыктан документларны бөтенләй саклап булмый диярлек. Тагын ике бина 8 Март урамында урнашкан – алар 120 процентка тулган, анда иң күп – 232 мең тартма материал саклана, бөтен подваллары да тулы, документацияне башка кабул итә алмыйбыз. Анда уку залы, сорауларны кабул итү бүлеге бар – стажны һәм хезмәт хакын раслау өчен халык бөтен республикадан шунда килә, судларда кирәкле мөлкәткә кагылышлы документлар да шунда бирелә. Тагын бер бина Декабристлар урамында урнашкан, 2018 елда гына төзелсә дә, ул мәсьәләне хәл итә алмый – архив тулган. Себер трактындагы бина инде 150 процентка тутырылган...

Хәзер документларның күпчелеге цифрлаштырылганга, безгә бик яхшы сервер бүлмәсе кирәк. Узган ел Росреестр бөтен заманча таләпләргә җавап бирә торган шәп бинаны файдалануга тапшырды: анда янгын сүндерү системасы, вентиляция, зур конференц-зал, туклану пункты, уку залы бар, сервер бүлмәсе өчен урын каралган, шулай ук реставрацияләү лабораториясен, картон җитештерүне, мәгълүматны беренчел эшкәртү үзәген җайлап булачак...

Мин Татарстан Президентына бик рәхмәтлемен – ул федераль акчага төзелгән бинаны республика мөлкәтенә бушлай тапшыруны Россия Хөкүмәте дәрәҗәсендә хәл итә алды. 8 Март һәм Себер тракты урамнарындагы архивлар шунда күченә, чөнки документлар саклау өчен анда идеаль шартлар тудырылган. Шуны аңлау зарур: әгәр документларны саклау шартлары нормага туры килми икән, алар әрәм булачак. Без саклап калганның күп өлеше реставрацияләүне таләп итә.

Яңа бина зур матур территориядә урнашкан, анда төрле чаралар үткәрергә мөмкин булачак, шулай ук «Экспо» да янәшәдә генә – анда исә халыкара һәм россиякүләм чаралар уздыру мөмкинлеге бар. 120 эш урынлы административ корпус та бар.

Архивлар – үлеп бара торган тармак, дигән сүз йөрсә дә, бу алай түгел. Нәкъ менә архивлар тарихи мирасны саклау урыны булып тора. Бу – киштәләрдәге ниндидер тузан баскан кәгазьләр түгел. Алар кирәкле, хәзер без аларны цифрлаштырабыз. Былтыр, ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм иткәндә, архивка игътибар гаять зур булды. Сораулар шулкадәр күп иде, архивчылар көчкә өлгереп барды. Чөнки һәр оешмага, һәр тармакка архивтан мәгълүмат таләп ителде, барысы да китаплар, фильмнар, чаралар әзерләде. Ә бу мәгълүматны саклап калу өчен, бөтен

5
– Минем әнием – рус, әтием – татар. Шунлыктан Яңа ел табынында нигъмәтләр хәзер дә «күпмилләтле» булып кала. Анда һичшиксез кулдан бөгелгән пилмән булырга тиеш.

6

– 1984 елдан бирле Яңа ел табыныбызда һәрвакыт үрдәк була. Ул чакта без Сабада яшәдек, әни үрдәкләр асрады, шунлыктан Яңа ел табыныбыз алма, кураагә һәм мандарин тутырып пешерелгән үрдәксез була да алмый иде!

заманча таләпләргә җавап бирә торган шартлар кирәк.

5 ноябрьдә күченә башладык, дүрт фура, 180 йөкче һәм архивчы көнне төнгә ялгап эшләде.

Хәзер исә уку залыннан мәхрүм калабыз дип хафаланган тарихчыларга җавап бирәм. Алай түгел. 8 Март урамындагы бина Казан муниципаль архивына тапшырыла, ул дәүләт архивы вазыйфасын башкарачак. Шунлыктан сорауларны кабул итү вакыты да, уку залының эш сәгатьләре дә үзгәрмәячәк. Документларның кайда саклануы мөһим түгел бит, аны эзләп килүче шул ук залга кереп компьютер каршына утыра да, рәхәтләнеп файдалана. Бездә бердәм архив мәгълүмат системасы, шунлыктан документның кайдан кертелүе мөһим түгел. Безгә хәтта Ханты-Мансийскидан да сорау бирергә мөмкиннәр. Тиздән исә уку залына килү зарурлыгы да бөтенләй бетәчәк.

– Ә документ цифрлаштырылмаган очракта җавап бирү күпме вакыт таләп итә?

– Цифрлаштырылмаган икән, гариза шундук дәүләт архивына китә, һәм регламент буенча аңа өч тәүлек дәвамында җавап бирелергә тиеш. Киләчәктә әлеге вакытны өч сәгатькә кадәр киметергә ниятлибез.

«ХЕЗМӘТ ДАНЫ ШӘҺӘРЕ»

– Сез ничек уйлыйсыз, Советлар Союзындагы архивларга, документлар саклауга мөнәсәбәт хәзерге мөнәсәбәттән аерыламы?

– Бик аерыла. СССРда архив документациясенә бик сак караганнар. Революция елларында бигрәк тә. Хәтта революциягә кадәрге Россиядә дә документларны ничек тә яхшырак сакларга тырышканнар. Ул чактагы документлар идеаль тәртиптә – сыйфатлы кәгазь, дөрес орфография, бөтен имзалар бар, барысы да төпләп тегелгән, хатасыз тутырылган. Билгеле, аларны саклау шартлары гел уңайлы гына да булмаган. Чиркәүләрдә янгынга каршы эремә белән эшкәртелгән стеллажларда төргәк-төргәк сакланган алар, җылытылмый торган биналарда хезмәткәрләр киез итек киеп йөргән.

Бөек Ватан сугышы елларында да архивка шундый мөнәсәбәт күрсәтелгәнгә, Казан «Хезмәт даны шәһәре» исеменә лаек булды да инде. Без бик күп материал тупладык, шулар нигезендә Тарих институты бик яхшы китап чыгарды. Барысы да Мәскәүгә җибәрелде, шунлыктан Казан әлеге мактаулы исемне алды. Хәзер Яшел Үзән шәһәре буенча материаллар әзерлибез, ул да әлеге исемгә лаек булыр, дип өметләнәбез.

Узган гасырның 80-90 нчы елларында, хосусый милек кертелгәч, документларга караш начарайды. Хосусый оешмалар документларын архивка бирми. Без 2018 елдан бирле әлеге юнәлештә эшлибез, предприятиеләрнең үз документларын тапшыруын дәгъвалыйбыз. Безнең законнар буенча, әгәр Пенсия фонды үз канунnарын үзгәртмәсә, архивлар әле тагын 18 ел буе юкка чыгарылган оешмаларда эшләүчеләрнең стажын һәм хезмәт хакы күләмен расларга тиеш. Ә миндә бүген шундый «югалган» 1616 оешма исәпләнә, кайчандыр аларда эшләүчеләргә без берничек тә ярдәм итә алмыйбыз. Мәсәлән, «Зима» берләшмәсе, без барыбыз да анда тегелгән киемне кигәнбездер. Әмма без әлеге предприятиедә эшләгәннәрнең стажын һәм хезмәт хакын раслый алмыйбыз. Милекче алышынган да, документлар безгә тапшырылмаган. Хәзер исә «Спартак» та шул ук хәлдә...

ЦВЕТАЕВА ӘТИСЕНЕҢ ВИЗИТКАСЫ

– Иң кызыклы нинди архив документларын атый аласыз? Күңелегезгә кереп калганнарын?

– Мәсәлән, 1910 елгы «О Казанском первоклассном Богородицком девичьем монастыре, храмах оного, зданиях, угодьях и документах» чиркәү исемлеген атарга була. Тагын генерал-прокурор П. Х. Обольяниновның Казан гражданы губернатор А. И. Мухановка хәбәрен мисалга китерә алам – Санкт-Петербург Азиат типографиясенең бер өлешен Казанга күчерү һәм аны

1 Сытабыз

2 Туглыйбыз

3 Болгатабыз

4 Басабыз

5 Җәябез

6 Кисәбез

7 Бөгәбез

8 Пешерәбез



Уважаемые читатели журнала
„Татарстан"
С наступающим Новым годом!
Пусть 2022 год принесет нам
большей уверенности в завтрашнем
дне, как это было в советские годы.
Вернется чистота и искренность
в человеческих отношениях.
Желаю всем взаимопонимания,
уважения друг к другу, счастья,
красивой любви и долголетия
нашим детям.
Ходай безне тигезлектән,
бәхет догасыннан аермасын!
Гульнара Габдрахманова

Казан гимназиясендә урнаштыру хакында император фәрманы турында ул. 1880 елның 9 маенда имзаланган әлеге документта Казанда мөселман дини китапларын бастыру өчен гарәп шрифтлы беренче типография булдыру хакында сөйләнә.

Ә менә әле беркайда да күрсәтелмәгән тагын бер документ – Марина Цветаеваның этисе Иван Владимировичның 3 нче гимназия директоры М. Ивановка биргән визиткасы. Цветаев үзе Мәскәү император университетындагы Сынлы сәнгать музееның беренче директоры булган.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ СЕРЕ

– Архив документларының, Татарстан халкының серләре кайда һәм нинди заманча шартларда саклануын без хәзер беләбез. Ә сезнең шәхси гаилә бәхетенең сере кайда саклана?

– Озак еллар буе бергә тату гомер кичерүнең (ирем белән без инде 28 ел бергә) төп сере һәркемнең үзенчә, әмма мин, хәләл җефетеңә нидер әйткәнче, башта уйларга кирәк, дип саныйм. Әгәр бөтен кеше шул кагыйдәне үтәсә, күп гаилә таркалмас иде. Миңа хәзерге яшьләрнең бик тиз өйләнешүе һәм тиз генә аерылышуы бер дә ошамый. Кайвакыт без аерылышырга җыенган яшьләрне архивка чакырабыз да, шәҗәрәләрен төзибез. Әби-бабаларының шулай бергә бик озак гомер итүен күрсәткәч, нигә соң сез дә шулай булдыра алмыйсыз, дип сорыйбыз. Аларның бүгенгедәй байлыгы да, туйганчы ашарына да, яшәргә аерым фатиры да булмаган... Сезнең бөтен нәрсәгез бар, тик бер-берегезне аңлый алмыйсыз, дигәч, уйга калалар.

Миңа әтием һәрвакыт әйтә иде: иреңне үзең сайлап чыктың, шуңа – түз. Идеаль кеше булмый ул. Бер-береңә яраклаша белергә кирәк.

Беркемне дә үзгәртергә маташырга кирәкми. Үзгәртү түгел, бәлки яраклашу, хөрмәтли белү – менә бәхет сере нәрсәдә. Һәм тагын теләсә нинди вак-төяккә дә куана белү зарур. Без ирем белән һаман бер-беребезне очрашуга чакырабыз әле. Керләр болай да юыла, ашарга барыбер пешерелә ул. Иң мөһиме болар түгел, ә бәлки бергәләп урманга бару, театрда спектакль карау, кичке табында рәхәтләнеп сөйләшеп утырудыр. Без барыбыз да бик төрле, хәләл җефетеңнең яхшы якларын күрергә өйрәнергә кирәк. Минем иманым камил: безнең гомер озынлыгын да, үзебезгә тиешле бәхет күләмен дә Аллаһ Тәгалә билгели. Иң мөһиме – аны көнкүрештәге вак-төяккә әрәм итмәү. Максат та бер генә, уртак булырга тиеш. Безнең дә башта йортыбыз да, машинабыз да, яхшы эшебез дә юк иде. Торабара исә, Аллаһка шөкер, барысы да булды, барысына да бергәләп ирештек, шуңа күрә бүгенгебез бик кадерле безгә.

Язманың видеоварианты да бар

Фото: Илнар Өметбаев

Автор: Руфия Фазылова

«ЧЫРШЫ, ЧЫРШЫ, БЕЗ СИНЕ САГЫНЫП КӨТТЕК ЕЛ БУЕ...»*

«Татарстан» журналы ел дәвамында ата-бабаларыбыздан килгән затлы һөнәрләрне, көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне барлады. Киләсе елга да әлеге проектны дәвам итәргә ниятлибез. Ә менә декабрь санына Яңа ел рухын кертергә булдык. Шуңа да бу юлы элеккечә итеп чыршы бизәдек. Героебыз Мәүлидә апа Шакирова белән узган гасырның илленче-алтмышынчы еллары Яңа ел бәйрәменә кайтып килдек.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

МӘКТӘП «ЁЛКАСЫ»

Мәүлидә апа Казан шәһәренең Яңа Савин районында яши. Берничә ел чыршы бизәмәгән булган, тик безгә теләктәшлек күрсәтергә рәхәтләнеп ризалашты. «Мин дә сезнең белән бергә балачакка кайтып килермен», – диде.

Мәүлидә апага гыйнвар башында җитмеш биш яшь тула. Биектау районының Зур Кавал авылы кызы ул. Дөрес, гомеренең күп өлеше Казанда узган. Сигез классны тәмамлагач, башкалага бәхет эзләп чыгып киткән. Һәм тапкан да...

– Эштән курыкмадым. Шуңа да унҗиде яшемнән Казанның ясалма күн фабрикасында, аннан 7 нче заводта эшләдем, – диде Мәүлидә апа. – Сәламәтлек өчен зарарлы эштә булганга, лаеклы ялга кырык биш яшьтән чыктым, тик барыбер 2013 елга кадәр эшләдем. Хезмәт стажым илле ике ел. Миннән олырак апалар авырый башлагач, заводтан китәргә булдым. Тормышның да матурлыгын күрергә кирәк, дип уйладым. Акрынлап дин гыйлемен өйрәндем, мәчеткә йөрдем. Аллаһка шөкер, дөньялык белән бергә ахирәт гамәлләрен дә алып барам. Анысы да бик кирәк, кызым...

Мәүлидә апа ясалма чыршыны әзерләп куйган иде. Пөхтәләп, кат-кат пакетларга төреп куелган ул. (Гомумән, хуҗабикә бик пөхтә, өч бүлмәле фатиры ялт иткән.)

– Кечкенә оныклар юк инде, үсеп җиттеләр, – диде хуҗабикә. – Бу чыршыга ничә ел икәнен төгәл белмим дә, күптәнге ул. Әнә шулай хасиятләп тоткач, сакланды. Уенчыклар исә тагын да картрак, байтагы совет чорында ясалган.

Мәүлидә апа уенчыкларны тагын да кадерләгән – һәркайсын аерым куеп, мамык белән каплаган. Ул аларга кулына яшь бала алган кебек, сак кына кагылды.

– Ә болар арасында сезнең балачактан калган уенчыклар юкмы? – дибез.

– Юк. Без үскәндә мондый пыяла, төсле уенчыклар бөтенләй юк иде. Бәлки шәһәр җирендә булгандыр, анысын әйтә алмыйм. Бу – балалар үскәндә алган уенчыклар. Без балачакта өйдә чыршы бизәми идек. Илленче еллар уртасы бит, тормышлар авыр. Ә менә мәктәптә Яңа ел бәйрәмен билгеләп уза идек. Укытучылар урманнан яшел чыршы кисеп алып кайта, ә без аны бизибез...

Мәүлидә апа бер вакыйганы бүген дә ачык хәтерли, чөнки балачагының иң якты истәлекләреннән берсе. Алтмышынчы еллар башында Зур Кавалның мәктәп директоры коридорга эләр өчен зур ялтыравык ука алып кайта. Ул озын, бик матур бизәкле була –

* «Чыршы янында» җырыннан. И. Шамсетдинов музыкасы. С. Урайский сүзләре.

мәктәпнең бер диварыннан икенчесенә кадәр җитә. Шушы гүзәллекне күреп балалар «аһ» итә!

– Безнең өчен ул ялтыравык бер могҗиза булды, моңа кадәр андый матурлыкны күргән юк иде, – дип дәвам итте Мәүлидә апа. – Бу халәтне бүгенге балаларга аңлатып булмый... Ул соклану, сөенү, аптырау да иде. Уку елы беткәнче сыйныфташлар белән шул турыда гына сөйләштек. Менә ул Яңа ел безнең өчен чынлап та зур бәйрәм булды.

Гаиләдә өч бала үсә алар, Мәүлидә апа уртанчысы. Абыйсы вафат инде, сеңлесе Биектау районының Ташлы Кавал авылында яши икән. Мәрхүм ире Илдар да Биектау районы егете була, Әсән авылыннан. Танышу тарихлары турында сорашкач, әңгәмәдәшем болай диде:

– Казанда очраштык без, шактый вакыт дуслашып йөрдек. Илдар миннән биш яшькә олы иде. Миңа егерме өч тулгач өйләнештек. Бик тырыш, булдыклы ир булды. Илдарга эшеннән бер бүлмә биргәннәр иде, башта шунда яшәдек. Төзелештә эшләде ул. Бу өч бүлмәле фатирны аның тырышлыгы белән алдык. Бик кызганыч, ирем унҗиде ел элек яман шештән вафат булды. Алтмыш өч яшендә генә иде. Оныкларны да туйганчы сөя алмады дип көрсендек. Алар әле бәләкәй иде. Илдар белән ике кыз үстердек, Гөлнара белән Алсу. Дүрт оныгыбыз бар.

КОНФЕТЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, КӘГАЗЕ ДӘ КАДЕРЛЕ!

Бүген Яңа ел бәйрәменә олысы да, кечесе дә әзерләнә. Алдан ук бүләкләр сайлана, мул табыннар корыла. Илленче елларда исә халык Яңа ел дигән бәйрәм барлыгын белгән, әмма аннан болай зур тамаша, ыгы-зыгы куптару бөтенләй башларына да килмәгән.

– 31 декабрь көнне радиодан җырлар яңгыраталар, бөтен бәйрәм киче шул иде, – ди Мәүлидә апа.

– Ә Кыш бабай бүләге? – дип аптырап сорап куйды кызлар.

– Безнең балачакта бүләк биреш юк иде. Аны тиеш дип тә уйламаганбыз. Ә менә балалар үскәндә конфет, алма, печенье ише әйберләрне пакетка салып бирә идек. Алар шуңа бик сөенә иде.

Тик шулай да Мәүлидә апа өчен балачактагы Яңа ел бәйрәме иң күңелле булып истә калган.

– Укытучы безгә кәгазьдән төрле матур бизәкләр ясата иде, – диде әбекәй. – Бу бик зур сөенечле вакыйга инде. Аны һәр сыйныф эшли, шунлыктан ул күп җыела. Аннан соң укытучылар уенчыкларны чыршыга элә. Балалар шул чыршы тирәсендә уйный, җырлый... Ул көннәрдә мәктәптән кайтып китәсе дә килми, гел шул чыршы янында гына әйләнәсе килә.

Мәүлидә апа безгә балачакларындагы кебек чыршы уенчыгы ясап күрсәтте. Уенчык дип... Конфет кәгазенә кәгазь яки пластилин тутырасың да, төреп куясың. Аннан соң җеп белән бәйләп чыршыга эләсең.

– Кызыл балчыктан төрле фигуралар ясап, аны киптереп, конфет кәгазенә дә төрә идек, – диде әбекәебез. – Без зуррак сыйныфларга җиткәч, пластилин чыга башлады. Аннан да ясый идек. Әле кайбер кешеләр, камырдан төрле формалар ясап, мич төбенә киптерергә куя иде.

Иң кызыгы (әллә кызганычымы), конфет кәгазе дә кадерле чак бит. Шуңа күрә аны мичкә якмыйча җыеп барганнар. Әбиләр хәтта конфет кәгазеннән оныкларына этәч, тавык сыннарын да ясап биргән. (Заманга яраклашу инде бу!)

Мәүлидә апа иренең апасы Солтания әби белән яши. Әбекәйгә җәен туксан яшь тулган, аны яратып «Алма апа» дип йөртәләр. Солтания апаның үз гаиләсе юк икән, кияүгә чыкмаган ул. Кечкенәдән сәламәтлеге белән проблемалар булган.

– Безнең Алма апа тыныч, сабыр холыклы. Гомер буе хәлен белешеп, бер-беребезне якын күреп яшәдек, – диде Мәүлидә апа. – Җәй көне бергә авылга кайтабыз, көзен Казанга киләбез. Аралашырга бик ипле әби ул. Әле аш-су әзерләгәндә ярдәм дә итә.

Солтания апа да кат-кат рәхмәтен әйтте:«Кешене үз балалары да болай карамый, Мәүлидәнең кызлары, оныклары миңа карата бик ихтирамлы», – диде.

...Һәр заманның үз шатлыгы, үз мәшәкате, куанычы. Нинди генә булса да, балачак кеше гомерендә иң якты хатирәләре белән уелып кала. Мәүлидә апа да балачагын, шул исәптән Яңа ел бәйрәмен дә, фәкать җете төсләр белән генә хәтерли.

«БЕЗ БИТ ҖИРГӘ ЯКТЫ, ҖЫЛЫ, ЯМЬ ӨСТӘРГӘ ЯРАТЫЛГАН»*

Бөтенсоюз удар төзелешләр чоры булган бу, партия һәм комсомол чакыруына ул вакытта бөтен илдән романтиклар җыелган. Безгә, ул төзүчеләрнең нәсел-нәсәбенә, куәтле предприятиеләр һәм хәтта шәһәрләр мирас булып калган.

Автор:
Катерина Котова

– Михаил Тимофеевич, башла! – дигән команда яңгырый.

Экскаваторның зур чүмече дөбер-шатыр килеп җиргә төшә, балчыкны каерып алып күтәрә дә йөк машинасының арбасына бушата. Дулаган буран һәм сызгырган җил тавышы аша алкышлар һәм фотоаппаратлар чекелдәве ишетелә. 1969 елның 13 декабрендәге бу минутлар Чаллы автогиганты туган мизгел дип кабул ителә.

БЕРЕНЧЕЛӘР!

Әлеге зур, шәп, матур йөк автомобиленә пьедесталга менү юлында авыр ком да, очлы ташлар да комачаулый алмады. Легендар «Дакар» ралли тарихында дүртенче тапкыр бөтен призлы урыннар подиумын «КАМАЗ-мастер» командасы яулады – автогигант өчен 2021 ел әнә шундый триумфтан башланды.

Хәер, җиңүләр спортта гына түгел иде. Төрле чәчелүчән йөкләр ташу өчен көйләнгән К5 буыны автомобильләренең яңа модельләре базарга чыгарылды, шәһәр пассажир электр транспорты линейкасы баетылды, Россиянең иң зур карьер үзбушаткычы тәкъдим ителде һәм автономияле режимда карьерларда куллануны күздә тоткан тиңсез «Геркулес» шарнирлы-кушылмалы үзбушаткычы күрсәтелде...

Бүген КАМАЗ илнең иң эре автомобиль корпорациясе булып тора һәм дөньяның иң алдынгы авыр йөк автомобильләре җитештерүчеләре арасында тәүге егермелеккә керә. Аның җитештерү куәте елына 71 мең автомобиль тәшкил итә, ә технологик чылбырда 31 меңнән артык кеше эшли.

Ярты гасыр элек җирдән әнә шул пионер чүмеч балчыкны күтәреп салу бәхете экскаваторчы Михаил Носковка тәти. Пионер чүмеч дип атау – беренче булганга гына түгел. Экскаватор өчен металлны Кострома пионерлары җыйган, ә Кострома комсомоллары шул металлдан завод төзү өчен махсус машина ясаган. Советлар Союзы гына түгел, ә дөнья күләмендә иң удар төзелеш әнә шулай башланып киткән. Хәтта БАМ салганда да төзелеш бу кадәр куәтле дәрәҗәдә бер урынга тупланмаган, эшләр территория ягыннан да, вакыт ягыннан да сузылган булган.

«ИКӘҮ ӨЧ КЕШЕ ӨЧЕН ЭШЛИ»

КАМАЗның девизы шундый була. Хәер, икенче төрлесе дә билгеле: «Авырлыклар онытылыр, могҗиза тормышка ашар, бүген төшкә кергән иртәгә чын булыр». Бу сүзләр КАМАЗ төзелеше рухын һәм кәефен тулысынча чагылдыра. Бүген күз алдына китерүе дә кыен: 1975–1976 елларга туры килгән иң кызу чорда бер төзелеш мәйданчыгында 95 меңгә якын кеше эшләгән!

– Чаллыга килгәч, чып-чын удар комсомол төзелеше икәнен шунда ук тойдым! – дип искә алган КАМАЗ төзелешенә тәҗрибәле инженер-төзүче буларак килгән, аннары «Камгэсэнергострой» җитәкчесенең беренче урынбасарына кадәр хезмәт юлы узган Виктор Ластовка. – Комсомол һәр җиргә өлгерә иде. Яшь-җилкенчәкне, дөресен генә әйткәндә, эксплуатацияләргә дә күп сорап тормыйлар, янәсе, әйдә, комсомол – алга, хезмәткә! Һәм комсомол алга бара, хезмәткә чума, әле җитмәсә, шат күңел белән, һич көчәнмичә.

– Бу бит чып-чын энтузиазм һәм комсомол дәрте иде! – дип сөйли шәһәрнең мактаулы гражданы Гөлзада Рзаева. – Кемдер зарлана башлый икән, юлына ак җәймә!

КАМАЗ төзелешендә комсомол оешмалары фикеренә, аларның тәкъдим һәм дәгъваларына илтифатсыз карарга мөмкин булмый. КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Беляев әнә шундый тәртип урнаштыра. Һәркем диярлек туп-туры аңа кереп, хәбәр итә алган: менә, бетонны токтарладылар, тиешле вакытны бозалар. Бер яктан, тулы демократия дияр-

* «Китмим әле яшьлегемнән» җырыннан. Луиза Батыркаева музыкасы. Фирая Зыятдинова сүзләре.

лек, икенче яктан, таләпчәнлек тә югары була. Һәр ялгышлык өчен Беляев: «Ә комсомол кая караган?» – дип сорау куя. Ул чакта беркем дә: «Бу безнең эш түгел», – дип җавап бирә алмаган.

1973 елда ук инде Чаллыдагы Бөтенсоюз удар комсомол төзелешендә катнашкан 8 мең комсомол «Коммунистик хезмәт ударнигы» исемен йөртә. Әмма романтик-энтузиастлар бу шәһәрдә гамәлгә куелган башка мактаулы исем – «КАМАЗ төзелеше ударнигы» исемен аеруча хөрмәт итә. Аңа 5 меңнән артык алдынгы хезмәткәр лаек була, ә бу исем белән бергә торак алганда өстенлек, шифаханәләргә ташламалы юлламалар да, еллык ялны уңайлы вакытта алу, транспортта бушлай йөрү мөмкинлеге дә бирелә.

Автогигантның проекттагы куәте шаккатыра. Елына 150 мең автомобиль һәм 195 мең көч агрегаты һәм двигатель җитештерүгә исәпләнгән завод эшли башлый. Шуннан соңгы унбер ел эчендә КАМАЗның кулланышка кертелгән төп фондлары бәясе ЗИЛ, ГАЗ, ВАЗ заводлары фондларының өчесен бергә кушып исәпләгәндәге бәя белән тигезләшә һәм 3,9 млрд сум тәшкил итә. Дәүләт комиссиясе заводның ике өлешен дә «бишле» билгесе куеп кабул итә.

«ТОТЫНДЫК ЗУР ТӨЗЕЛЕШКӘ ЯШЬЛӘРЧӘ ҖИҢЕЛ КУЛДАН»

Яшьлек тыкрыгы һәм Яшьләр бульвары, Романтиклар һәм Энтузиастлар бульварлары… Бүген бу исемнәр безгә әнә шул каһарманлык көннәре турында хәтерләтә. Рекордлы срокларда файдалануга тапшырылган автогигант янәшәсендә шәһәр дә яшен тизлегендә калкып чыга.

Яңа эшкә килгән кешеләрне еш кына вагоннарга, тулай торакларга һәм хәтта якын-тирә авылларга да урнаштырганнар. Тик нәкъ менә Чаллыда фатир алу иң җиңеле була. Күпләр төзелешкә әнә шуның өчен килә дә. Төзелеш темплары халык санының үсеш тизлегенә иярергә мәҗбүр була, ә кайчагында КАМАЗга көненә биш йөзгә якын эшче килә. «Иртән өйдән бер юл белән чыгып китсәң, ә кайтканда инде урап кайтырга туры килә, чөнки бу урында яңа объект төзелә башлаган яки зур чокыр казыганнар», – дип искә алган берничә ел Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабын җитәкләгән Рим Халитов.

Ә яшәү шартлары ничегрәк соң? Проблемалар җитәрлек булган!

– Без аларга игътибар итмәскә тырыштык, – дип искә ала Гөлзада Рзаева. – Резин итекләр һәм бер телем ипекәй – анысын да икегә бүләбез…

КАМАЗ төзүчеләре резин итекләргә багышлап күпме мәдхия язгандыр! Шәһәр төзелешендә саз-пычрак ерып йөрүләр һәркемгә дә туры килә. Удар төзелеш геройларының тездән ләмгә баткан фотосурәтләрен санап бетерерлек түгел. Су салынган тимер ләгәннәр һәм алар янында чүпрәк уралган агач таяклар һаман да истә, итеккә ябышкан балчыкны шунда чистарта халык.

Ә иптәшең белән бүлешергә туры килгән «ипи телеме» каян килгән? Беренче төзүчеләр товарларны автокибетләрдән сатып ала. Тик дүрт ел эчендә, 1976 елдан башлап, шәһәрдә утызлап кибет, шул исәптән ике универсам ачыла. Әлбәттә, бөтен СССРдагы кебек үк, киштәләр әллә ни муллык белән мактана алмый. Тик адәм баласына күп кирәкме соң? Бигрәк тә романтик рухлы комсомолларга.

Инде 1976 елның 7 августына ук Чаллыда 1 миллион квадрат метр торак файдалануга тапшырыла. Завод янында яңа шәһәр үсеп чыга. Бүген ул – зур сәнәгать үзәге, Татарстанда халык саны ягыннан бары тик аның башкаласыннан гына калыша торган шәһәр. «Еллар узар, ә совет кешеләре Камадагы хезмәт батырлыгы турында горурланып искә алыр» – Леонид Брежневның бу сүзләре бик алдан күреп әйтелгән булып чыга.

БӨТЕНСОЮЗ ТӨЗЕЛЕШЛӘРЕ МИРАСЫ

Татарстанда удар комсомол төзелешләренең тарихы 1958 елда башлана. Ул вакытта Казан химия заводы – хәзерге «Оргсинтез» төзелеше старт ала. Беренче продукция 1963 елда чыгарыла.

1959 елда Зәй дәүләт электр станциясе төзелеше игълан ителә. Зәй авылы янында Яңа Зәй эшчеләр бистәсе барлыкка килә.

1962 елның октябрендә Бикләп урман хуҗалыгына караган территорияне агачлардан чистарту эшенә керешәләр. Тиздән биредә башка гигант – «Түбән Кама Нефтехим» үсеп чыга. Җитештерү 1967 елда башлана. Завод тирәсендә Түбән Кама шәһәре пәйда була.

КУКМАРА КИЕЗ ИТЕКЛӘРЕ:
ҖЫЛЫ, УҢАЙЛЫ ҺӘМ МАТУР

Киез итек киеп, беренче карга чыккач, күңелгә җылы йөгерә: тормышыбызда әле нинди дә булса рәхәтлек бар икән бит. Йомшак һәм искиткеч җылы үзләре. Традицияләрне саклаган хәлдә, камиллеккә ирешергә омтылып, Кукмарада хәзергәчә нәкъ әнә шундый киез итекләрне инде менә 154 ел басалар.

КИЕЗ ЭШЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫЛАР

Кукмара һәм аның тирә-ягында борын-борыннан һөнәрчелек үсештә булган. Мәсәлән, Казан губернасының елъязма кенәгәләрендә йон иләү-түшәү белән шөгыльләнүче һөнәрчеләр искә алына. Нәкъ менә шулар киез басу эшенең чишмә башында торган да инде. Кукмарада киез итек җитештерү чын-чынлап исә 1880 нче елларда киң таралыш ала. 1910 елга Россиядә чыгарылган 21 миллион пар киез итекнең 3 миллионы Кукмара җитештерүчеләренеке була. Иң беренче булып киез итек басу эшен абыйлы-энеле Комаровлар башлап җибәрә. Эре эшмәкәрләр бу продукцияләрен сатуда һичбер кыенлык кичерми. Кукмара һәм аның тирә-ягында киез итек җитештерә торган башка ширкәтләр дә була. «Бертуган Родигиннар» фабрика-сәүдә ширкәте, Василий Вавиловның киез аяк киемнәре фабрикасы, абыйлы-энеле Войдиновларның остаханәләре – әнә шундыйлардан.

Социалистик җәмгыять төзелгәч, барысы да үзгәрә. Дәүләткә тартып алынган киез итек фабрикаларында җитәкчелек фабзавкомчылар кулына күчә.

«КЫЗЫЛ ТУКУЧЫ»

Кукмара аяк киеме фабрикасы индустриализация елларында әнә шулай дип атала. Бу чорда цехларның яңа корпуслары барлыкка килә, иске биналар ремонтлана һәм төзеп бетерелә, әмма җитештерү эше тагын да җитдирәк реконструкция уздыруны һәм бар процессларны бер урында туплауны таләп итә. 1933 елда биредә

Фотоларны «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖ тәкъдим итте. Реклама.

колачлы үзгәрешләр башлана, тик Бөек Ватан сугышы аларны тормышка ашырырга комачаулый. 1,2 миллион пар киез аяк киеме җитештерү куәтенә ия фабриканың төзелеш һәм реконструкция эшләрен сугыштан соңгы елларда гына тергезәләр.

Ул елларда тарих сәхнәсендә барган вакыйгаларның берсе дә фабриканы читләтеп үтми: репрессияләр дулкыны һәм «чистартулар» аркасында җитәкчеләр калейдоскоптагы сурәтләр кебек алышынып тора, эшче-крестьян комиссиясе предприятие эшчәнлегенең барлык юнәлешләрен дә контрольдә тота. Шул ук вакытта, бөтен илдәге кебек үк, гавамны сәнгатькә җәлеп итү, наданлыкны бетерү, уйлап табучылык һәм башкалар да фабрика тарихына языла.

Аннан сугыш була, «Киез итекләр фронтка снарядлар кебек үк кирәк» дигән гыйбарә ул чакта Кукмара фабрикасы коллективы өчен хезмәтнең төп мәгънәсенә әйләнә. Ә инде сугыш тәмамлангач, фабрика тыныч тормышка кайта.

КУКМАРА ХАЛКЫНА

1954 елда «Кызыл тукучы» киез итек-аяк киеме фабрикасының исеме Кукмара киез итек фабрикасы дип үзгәртелә.

СССР елларында Кукмара нигездә нәкъ менә киез итек фабрикасы ярдәме белән тормыш өчен уңайлы, заманча бистә булып үсә. Кукмара итекләре ул вакытта бөтен Совет Армиясен, Поляр түгәрәк аръягында эшләүчеләрне, Байкал-Амур магистрале төзүчеләрен, Көнбатыш Себер нефтьчеләрен җылыга тиендерә.

Районның барлык халкы диярлек кайчан да булса мондагы киез итек басу-киез комбинатында эшләгән. Киез җитештерү эшендәге совет кадрларына ихтирамлы мөнәсәбәтне фабрика хезмәткәрләренең социаль яктан ничек тәэмин ителүе дә раслый: предприятие хисабына алар өчен күп фатирлы торак йортлар, тулай тораклар, балалар бакчалары һәм яслеләр, сәламәтләндерү лагерьлары төзелә. Шәхси йортлар салуда ярдәм күрсәтелә. Кукмара өчен әле сугышка кадәр үк көнүзәк мәсьәләләрнең берсе – биологик чистарту корылмаларын төзү мәсьәләсе дә хәл ителә. Куәтлелеге зур запас белән проектланган бу чистарту корылмалары бистәдә биш катлы торак йортлар һәм социаль объектлар төзүне башлап җибәрергә мөмкинлек бирә...

ҺӨНӘРНЕ САКЛАП КАЛАЛАР

Бүген Кукмара киез итек фабрикасы каршында «Бертуган Комаровлар» исемен йөрткән тукталыш-пассажирлар платформасы бар. Ул 30 ел элек предприятиенең шул чактагы директоры Шамил Әхмәтшин тәкъдиме белән төзелә. Узган чор фабрикантлары – киез эшенең башында торучыларга хәзерге заман эшкуарыннан әнә шундый хөрмәт билгесе ул. Әлеге тукталышка төшкәч, бүгенге Кукмара халкы һәм аның кунаклары «Кукмара киез итекләре» комбинаты янындагы мәйданга килеп чыга.

Шамил Әхмәтшин җитәкчелек эшен болгавыр 90 нчы елларда башлый. Җитештерүне үстерү өчен әллә ни яхшы вакыт түгел кебек. Тик нәкъ менә шул чакта предприятие модернизация уза, пар казанналары бинасы күмердән газ куллануга күчерелә. Бу исә банкротлыкны булдырмый калырга мөмкинлек тудыра. Предприятие алдындагы икенче бурыч, мөгаен, тагын да мөһимрәк булгандыр – гади сатып алучыга, халыкка йөз тоту. Кукмаралыларга авыр була. Алар өчәр смена эшли, бартер белән канәгатьләнә, әмма борынгы һөнәрне саклап калалар...

БЕРЕНЧЕ МОДЕЛЬ

– Ни генә дисәк тә, Россиядәге кыш өчен киез итек белән ярыша алырлык аяк киеме юк. Өстәвенә, җылылык – аның бердәнбер өстенлеге түгел. Ул үз хуҗасына дистәләрчә ел хезмәт итә ала, – ди «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖ генераль директоры Ләлә Шәрипова. Бернинчә ел элек ул биредә әтисе Шамил Әхмәтшинны алыштыра һәм аның эшен дәвам итә. – Бер ярым гасыр элек кебек үк, без гадәти, классик киез итекләр чыгарабыз. Алар безнең иң беренче модельләребез була. Берничә дистә ел солдат һәм эшчеләр әнә шуларны киеп йөрде. Караңгы соры төстәге ул итекләр резин яки ансыз гына табанлы. Әлбәттә, аларның кыяфәтендә нәфислек юк. Шуңа да карамастан, СССР чорында без нәкъ менә шундый ике миллионга якын пар киез итек җитештерә идек.

Инде менә 30 ел армия кышкы аяк киемен Кукмара комбинатыннан алмый, киез итекләргә нигездә төрле предприятиеләр үз эшчеләренә махсус аяк киеме сыйфатында заказ бирә. Бүген биредә ел саен шундый 150 меңгә якын пар киез итек басыла. Ә барлык җитештерелгән киез итекләр саны елына 350 мең пар тәшкил итә. Махсус аяк киемнәре өчен тупасрак, ә Кукмара киез итекләре өчен – йомшаграк киез кулланыла.

Лэлэ Шэрипова, «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖ генераль директоры.

КУЛ КӨЧЕ БЕЛӘН БАСЫЛА

Кукмара киез итекләре, шулай ук киез җитештерү, тегелгән аяк киеме һәм кием-салым өчен чималны комбинат Россия, Төркия, Казахстан, Монголия, Австралиядәге ышанычлы сатучылардан гына ала. Киез итекләргә күбесенчә җирле чимал – Россиядән җыелган йон кулланыла, ә киез җитештерү өчен Австралия мериносы йоны кирәк. Киез итек басу беренче карашка гына гади тоела, имеш, бер кочак йон аласың да итек әвәлисең. Асылда хәтта чималны әзерләү этабы ук бик катлаулы. Төрле сорттагы чиста, киптерелгән йон күпертелә һәм, эшләнмә өчен таләп ителгән бер төрле массага килгәнче, бергә катыштырыла.

– Әйе, башлангыч мәлдә киез итек ул – бер тотам сарык йоны гына. Берничә дистә этаптан гыйбарәт җитештерү процессыннан соң ул уңайлы җылы аяк киеменә әверелә, – дип сөйли Ләлә Шамил кызы. – Киез аяк киеме җитештерүдә күп эш элеккечә кул хезмәте белән башкарыла. Станоклар, тетү-чистарту аппаратлары, пресслар – кирәкле җиһазлар, әлбәттә, аларның булуы яхшы. Әмма машина эше белән генә бетми. Итекнең баштагы заготовкасы, ярымфабрикаты хатын-кызлар кулы белән эшләнә. Әзер киез итекнең сыйфаты аларның һөнәри осталыгына бәйле, шуңа күрә дефектларны булдырмау мөһим. Һәм кул хезмәте таләп итә торган мондый эшләр бик күп.

КИЕЗ ИТЕКЛӘР ТӨРЛЕ БУЛА

– Кара, ак, кызыллар... Әле соры, яшел, зәңгәре дә бар, – дип, генераль директор Ләлә Шәрипова берничә дистә төсмердән гыйбарәт палитраны күрсәтә. – Заказ булса, без теләсә кайсы төскә буйый алабыз. Әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, классик төсләр күбрәк популяр. Аяк киеме төрле бизәкле дә, чигүле дә, үкчәле һәм уңайлы табанлы да булырга мөмкин.

Сүз уңаеннан, күпләр Кукмара киез итекләрен нәкъ менә табаны аркасында югары бәяли. Аны термоэластопласттан ясыйлар. Ул сыгылмалы, ярылмый, җылыны яхшы тота, карда таймый һәм суыкта да катмый. Махсус киез аяк киеменең табаны ябыштырылып кына калмый, ә кирәкле калып буенча пресс астында кысып тотыла. Протекторның җаның теләгән рәсемен һәм төсен сайлап алу мөмкинлеге бер нәрсә, мондый аяк киеме әле һич тузмый да.

БАРЫСЫН ДА ЭШКӘ

Эшләп чыгарылган продукциянең зур өлешен киез эшләнмәләр алып тора. Киез җитештерү юнәлеше комбинатта 1981 елда ачыла. Үз вакытында ул СССРда Германия, Польша һәм Япониядән кайтартылган иң заманча җиһазлы бердәнбер эксперименталь җитештерү урыны була. Предприятие тулы цикллы – йонны юудан башлап, киптерү, тетү һәм түшәүгә кадәр. Хәзерге көндә дә Кукмара киез итек комбинаты – Россия аяк киемнәре фабрикаларын киез белән бердәнбер тәэмин итүче. Моннан тыш, биредә тирмә киезе дә эшләнә. Кукмаралылар ай саен төрле төрдәге 20 тонна киез җитештереп сата.

Нәкъ менә киез җитештерү комбинат җитәкчелеген тегелгән аяк киеме эшләп чыгара башлауга этәрә, ә мондый аяк киеменә соңгы елларда ихтыяҗ үсә. Әүвәл 5 тегүчедән башлыйлар, ә аннары эш үсә бара. Дизайнер алалар. Өряңа төрле аяк киеме булдыралар. Хәзер яңа модельләрне ике дизайнер иҗат итә, йөздән артык кисүче һәм тегүче җитештерә.

ВАКЫТ СЫНАГАН ҺӘМ МОДАЛЫ

Биредә элекке кебек үк елына 1,2 миллион пар киез итек эшләп чыгара алалар. Әмма бүген ул Кукмара продукциясенең өчтән бер өлешен генә тәшкил итә. Сатып алучылар арасында киездән тегелгән аяк киеме бөтен дөнья күләмендә популярлаша бара. Мондый аяк киеме үзенең элгәрләреннән иң элек яхшылап уйланылган заманча дизайны белән аерылып тора. Нәфис ярымитекләр, ботинкалар, кроссовкалар, җиңел кедлар... Комбинат продукциясе ас-

сортиментында ачык өсле аяк киеме генә юктыр, мөгаен.

Заманча трендлардан калышу ярамавын аңлап, кукмаралылар махсус күргәзмәләрдә даими катнашып тора. Алар барлык модалы тенденцияләр һәм яңалыкларны күзәтеп бара. Шундый яңалыкларның соңгыларыннан – кедлар һәм лоферлар. Боларның беренчесе бик җылы, таймый торган табанлы, урамга да киеп чыгарга була, бина эчендә алмаш аяк киеме сыйфатында да кулланырга мөмкин. Ә лоферлар фасыллар алышынгандагы коры көннәр өчен бик ярап куя.

Бөтен Россия өчен югары сыйфат символына әверелгән киез итек – Кукмараның үзендә гадәти аяк киеме, аны кышын балалар да, өлкәннәр дә, эшчеләр дә, модага ияручe гүзәл хатын-кызлар да бик ярата. Чөнки киез итек – төрле яшь категорияләрендәге кешеләр кия торган һәм киләчәктә дә киячәк аяк киеме. Алар яшьләргә дә, өлкәннәргә дә, шәһәр халкына да, авыл кешеләренә дә үзләрен бер үк дәрәҗәдә җылыда хис итәргә мөмкинлек бирә.

Иң мөһиме – Кукмара киез итек басу-киез комбинаты хезмәткәрләре, бер ярым гасырлык тәҗрибәгә карамастан,без түземсезлек белән көткән яңа эшләнмәләр ясау нияте белән янып эшли.

САННАР ГЫНА

Елына **1 млн 305 мең кг** йон

Ә бу:
көн саен **1917 сарыкның йонын** кырку дигән сүз

Елына **562 мең пар аяк киеме**

Ә бу:
Кемерово, Оренбург халкы яки Уфа белән Самараның яртысы

Елына **162 мең кг** киез сату

Ә бу:
22 футбол кыры мәйданы дигән сүз

БЕЗНЕҢ АЯК КИЕМЕН КИЯЛӘР:

Мәскәүнең һәр **22 нче** кешесе

Россиянең һәр **261 нче** кешесе

«КУКМАРА КИЕЗ ИТЕК БАСУ-КИЕЗ КОМБИНАТЫ» АҖ КОМПАНИЯСЕНЕҢ ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

1867 елда нигез салына. Кукмараның беренче эшмәкәрләре– бертуган Комаровлар. Гаилә башлыгы Василий Алексеевич бу эшнең башында тора. Әтисенең эшен – киез аяк киеме җитештерүне уллары Николай һәм Сергей Комаровлар дәвам итә.

Хәзерге вакытта комбинатта 500дән артык кеше эшли. Бер ел эчендә алар 350 мең пар киез аяк киеме җитештерә. Комбинат продукциясенең өчтән берен тәшкил иткән киез итекләрдән тыш, монда бурка, ботинка, кроссовка, итекләр, баш киемнәре, валешлар, мунча комплектлары, юрганнар да бар...

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

Күпләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоннар: (84364) 2-08-31
8-800-250-11-32

Фирма кибете
Адрес: Кукмара шәһәре, Вахитов ур., 1
Телефон: (84364) 2-08-78

ҖИДЕ КАТЛЫ ТАРИХ

Советлар Союзы күптән юк инде, әмма аның иң шәп идеяләре, чын проектларда гамәлгә ашырылып, яшәүләрен дәвам итә. Мәсәлән, С.П.Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинатында (ККК).

Автор: Ксения Семина

Узган гасырның 90 нчы елларында комбинат директоры Сергей Титов кабинетына керүчеләрне Ленин портреты каршы алган. Бөтендөнья революциясе юлбашчысының карашы күпләрне тартынырга мәҗбүр иткән. Крестьян гаиләсендә туган, тормышка юлламаны совет белем бирү системасы аркасында алган Титов күмәкләшү идеясе яклы, моның өстенә, зирәк, алдан күрүчән стратег та булган.

Якынлашып килгән хосусыйлаштыруның нәтиҗәләрен алдан сиземләгән Титов инициативасы белән 1991 елда комбинат күмәк предприятие статусын алган. Эшчеләр аның милекчеләренә әйләнгән. Предприятиене «прихватизаторлар» кулына эләгүдән исә «Промстройбанк» төзелеш өчен биргән һәм әле түләнеп бетмәгән кредит саклап калган. Башкалар кебек авырлыклардан куркып калмыйча, Сергей Титов киләчәктә дә үз коллективын әллә ничә тапкыр җиңүгә ирештергән. Комбинатта ул 1980 елда беренче нигез ташы салынган көннән алып 2011 елда вафат булганчы эшләгән.

«АКЧАНЫ ҮЗЕГЕЗ ЭЗЛӘГЕЗ!»

Комбинат үзенең барлыкка килүе белән Сәнәгать төзелеше лагерьлары Баш идарәсенең элеккеге җитәкчесе һәм илдәге целлюлоза-кәгазь тармагының баш идеологы, СССР Министрлар Советы Дәүләт комитеты рәисенең матди-техник тәэминат буенча урынбасары Георгий Орлов хыялына бурычлы. Ул үзенең бөтен гомерен совет целлюлоза-кәгазь сәнәгатен булдыруга багышлаган. 1980 нче еллар башында Орловка инде сиксән яшь тирәсе булган. Әмма әле аның барыбер СССР Дәүләт тәэминаты комитетында үзенең грандиоз планын раслатырлык сәяси абруе җитәрлек булган: ул илдә макулатура чималында эшли торган җиде комбинат төзетүгә рөхсәт алуга ирешкән.

Шул предприятиеләрдән берсе – Яр Чаллыдагы комбинат. Анда икенчел чималдан картон һәм сырлы картон, шулай ук елына 50 мең тонна бәдрәф кәгазе җитештерү планлаштырылган. Төзелеш башланыр алдыннан исә СССР Дәүләт тәэминат комитетының яңа башлыгы проектка акча бирүдән баш тарткан. «Акча юк һәм булмаячак та! Төзергә телисез икән – үзегез эзләгез!» – дигән ул Орловка. Беркайчан да чигенергә күнекмәгән Орлов финанс проблемасын хәл итү өчен башка юллар эзләргә тотынган. Һәм тапкан да: «Промстройбанк» пеня һәм штрафлардан тупланган һәм ил бюджетында бүленми торган акчадан кредит бирергә ризалашкан. Комбинат әлеге кредитны түләп бетерү бурычын тулысынча үз өстенә алырга тиеш булган. Коллектив бу шартка ризалашкан. Комбинат төзелә башлаган. 1986 елда сырлы картон җитештерүнең беренче чираты тантаналы төстә ачылган. Ә рулонлы (төргәкле) бәдрәф кәгазенең беренче ике вагоны 1988 елда заказчыларга барып ирешкән.

Тик менә 1990 нчы елларда бәдрәф кәгазе илдә популяр товарлардан саналмаган шул әле. Үзгәртеп коруга кадәр аңа бәя Мәскәүдә бил-

1

гелəнгəн. Чаллы комбинатында җитештерелгəн төргəк 30 тиен, ə җəмəгать транспортында билет 5 тиен торган. Халык билгеле максатларда газетадан файдалануны кулайрак күргəн. Шунлыктан комбинатта əлеге цивилизация казанышын популярлаштыруның иң нəтиҗəле ысулы – аны арзан бəядəн сату, дигəн карарга килгəннəр. Шул рəвешле эконом класслы кəгазь җитештерү стратегиясе формалашкан. Җитештерүне тамырдан үзгəртеп кору, яңа кыйбатлы җиһазлар сатып алу, хезмəткəрлəрне укыту талəп ителгəн. Планлаштырылган күлəмгə чыгу өчен алты елга якын вакыт киткəн.

Хəзер Чаллыда җитештерелгəн бəдрəф кəгазе төргəгенең күплəп сату бəясе 12 сум тəшкил итə. Чаллы җəмəгать транспортында йөрү исə 25 сум тора. Комбинат шул ук җитештерү мəйданнарында, шул ук сандагы персонал белəн проект куəтен өч тапкырга арттырган. Табигый ки, продукциянең үзкыйммəте кимегəн.

КАРТОН СƏНГАТЕ

Бервакыт Плеханов исемендəге Россия икътисад академиясендə берничə ай буе безнең Самосырово чүплегендəге калдыкларны өйрəнгəннəр. Нəтиҗə шуны күрсəткəн: бирегə ел буена китерелгəн макулатура Чаллы комбинатын ел буена чимал белəн тəэмин итəргə җитəрлек икəн. Əлеге мəгълүмат Татарстан җитəкчелегенə җиткерелгəн. Татарстанда макулатура җыю һəм сортларга аеру системасын яхшырту мəсьəлəсен өйрəнү буенча махсус комиссия төзелгəн. Нəкъ менə Чаллы картон-кəгазь комбинаты кебек предприятиелəр пəйда булу белəн, халык хуҗалыгында икенчел чималны киң куллану башланган. Үз чиратында комбинат исə игътибарын технологиялəрне камиллəштерүгə юнəлткəн.

«Шаяртасызмы? Ак картон тартмалар? Аларны йөкчелəр шундук пычратачак бит!» – комбинаттагы ноу-хау – күрəн түгел, бəлки ап-ак тышлы картон тартмаларны күргəзмəлəрдə якынча шундыйрак сораулар белəн каршылаганнар. Җитештерүчелəр ак төснең өстенлеклəрен аңлаганчы шактый вакыт үткəн. Сəүдə залындагы ак тартмалар сатып алучыда күрəненə караганда күпкə уңайрак тəэсир калдыра.

Икътисадый яктан катлаулы 1990 нчы елларда мондый новациялəр мордарлыкка тиң була, əмма комбинатта яхшы аңлыйлар: башка юл юк, өр-яңа базар булдырып кына, уңышлы килəчəккə өметлəнеп була. Моннан тыш, компания өр-яңадан башлауга күнеккəн инде. Биредə илдə беренче булып үзебездə җитештерелгəн тармак җиһазларын эшлəтеп җибəрүне, полиграфия өчен гаять катлаулы һəм иң заманча технологиялəр талəп иткəн сырлы картонга сурəт төшерүне үзлəштерəлəр, заказчыларның техник биреме буенча дизайн эшлəү өчен үзлəренең конструкторлык бюросын булдыралар.

Ягъни бары тик чит ил компаниялəре генə шөгыльлəнгəн (əле алар да үзлəре түгел, бəлки подрядчылары эшлəп биргəн) эшлəрне башкаралар. 1998 елда комбинат БДБ иллəрендə беренче булып ул чакта иң алдынгы гофромашина сатып ала. Тармак өчен бу революцион адымга əйлəнə – башка җитештерүчелəр дə хуплаганга, кəгазь-картон сəнəгате яңа дəрəҗəгə күтəрелə. Россия предприятиелəрен агач тартманы картонга алыштырырга өйрəтү дə җиңел генə бармый, əмма бу миссия дə уңышка ирешə.

2014 елдан башлап комбинат картон ясый торган машинаны модернизациялəү белəн шөгыльлəнə (бу 50 миллион еврога төшə), нəтиҗəдə Чаллы ККК дөньяның иң яхшы картон һəм сырлы кəгазь җитештерүчелəренең беренче өчлегенə кертелə. Һəм болар барысы да – бары тик үз акчаларына.

Комбинатның бүгенге хəлен сурəтлəү өчен, берничə факт китерик. Биредə үзлəренең социаль базалары – профилакторий, Балалар мəдəният сарае, ял базасын саклап калганнар. Җитештерүне модернизациялəүгə инвестициялəр елына 10 миллион евродан да ким түгел. ККК шəһəрдə, тармакта һəм республикада иң югарылардан булган уртача хезмəт хакы белəн дə мактана ала. Шуңа дивидендлар да өстəлə, аны предприятие акционеры булган барлык хезмəткəрлəр ала. Һəркемнəн – сəлəтенчə, һəркемгə – хезмəтенчə.

1 Бəдрəф кəгазе җитештерү. 1980 нче еллар ахыры.

2 Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шəймиевнең комбинатка сəфəре.

3 Беренче генераль директор Сергей Павлович Титов.

«ЭШКӘ БАРА КОЛХОЗ БАТЫРЛАРЫ...»*

1930 елда оешкан Сталин исемендәге колхозның варисы – «Кама» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы Балтач район үзәгеннән төньяктарак, утыз чакрым ераклыкта урнашкан. Бүген анда хезмәт итүчеләр кырчылык, яшелчәчелек, сарыкчылык һәм сөт терлекчелеге белән шөгыльләнә.

Автор: Алсу Троицкая

КОЛХОЗ ЭШЕН ДӘВАМ ИТЕП

Пыжмара авылы. «Кама» идарәсе бирдә урнашкан. АХҖК рәисе **Рәкыйп Нәҗипов** кабинеты тәрәзәсеннән авыл урамы, мәктәп, аның янына туктаган автобус күренеп тора:

– Тирә-юньдәге авылларда укучылар саны кимегәннән-кими бара. Менә бүгенге көндә аларны укырга бирегә алып киләләр, – дип аңлатып китә рәис. – Мәктәбебез 1978 елда – «Кама» колхозының гөрләп торган чагында салына. Идарә бинасы да безгә мирас буларак күчте, бу бина төзелгәнгә дә 60 ел. Элек бик яхшы төзегәннәр, намус белән...

Бүген «Кама» АХҖК йөздән артык кеше эшли. Ә бит колхозда 450 ләп кеше эшләгән чаклар бар иде. Элек машиналар остаханәсе мөдире булып эшләгән **Фаяз Кадимов** та моны яхшы хәтерли:

– Сәяси укулар буенча бер дәрестә безнең авыл укытучысы Зөбәер Юнысов без, яшь колхозчыларга, болай диде: «Авыл кешеләренең күпләп шәһәргә күченгән вакытлар җитәр, авыл бушап калыр». Ул чакта шәһәрлеләрне кем ашатыр соң дигән соравыбызга кулларын гына җәеп җибәрде. Менә бүген, ничә еллар үткәч, мин аның хаклы булуын таныйм. Яшьләр калмый... Бүген «колхоз» дигәндә күпләр пенсионерлар гына яшәгән авылны күз алдына китерә. Кызганычка каршы, аның бу сүзләрендә хаклык бар...

Аның сүзләре белән **Нәкыйп Галимуллин** да килешә:

– Мин күп еллер колхоз фермасында зоотехник, соңрак мөдир булып эшләдем. Безнең колхоз гел алдынгылар рәтендә йөрде, социалистик ярышларда ирешкән югары күрсәткечләр өчен берничә мәртәбә күчмә байрак алды. Сүз уңаеннан бүген АХҖК колхоз эшен дәвам итеп, күп нәрсәне үз җилкәсендә калдырды. Грантларда, милли проектларда катнашу өчен заявкалар бирә, үзәк су системасын, юлларны карап тота, мәктәпкә, балалар бакчасына, ФАПка булыша, сабантуйлар үткәрә, мәчет, чиркәүгә иганә ярдәме күрсәтә. Авылдашлар мөрәҗәгать итсә, терлек азыгы, ашламалар белән дә ярдәм итә. Кирәк икән, процент-

Автор фотолары

* «Уянсыннар кырлар» җырыннан. Салих Сайдашев музыкасы. Әхмәт Файзи сүзләре.

сыз ссуда биреп, акча белән булыша. Ә менә колхозчылар, дөресрәге авылда үз эшен ачучылар, элеккегеләр кебек түгел инде. Алар уртак эш турында уйламый, үз җайларын гына кайгырта. Совет чорында без ничек яши идек соң? Барысы да күмәк, уртак иде, бөтен нәрсә өчен дә уртак җавап бирә идек. Ә хәзер үзенә эшләгән кеше, мәсәлән, авыл урамын чистарту кебек эшләр турында кайгыртмый.

ЯШӘҮ КҮҢЕЛЛЕРӘК

Әмма шулай да совет чорын идеаллаштыру дөрес үк булмас, дип саный элеккеге колхоз хисапчысы **Нургаян Сафин**:

– 60 нчы елларның икенче яртысына кадәр совет колхозчылары «таякка» эшләде, эш көннәре өчен хезмәт хакын натуралата, гадәттә ашлык белән ала иде. Җайлы, әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, авыл хуҗалыгын күтәрүнең нәтиҗәле булмаган ысулы. 1966 елның маенда хөкүмәт кабул иткән карардан соң барысы да үзгәрде. Карар буенча авылда хезмәт иткәнгә акчалата түләү гарантияләнде. Колхозчының иртәгәсе көнгә ышанычы артты. Әгәр без ул чакта 100 сум акча алганбыз икән, ул тормыш итәргә дә, депозитка салырга да җитә иде.

ТАРТЫП АЛЫРГА ҺӘМ БҮЛӘРГӘ

– Механизаторлар да яхшы хезмәт хакы ала башладылар, техника күп иде, эше дә, – дип өсти **Наил Зәкиев**. – Үзегез беләсез, белем алу түләүсез, медицина хезмәте шулай

үк бушлай, шифаханәләргә юлламалар бирәләр. Ә аннан соң үзгәртеп кору күп кешене шәһәргә куды. Запас частьларны, техниканы кайтару планы өзелде, ягулык-майлау материалларына бәяләр котырып артты. Хакимиятнең бер генә бурычы калды – тартып алырга һәм бүләргә. Колхозга исән калу өчен тырышырга туры килде. Ул вакыттагы хәлләрне искә төшерәсе дә килми...

ТӨП КАПИТАЛ

Ул болгавыр заманнарны «Кама» колхозы исән-имин үтә. 2001 елда авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы итеп үзгәртелеп, ул берничә мәртәбә эш юнәлешен үзгәртә.

Әгәр элек хуҗалык составына алты авыл кергән булса, бүген алар дүртәү генә калган. Җир пайларының бер өлеше шәхси кулларга һәм крестьян-фермер хуҗалыкларына күчкән. Әмма, «Кама» рәисе Рәкыйп Нәҗипов фикеренчә, совет чорыннан калган нәрсәләр бүген кооперативка бик булыша:

– Сүз дә юк, биналарны, корылмаларны, авыл хуҗалыгы предприятиесе инфраструктурасын өр-яңадан кору – бер хәл, ә булганыннан гына файдалану – икенче. Реконструкциягә, яңа технологияләргә, яңадан коралландыруга акчалар тотуга да карамастан... Ләкин иң күңелсезе шул: авылда гомер-гомергә төп капитал кеше булган. Ә алар элеккегечә читкә китү ягын карый. Һәм мондый хәл минем туган колхозымда гына түгел, бөтен ил буенча күзәтелә...



БЕР, ИКЕ, ӨЧ! БЕЗНЕҢ КУЛДА – КӨЧ!

Урамда күңелле музыка яңгырый. Спорт костюмы кигән егетләр һәм кызлар күнегүләр ясый, сикергәләп-йөгергәләп ала. ГТО буенча алтын значок алыр өчен соңгы нормативны тапшырырга җыена алар.



Автор:
Олеся Бондаревская

Стадион Әлмәт шәһәрендәге Татар республика физик культура техникумы янәшәсендә генә урнашкан. Әзерләнүчеләр арасында техникум студенты 16 яшьлек Миңнеразый да бар.

Әтисенең беренче мәртәбә Сабан туенда батыр калу көнен хәтерли әле ул. Шуны уйлыйуйлый йөгерергә әзерләнә. Ул чакта әтисенә төп бүләк – тәкә һәм тагын гореф-гадәт буенча яңа өйләнешүчеләрдән чиккән сөлге тапшыралар. Җиңү, шатлык, көч – егет өчен бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр.

– Ну нәрсә, әзерме? – дип, егетнең җилкәсенә кагып ала тренеры. Әлбәттә, әзер. Старт бирелүгә ул алга омтыла – җиңел итеп, шатланып йөгерә.

– Яхшы! – дип кычкыра финишта вакытны теркәп торучы тренер. Нәтиҗә – 2,58! Соңгы норматив тапшырыла. Берничә көннән 16 яшьлек Миңнеразыйга тантаналы линейкада ГТО буенча алтын значок тапшыралар. Урамда – 1968 ел. Бу аның беренче ГТО значогы була.

ХЕЗМӘТ ҺӘМ ОБОРОНА

Героебыз үзен башкалардан аерылып торган кеше дип санамый, чөнки ул вакытларда «Сәламәт тәндә – сәламәт рух» шигаре җәмгыятьтә лаеклы урын табарга, хөрмәткә ирешергә теләгән һәркем тормышында зур роль уйный. Ә значок алу бик абруйлы санала, чөнки аңа ирешкән егетләр киләчәктә солдат – Ватанны саклаучы булачак. Рәсми рәвештә 1931 елда расланган ГТО комплексының бурычы шундый сакчыны әзерләү була да инде. Аның максаты «Совет кешеләренең, беренче чиратта яшь буынның физик тәрбия һәм мобилизацион әзерлеге дәрәҗәсен алга таба да күтәрү» була. Беренче елларда алтын һәм көмеш значокны миллионлаган совет кешесе ала – мәктәп укучысыннан башлап пенсионерларга кадәр. «Әгәр спорт яратмасам, значокка ия булмасам, мин Берлингача барып җитә алыр идемме икән!» – әлеге сүзләрне Бөек Ватан сугышы Герое Иван Копылов әйтә.

Әлмәт янындагы авылда туып-үскән Миңнеразый әтисеннән үрнәк ала һәм спортның барлык төрләре буенча уңышка ирешергә омтыла. Армиягә чакыру кәгазе киләчәк көн турында хыяллана һәм медкомиссияне уңышлы үтү өчен ныклап спорт белән шөгыльләнә. Значок алып, Миңнеразый үзенең көчен, сәламәт булуын раслый. Үз-үзенә булган ышанычы иптәшләре арасындагы абруен күтәрә. Матур кызлар аның белән очрашырга тели, урам малай-шалайлары аңа бәйләнми. Чакыру комиссиясен үтеп, ул Мари Элга солдат хезмәтенә китә, спорт ротасына билгеләнә. Гомумгаскәри әзерлектән тыш, әлеге ротада хезмәт итүчеләр спорт белән дә шөгыльләнә, төрле ярышларда полк намусын яклый. Миңнеразый ике мәртәбә Идел буе хәрби округы беренчелегендә призер була. Армиядән соң бокс буенча спорт мастеры исемен ала һәм спортта профессиональ эшен туган ягы Әлмәттә дәвам итә.

ТОРМЫШНЫҢ АЛТЫН БИЛГЕСЕ

2021 елның февралендә Миңнеразый Хәйдәров яңадан ГТО дип язылган стенд янында басып тора. Хәзер инде Әлмәт физик культура көллияте (ул укыган техникум бүген шулай дип атала) укытучысы һәм эксперт сыйфатында. Көллияттә Бөтенроссия ГТО физкультура-спорт комплексы фестивале оештырыла. Ярышларда катнашучы 180 студент арасыннан 31 кеше нормативларны алтын значокка тапшыра. Калганнарына көмеш һәм бронза значоклар бирелә.

– Соңгы елларда спортка һәм армиядә хезмәт итүгә кызыксынуның кабат уяна башлавын күрәм. Безнең егетләр хәмер, наркотиклар белән мавыкмый. Күпләр өчен спорт – тормыш рәвеше

һәм булачак профессия. Бу аларның үзләренең, эти-әниләренең һәм без – педагогларның системалы эше нәтиҗәсе, – дип аңлата Миңнеразый Мөнир улы.

Ул үзе дә спорт белән шөгыльләнүен дәвам итә. 2014 елда ГТО комплексын рәсми рәвештә яңадан кайтарганнан соң, Миңнеразый Мөнир улы шунда ук нормативлар тапшыра – ГТО буенча алтын значокка. Беренче тапкырдан ук буйсынмаган бердәнбер дисциплина – пневматик винтовкадан ату, 10 метр ераклыктан. Әмма бераз шөгыльләнгәннән соң, спортчы мөмкин булган 50 очкодан 47не җыя.

– Минем һәр көнем 50 тапкыр чүгәләүдән һәм 2–3 чакрым йөгереп кайтудан башлана. Кышын авылга кайтам һәм чаңгыда шуам. Нindидер аерым диеталар тотмыйм, әзрәк ашарга тырышам, – ди Миңнеразый Мөнир улы. – Гади күнегүләрне өйдә эшләргә мөмкин, иң мөһиме – даими шөгыльләнергә кирәк, ялкауланмаска. Бу сәламәт яшәү рәвешенең гап-гади нигезе. Безнең кешеләрнең үзләренең сәламәтлекләре һәм гомерләренең озынлыгы үз кулларында булуын аңлау вакыты тиздән килеп җитәр, дип уйлыйм.

ГТО НОРМАЛАРЫ: СССРДА һӘМ БҮГЕН
16 – 18 ЯШЬЛЕК ҮСМЕРЛӘР
АЛТЫН ЗНАЧОК

1972 ел

Йөгерү 100 м (с) **13,5**

1000 м (мин., с) **3,20**

Озынлыкка сикерү (см) яисә Биеклеккә сикерү (см) **280/135**

700 г лы граната ыргыту (м) яисә 5 кг лы туп ыргыту (м) **40/10**

Чаңгыда йөгерү, 5 км (мин.) яисә 10 км (мин.) **25/52**

Марш-бросок, 6 км (мин.) яисә Велосипед кроссы, 20 км (мин.) **32/46**

Йөзү, 100 м (мин., с) **1,45**

Аркылы борыста тартылу (тартылу саны) яисә Аркылы борыска таянып көч белән әйләнү **21/4**

Туристлык күнекмәләрен һәм урында ориентлашуны тикшерү (км) **20 км лы бер сәяхәт яисә 12 км лы 2 сәяхәт**

Сугышчан коралдан ату – башлангыч хәрби әзерлек программасы буенча башлангыч күнегү – **«яхшы» билгесенә**

Автомобиль, су-мотор, мотоцикл, планер, парашют, самолет, вертолет, су асты спорты, биатлон, ядрәдән ату, радиоспорт, ориентлашу, көрәш (барлык төрләре), бокс яисә спортның теләсә кайсы төре буенча спорт разряды **III/II**

2021 ел

Мәҗбүри сынаулар

Йөгерү, 30 м яисә 60 м яисә 100 м (с) **4,4/8,0/13,4**

3000 м (мин., с) **12,4**

Биек аркылы борыста тартылу яисә 16 кг лы гер күтәрү яисә Яткан килеш таянып, кулны бөгү һәм турайту (башкару саны) **14/33/42**

Гимнастика эскәмиясендә баскан килеш алга таба иелү (эскәмия биеклегеннән, см) **+13**

Сайлап булган сынаулар

Бер үк арaны берничә мәртәбә алга-артка таба йөгереп үтү, 3х10м **6,9**

Ераклыкка сикерү яисә, Ике аяктан этелеп, баскан урыннан ераклыкка сикерү (см) **440/230**

700 г лы спорт снарядын ыргыту (м) **35**

Йөзү, 50 м (мин., с) **0,50**

Утырган һәм баскан килеш пневматик винтовкадан ату (очколар) **25**

Коралсыз үзеңне яклау (очколар) **26–30**

Туристлык күнекмәләрен тикшерү буенча сәяхәт (км) **10**

Алтын значок алу өчен 4 мәҗбүри нормативны һәм 5 сайлап алынганын үтәргә кирәк.

«АВЫЗ ИТЕП АРА-ТИРӘ, АХУН КИЛӘ АВА-ТҮНӘ...»*



«Возрождение» үзәгендә исерек кешеләргә, сәрхүшләргә ярдәм күрсәтелә. Совет айныткычларының тиңдәшеме ул? Әйе дә, юк та.

Автор:
Ольга Туманская

«Җылы кабул итүегез өчен рәхмәт белдерәм». «Аңлаганыгыз өчен рәхмәт». «Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт. Бик тетрәндергеч». Тигезле-тигезсез хәрефләр, калтыранган куллар белән язылган әлеге «Шикаятьләр һәм тәкъдимнәр кенәгәсе»ндә шикаятьләр дә, тәкъдимнәр дә юк. Анда барлык язулар да «рәхмәт» сүзеннән башлана.

– Бу кенәгә битләрендә, барыннан да элек, кешеләргә мөнәсәбәтебезне күрергә мөмкин, – ди Михаил Игнатьев. Әнә шулай дип җавап бирде үзәкнең директоры минем: «Возрождение» һәм совет айныткычлары арасында төп аерма нәрсәдә?» – дигән соравыма.

БЕЗГӘ АЙНЫТКЫЧЛАР КИРӘК

– Шулай да уртак якларыбыз бар, – дип дәвам итә ул. – Сүз төп максат турында бара. Мөстәкыйль рәвештә йөрерлек хәлдә булмаган яки үзләренең кайда икәнлеген чамалый алмаган, әмма медицина ярдәменә мохтаҗ түгел исерек кешеләрне урамда калдырырга ярамый.

Сүз уңаеннан, бу мәсьәләдә Игнатьев – чын белгеч, чөнки ул кайчандыр Казан шәһәренең Совет районы Эчке эшләр идарәсе карамагындагы Медицина айныткычы башлыгы булып эшләгән. Тик 2011 елда Россиядә Эчке эшләр министрлыгы реформасы башлана һәм айныткычларны бетерәләр. Бераз вакыттан соң исә бу карарның ялгышлыгын таныйлар. 2017 елның июнендә Президент Рөстәм

Фото: Александр Ефремов

* Гамил Афзал. «Тотып җибәр, апаем...»

Миңнеханов Татарстанда муниципаль айныткычлар эшчәнлеге турында закон имзалый.

Моның сәбәбе бик гади була. Урамдагы исерек кешеләрне хастаханәләргә алып баралар. Ә тагын кая алып китсеннәр инде аларны? Нәтиҗәдә, табибның игътибары еш кына дөрес кешегә юнәлтелми, чөнки андый «пациент»ларның 80 процентына медицина ярдәме кирәкми дә. Моннан табиблар гына түгел, ә чыннан да ярдәм таләп ителгән затлар да зыян күрә.

«Возрождение»нең фойесында диварлар хәмер зыяны турында агитплакатлар белән бизәлгән – алар совет елларында әлеге бинада урнашкан иске айнытычтан калган. Кечкенә генә тәрәзәле палаталарның галәмәт зур ишекләре дә – шул чор сәламе.

– Болар – чып-чын совет мирасы. Элек айнытычларның ничек эшләгәнен аңласыннар өчен, без аларны махсус калдырдык, – дип сөйли Игнатьев. – Ишекләр тыштан бикләнә иде, «Эчәсем килә!» яки «Бәдрәфкә барам!» дип шакырга кирәк…

Бүген бу бүлмәләр бикләнми. Эчкә күз салабыз – анда берничә кушеткадан башка берни дә юк. Бөтен җиһазлар да тәбәнәк һәм идәнгә беркетелгән. Аларны күтәрә дә, идәннән кубарып, дөбер-шатыр тавыш та чыгара алмыйсың, караваттан егылып җәрәхәтләнү дә мөмкин түгел. Болар барысы да – үзәккә килүчеләрнең куркынычсызлыгы өчен.

«КЛИЕНТ»НЫҢ ПОРТРЕТЫ

Әйе, әйе, без дөрес ишеттек – «килүчеләр». Монда шактый салмыш кешеләрне нәкъ менә шулай дип атыйлар. Элекке кебек «эләккәннәр», «тоткарланганнар» бөтенләй юк.

– Сүз уңаеннан, «Возрождение»дә шау-шу, гаугa куптарган кеше булганы юк, – дип сөйли Игнатьев. – Ә кешечә мөнәсәбәт күрсәтелә икән, ник әле котырырга, ди? Асоциаль элементлар да биредә күренми диярлек, безгә килүчеләрнең күбесе – гап-гади кешеләр. Үз көчләрен чамалап бетермәгәннәр – бу хәл һәркем белән булырга мөмкин.

Игнатьев күптәнге кызык вакыйганы искә ала. Ул чакта аларның «Советский» айнытычына ике опера җырчысын китерәләр. Сәнгать кешеләре икәнлеге иртән, бу тыныч, зыялы затлар уянгач кына ачыклана. Анкетада кайсы тармакта хезмәт итүләре турындагы сорауга җавап айнытыч хезмәткәрләрен шикләндерә. Әнә шул чакта айнытыч коридорында опера партиясен җырлап җибәрмәсеннәрме?..

Бүген Ярдәм үзәге көненә уртача 8–10 кеше кабул итә. Ел башыннан, тулыр-тулмас 11 ай эчендә, монда мең ярымнан артык кеше булган. Эш җитәрлек. Хәер, совет чорында Казанда мондый айнытыч белән һәр район мактана алган. Нәрсә булган соң – әллә азрак эчә башлаганнармы?

– Мөгаен, культуралырак эчә башлаганнардыр, – дип җавап бирә Михаил Игнатьев. – Өстәвенә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау да кешеләргә тәэсир итә. Спорт заллары, бассейннар, искиткеч парклар – чәркәханәдә сыйланып утыру урынына буш вакытны бик файдалы итеп уздырырга мөмкинлек биргән урыннар күп бездә.

Игнатьев хәтта Яңа ел бәйрәмнәрендә дә килүчеләр саны бик артыр дип уйламый. Аларның эшендә хәзер сезонлылык юк, һәм бу җәһәттән җомга дүшәмбедән аерылмый. Барысы да гадәти режимда, планлы рәвештә – үзәк һәр көнне, тәүлек буе эшли.

ЯЛ ИТ, АХИРӘТ!

– Сезгә эләккән кешегә нәрсә яный? – дип сорыйм Игнатьевтан.

– Бернәрсә дә янамый!

Былтыр «Возрождение» үзәгенә сиксән яшьлек бабайны китерәләр. Исерер өчен карт кешегә күп кирәкми инде, дип аны акларга тырыша Михаил. Өй адресын белешеп караганнар – бабай искә төшерә алмаган. Бәхетсезлек очракларын теркәү бюросында оператор актив эшкә керешә. Ак киез итекләр төп билге була!.. Әнә шул билге буенча туганнарын табалар да. Алар инде дөнья бетереп эзлиләр икән бабайны, шундук алырга дип килеп тә җитәләр, тәмле төшләрен ул инде өйдә карап бетерә.

Салмыш кешеләрне ярдәм үзәгенә гадәттә полиция китерә. Хастаханәгә салыр өчен нигез табылмаса, кайчагында «Ашыгыч ярдәм» дә кертеп чыга. Бик сирәк кенә гражданнар үзләре мөрәҗәгать иткән очраклар да була.

Шундый бер хәл күптән түгел теркәлә. «Возрождение»гә ике кыз белән бер егет килә. Алар

1
«Возрождение»дә совет чоры тәҗрибәсен сайлап-сайлап кына алалар, чөнки айнытычларның заманча дәвамчылары Эчке эшләр министрлыгы түгел, ә шәһәр башкарма комитеты карамагында оештырылган.





2

«Шикаятьләр һәм тәкъдимнәр кенәгәсе»ндә шикаятьләр дә, тәкъдимнәр дә юк. Анда барлык язулар да «рәхмәт» сүзеннән башлана.

3

– Элек салмыш кешеләр милиция белән бик очрашмаска тырыша иде. Берәрсе «Ментлар!» дип кычкыра да, кем кая йөгерешә башлый.

кызларның берсен үзәктә калдыруны сорый. Яшьләр ресторанда танышкан икән, бергәләп күңел ачканнар. Бер кыз хәмер күләмен чамалап бетермәгән, аны ярдәм үзәгенә алып килгәннәр дә инде. Иртән үзләре үк килеп, айныган кызны алып та киткән.

– Элек салмыш кешеләр милиция белән бик очрашмаска тырыша иде. Берәрсе «Ментлар!» дип кычкыра да, кем кая йөгерешә башлый, чөнки ул чакта кешене урамнан эләктереп алалар да айныткычка алып китәләр, ә аннан инде бу факт турында эш урынына да, рөхсәт бирү оешмасына да хәбәр итәләр. Бәлки, айныткычка эләккән кешенең рөхсәт белән алынган ау мылтыгы бардыр. Хәзер мондый күренеш, әлбәттә, юк.

Сүз уңаеннан, Бәхетсезлек очракларын теркәү бюросы – үзәк хезмәткәрләре монда килүчеләр турында мәгълүмат җибәрә ала торган бердәнбер урын. Шуннан соң туганнары үзәккә килеп, «артык бәйрәм итеп җибәргән» затны теләсә кайсы вакытта алып китә ала. Совет айныткычларында андый нәрсә рөхсәт ителми. Анда эләккән кеше айныткычта иртәнгә кадәр калдырыла, шуннан соң аңа «җәмәгать урынында исерек килеш күренгән өчен» штраф языла һәм айныткыч хезмәтләре өчен түләү квитанциясе тоттырыла.

Бүген «Возрождение» мондый хезмәтләрне бушлай күрсәтә. Бушлай дип инде, барысы да дәүләт хисабына. Бер яктан караган, ник бушлай әле ул?! Икенче яктан, мондый юмарт гамәл урамнарда бәхетсезлек очракларын һәм җинаятьләр санын киметә, чөнки аңнары хәмер белән томаланган кешеләр еш кына хокук бозуның йә субъектына, йә объектына әйләнә. Ә эчүчелек белән көрәшкә килгәндә, бу мәсьәләдә сәламәт яшәү рәвешен профилактикалау да шактый уңышлы эшли.

«БЕЗДӘН БОЕГЫП КИТМИЛӘР»

– Иртәм нидән башланды? Казан айныткычында башланды ул! – дип хәбәр итә экраннан Елена Малышева.

«Здоровье» тапшыруының алып баручысы 2020 елда «Возрождение»гә экскурсия белән килә, бөтен илне әлеге үзәк белән таныштыра һәм шул рәвешле сәламәтлек саклау өлкәсенең иң көнүзәк проблемасын күтәреп чыга. Без, иртәнге якта баргач,үзәккә кичтән килүчеләрне очрата алмасак, Елена Малышевага бәхет елмая – 37 яшьлек Рәшит аның программасына эләгә.

– Монда сезгә мөнәсәбәт нинди булды? – дип сорый Мәскәү кунагы аңардан.

– Бик шәп.

– Монда ничек килеп эләктегез?

– Тукталышта йоклап киткәнмен...

Елена Малышева тапшыруыннан без Рәшитне игътибарсыз калдырмауларын белдек, хәмергә бәйлелектән котылу өчен, аны дәвалану һәм реабилитация курсы узарга күндерәләр. Әмма ул вакыйганың көтелмәгән дәвамы була.

– Кеше югалган булган, гаиләсез калган, тик бу тапшыруны аның әнисе караган икән, ул исә улы турында инде күптән бихәбәр яшәгән, – дип сөйли Михаил Игнатьев. – Әнә шулай табылды Рәшит!

Сүз уңаеннан, Елена Малышева әлеге үзәкнең бердәнбер кунагы түгел. Казан тәҗрибәсен өйрәнергә Чебоксар, Екатеринбург, Астрахань, Якутия – кыскасы, илебезнең төрле төбәкләреннән киләләр. Ә уртаклашыр нәрсәләр чыннан да бар. Үзәккә килүчеләр өчен нинди шартлар тудырылу дисеңме, күрсәтелә торган хезмәтләрнең тиешле югарылыкта булуы дисеңме...

«Возрождение» бинасында хастаханә исе килә. Операция бүлмәсендәге кебек чисталык саклана. Коридордагы мәгълүмат тактасында – медицина ярдәме күрсәтүгә лицензия. «Без бәби генә таптыра алмый-

4

– Сезгә әләккән кешегә нәрсә яный? – дип сорыйм Михаил Игнатьевтан.
– Бернәрсә дә янамый!

САЛМЫШ КЕШЕНЕ НИШЛӘТЕРГӘ?

– Әгәр сез урамда яткан исерек кешене күрсәгез, иң әүвәл 112 телефонына шалтыратыгыз, – дип киңәш бирә Михаил Игнатьев. – Коткару хезмәте белгечләре сезгә тиешле юлны күрсәтер. Иң мөһиме, кешене игътибарсыз калдырырга ярамый, бәлки, көтмәгәндә аның хәле начарланып китәр (яки инде ул хәзер шундый хәлдә). Аңа кагылмагыз, бергәләп ярдәм килгәнен генә көтегез.

быз бугай», – дип шаярта Михаил Игнатьев. Гомумән, монда һәрнәрсәгә караш җитди: штатта, каравылчыдан тыш, фельдшер һәм исерекләр белән эш итү үзенчәлекләренә өйрәтелгән санитар да бар.

Элек мондый биналарда медицина ярдәме бик аз дәрәҗәдә, сүз өчен генә була. Бүген кабул итү тулы медицина тикшерүеннән башлана. Ә аннары хатын-кызлар – аерым, ир-атлар аерым бүлмәгә урнаштырыла. Бирегә сирәк кенә булса да алып киленгән сукбайлар да аерым яткырыла.

Теләге булганнар биредә үзләрен тәртипкә китерергә мөмкин – чиста ванна һәм санузел бар. Ә аннары кешегә юрган һәм бер тапкыр кулланыла торган җәймә бирелә. Шуннан соң рәхәтләнеп йокы туйдыра аласың! Сүз уңаеннан, монда мендәрләр юк – алар салмыш кеше өчен куркыныч тудырырга мөмкин.

Барлык белемнәр дә совет чоры тәҗрибәсенә нигезләнә. Хәер, «Возрождение»дә бу тәҗрибәне үзләренә сайлап-сайлап кына алалар, чөнки айныткычларның заманча дәвамчылары Эчке эшләр министрлыгы түгел, ә шәһәр башкарма комитеты карамагында оештырылган. Шуңа бәйле рәвештә, эшкә караш та аерыла. Ишек турында хәтерлисезме? Биредә ирексезләүнең бер төре дә хупланмый, СССР айныткычларында котырынган гражданнарны тынычландыру өчен кулланылган «бәйләү методы» турында әйтеп тә торасы юк. Бүгенге тәҗрибә күрсәткәнчә, аерым очраклар өчен полиция чакыру төймәсен файдалану нәтиҗәлерәк, ә кызу канлылыкны, ярсып китүчәнлекне яхшы мөнәсәбәт күрсәтү белән тыеп була.

– Исерек кешегә: «Йә, эчеңне күрсәт әле, бәлки, анда синең бик нык тырналган урыннар бардыр!» – дип әйтеп кара син, «фәләнемә олак» дип җикеренәчәк. Монда һәр кешенең шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, иҗади эш йөртү зарур, – дип сөйли үзәкнең санитары Илсур Лотфуллин. – Кайчагында кешегә аның белән кемнеңдер утырып торуы, сөйләшүе генә кирәк. Янәшәсенә утырасың да әңгәмә корып җибәрәсең. Шуңа күрә без монда барыбыз да диярлек психологлар!

Илсурның узган сменасында үзәккә өлкән яшьтәге бер әбине алып килгәннәр. Аңа сиксән яшь чамасы була. Улы белән ызгышкач, кайгы-хәсрәтен уртаклашырга дип, дус хатыны янына юл тота, тик үзенең хәлен-яшен чамалап бетерми – тукталышта исереп йоклап китә. Шулай итеп «Возрождение»гә китерелә. Илсур белән бик озак сөйләшеп утыра алар, әби күңелен бушата. Ә иртән, йокысы туеп һәм бик канәгать булып, өенә кайтып китә.

– Бездән боегып китмиләр, – дип шаяртып алды Илсур саубуллашканда.



Рәсем1. Агынтылы эжектор куллану технологиясенең схемасы.

«ГАЗПРОМ ТРАНСГАЗ КАЗАН»: ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯ ГАЗНЫ ЮГАЛТУЛАРНЫ КИМЕТӘ

Табигый газ нефть белән бергә Россия Федерациясе сәнәгатенең энергетик нигезен тәшкил итә.

«Газпром» магистраль газүткәргечләре буенча тормыш өчен гаять мөһим углеводородлар ташуны 260 тан артык компрессор станциясе тәэмин итә. Алар составында 400дән артык цех яки дүрт мең ярымнан артык газ кудыру агрегаты бар. Газ ташу эше магистраль газүткәргечләрдә басымны арттыру юлы белән башкарыла һәм түбәндәгеләрдән гыйбарәт: компрессор станциясенә кергән газ механик катнашмалардан чистартыла, газ кудыру агрегатының басым зурайткычында кысыла һәм, суытылганнан соң, юлын дәвам итү өчен газүткәргечкә озатыла. Әлеге технологик процесста котылгысыз югалтулар да бар. Мәсәлән, газ кудыру агрегаты режим буенча яки планлы хезмәт күрсәтү өчен туктатылган очракта, андагы үзәктән куылышлы басым зурайткычның контурында 3 мең кубо-

Фото «Газпром Трансгаз Казан» ЖЧЖ тарафыннан бирелде. Реклама.

метрга якын газ ябылып кала, һәм ул һавага кудырып чыгарыла.

Бер агрегатның ел дәвамында 10–15 тапкыр туктатылуын исәпкә алганда, өч газ кудыру агрегатыннан басым белән чыгарып җибәрелгән ягулык күләме бер елга 140 мең кубометрга җитә.

Шул ук вакытта әлеге өч агрегаттан гыйбарәт цехны тоташтыру вакытында кудырып һавага чыгарылган газ күләме 230 мең кубометр чамасы тәшкил итә.

Аңлашыла ки, әлеге югалтуларның күләме газ-транспорт предприятиеләре тарафыннан эксплуатацияләнә торган цехлар санына пропорциональ рәвештә арта. Шундый зур хезмәтләр куеп табылган, газүткәргечләр буенча меңнәрчә километр узган зәңгәр ягулык өч көн дәвамында сәнәгый, коммуналь ихтыяҗларны канәгатьләндерә һәм республиканы җылыта алган булыр иде, ә аны атмосферага очырырга туры килә.

Бу проблеманы хәл итү максатыннан, «Газпром Трансгаз Казан» җәмгыятендә агынтылы эжектор куллану нигезендә мондый газны кире магистраль газүткәргечкә җибәрү технологиясе эшләнде һәм патентланып гамәлгә кертелде. Технологиянең асылы түбәндәгедән гыйбарәт (рәсем 1). Газ кудыру агрегаты туктатылганнан соң, газны шәмгә чыгарып җибәрер алдыннан, эжекторның (14) керү юлындагы (17) һәм чыгу юлындагы (16) краннары ачыла. Шул ук вакытта кысу коллекторыннан 7,4 МПа басым белән эжектор һәм кран 16 аша бирелгән газ кран 17 аша агып чыга. Эжекторны басым зурайткыч коллекторы белән тоташтырган кран (15) ачылганда, коллектордагы газ суыртып алына.

Газны суыртып алу өчен, 160 кубометр ягулык газы һәм 110 кВт сәгать электр энергиясен сарыф итеп, без 2600 кубометр зәңгәр ягулыкны коткарып калабыз. Табигый газга сакчыл караш күзлегеннән исә, туктатылган компрессор цехыннан газ суыртып алу өчен агынтылы эжектор куллану тагын да нәтиҗәлерәк (рәсем 2).

Бу очракта янга калдырылган газның күләме 180 мең кубометрдан артыкны тәшкил итә.

Шулай итеп, «Газпром Трансгаз Казан» ҖЧҖ белгечләре компрессор станцияләренең туктатылган җиһазларыннан газ суырту технологиясен уңышлы эшләп чыкты. Әлеге технология «Газпром» ГАҖ департаментларының уңай бәяләмәсен алды һәм тармак масштабында куллануга тәкъдим ителде. Казан белгечләренең хезмәте элек саклап калу мөмкинлеге бөтенләй каралмаган һәм бу юнәлештә икътисадый яктан нәтиҗәле ысулны тормышка ашырып булмый дип уйланылган табигый газның 85% ка кадәрен саклап калуны тәэмин итә. Т

Рәсем 2. «Арча» компрессор станциясенә караган Ямбург – Көнбатыш чик цехының технологик тоташтыргычы составында сынау эжекторы.

ТОРМЫШ ХИМИЯСЕ

«Казаныбызда бик яхшы препаратлар ясыйлар. Мазьлары, бигрәк тә күзнеке, бик югары сыйфатлы... Үз эшләнмәләре дә бар, мәсәлән, тукымаларны яңадан торгызу өчен препарат. Мин реклама ясамыйм, ә башкаларның күзен ачарга гына тырышам: үзебезнеке бар икән, ник читнекен сатып алырга соң?» Интернетта бер казанлы илебезнең фармацевтика өлкәсендәге иң алдынгы ширкәтләреннән берсе – «Татхимфармпрепаратлар» АҖ җитештерә торган дарулар турында әнә шундый уңай бәяләмә калдырган.

Пандемиянең кызган чагы күбебезгә бушап калган даруханә киштәләре белән дә истә калачак. Ул вакытта кайбер көннәрдә «ковидны дәвалау» исемлегендәге препаратларны гына түгел, теләсә кайсы гаиләнең дару капчыгында була торган иң гадиләрен дә сатып алып бетерделәр. Фармацевтика тармагына җитештерү күләмен тиз арада арттыру мәсьәләсен хәл итәргә туры килде. Өстәвенә, бу – чималны һәм кирәкле материалларны чит илләрдән китерүне кыенлаштырган карантин чаралары фонында. Бәяләр үсеше дә хәлне катлауландырды.

Предприятиеләрнең барысы да пандемия таләп-бурычларына тиз һәм нәтиҗәле җавап бирә алмады. «Татхимфармпрепаратлар» ширкәтендә исә, вәзгыятьне оператив рәвештә бәяләп, дөрес стратегияне сайлау гына түгел, кыска вакыт эчендә аны тормышка да ашыра алдылар. Предприятие җитештерүне бер көнгә дә туктатмады. Хәзерге вакытта компания иң тулы куәткә эшли һәм препаратларны даими партнерларга кирәк күләмдә җитештерә.

Вируска каршы препаратларга (шул исәптән сәдәп формасындагы «Афлюдол»), ялкынсынуга каршы даруларга, температураны төшерә, йөрәк-кан тамырлары авырулары булганда кулланыла торган препаратларга ихтыяҗ аеруча зур. Даруларның барлык төрләре дә федераль һәм төбәк даруханә челтәрләренә, шулай ук Россиянең һәм чит илләрнең эре дистрибьюторларына уңышлы җибәрелеп тора.

ПАНДЕМИЯ – ӨСТӘМӘ ЭТӘРГЕЧ

Катлаулы икътисадый хәл компанияне инновацияләргә йөз тотуга этәрә. Пандемия вакытында «Татхимфармпрепаратлар» АҖ ирешкән югарылык технологик камилләшүне күздә тоткан күпьеллык планлы процесс нәтиҗәсе булды. Югары технологияле җитештерү базасын булдыру буенча колачлы инвестиция проектларының кайберләре предприятиедә 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәр фармацевтика сәнәгатен үстерү стратегиясе кысаларында гамәлгә кертелә. «Татхимфармпрепаратлар» АҖндә GMP ЕС (Европа Берлегенең

Фотолар «Татхимфармпрепаратлар» АҖ тарафыннан бирелде. Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

җитештерү практикасы таләп иткән стандарт) таләпләренә туры килә торган сәдәп препаратлар чыгару линиясен уңышлы эшләтеп җибәрделәр, шулай ук стериль күз даруларын һәм тәнгә сөртә торган мазь һәм гельләрне җитештерүне җайга салдылар.

Предприятие үз эшен цифрлаштыруны да камилләштерә. Даруханәләрдә ялган дарулар барлыкка килүне булдырмау максатыннан, 2020 елда Россия Хөкүмәте карары белән дару препаратларын махсус маркировкалау гамәлгә кертелде. Җитештерүчеләр продукция кабына махсус тамгалар сала. Бу тамгалар махсус хисап җиһазлары белән укыла. Алар җитештерүче һәм препарат турында тулы мәгълүматны үз эченә ала: монда теркәү таныклыгының хуҗасы, препаратның яраклылык вакыты һәм тасвирламасы, аның сериясе, кап төре һәм препаратның сатуда булу-булмавы күрсәтелә.

Андый маркировкалау линиясе «Татхимфармпрепаратлар» АҖндә дә эшләтеп җибәрелде. Махсус автоматлаштырылган система даруларның җитештерүчедән алып даруханәгә кадәр хәрәкәт этапларын күзәтеп торырга мөмкинлек бирә. Дару турында кодта яшерелгән бөтен мәгълүмат базардагы барлык даруларның гомуми базасында да бар. Сатып алучы смартфон өчен бушлай кушымта ярдәмендә шушы каптагы даруның статусын тикшереп, аның ялган түгел, ә канунлы рәвештә җитештерелгән продукт булуына инана ала. Маркировка процессын производствога кертү өчен «Татхимфармпрепаратлар» АҖ зур әзерлек эшләре башкарды: цехлар яңадан җиһазландырылды, яңа программалар сатып алынды, хезмәткәрләр өчен курслар оештырылды.

Бу күп көч куюны таләп иткән һәм кыйммәтле процессларның максаты – кулланучының сәламәтлеге. Компания даруларның нормативларга туры килүен һәм куркынычсызлыгын катгый контрольдә тота. Аның сынау лабораториясе заманча аналитика җайланмалары белән җиһазландырылган, ә җитештерү ISO 9000 сыйфат менеджменты системасына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла, әлеге системаны «Татхимфармпрепаратлар» АҖ Россиянең фармацевтика тармагында беренчеләрдән булып кертте.

МИРАСНЫ ИШӘЙТЕП...

2021 елда «Татхимфармпрепаратлар» АҖ үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Бу бәйрәмне предприятие GMP халыкара стандартларына туры килгән яңа, заманча җиһазлар белән каршы алды.

Компаниянең продукция портфелендә 130 дан артык дару препараты исәпләнә. Предприятие продукциясенең 60% ка якыны импорт даруларны алмаштыра. Татарстан фармацевтика продукциясенә Россиядә дә, якын чит илләрдә дә ихтыяҗ зур.

RNC Pharma аналитика компаниясе мәгълүматлары күрсәткәнчә, предприятие 2021 елның 10 ае нәтиҗәләре буенча дару препаратлары җитештерүчеләр арасында беренче егермелеккә керә, ә күз мазьлары җитештерүчеләр арасында Россиядә лидер булып тора.

«Татхимфармпрепаратлар» АҖ табиблар еш билгели торган дару чараларын да, илебездә авыр дәвалана торган авырулар белән көрәшү өчен инновацияле препаратлар да эшләп чыгара. Мондый универсальлек сәбәпле компаниянең ышанычлы даими партнерлары да күп. Алар арасында – «НПК Катрен» ЯАҖ, «Протек» Инновацияләр кертү үзәге» ЯАҖ, «ФК Пульс» ҖЧҖ, «БСС» ҖЧҖ, шулай ук «Планета здоровья», «Фармаимпекс», «Аптека Вита», «Apteka.ru», «Здравсити», «Фармленд»,«АСНА» һәм башкалар кебек популяр даруханә челтәрләре.

Ихтыяҗга һәм өметле тикшеренүләргә йөз тотып, компания препаратлар линейкасын киңәйтүне дәвам итә. «Фарма 2030» программасы кысаларында Казан федераль университеты белән берлектә шешләргә, ялкынсынуларга, бактерияләргә каршы препаратлар һәм башка инновацияле дарулар булдырыла. Берничә фармацевтика препараты Казанның А.Е.Арбузов ис. Органик һәм физик химия институты белән берлектә эшләнә. Алар кайбер неврологик чирләрне, йогышлы авыруларны дәвалаганда, шулай ук онкологиядә кулланыла һәм бу даруларның Россия фармацевтика базарында тиңе юк.

Офтальмология препаратлары линиясен киңәйтүне дәвам итеп, компания микробларга каршы моксифлоксацинлы күз тамчылары, шулай ук күзнең мөгез катлавы һәм тышчасында савыктыру процессларын стимуллаштыру өчен «Декспантель» күз геле чыгаруны җайга салды.

Болар барысы да– компаниянең озак вакытка исәпләнгән үсеш стратегиясенең бер өлеше. «Татхимфармпрепаратлар» АҖ үз миссиясен сәламәтлек саклау тармагын илебездә җитештерелгән сыйфатлы дару препаратлары белән тәэмин итүдә күрә. Бу исә нәтиҗәле медицина ярдәменә, Россия гражданнарының сыйфатлы тормышына нигез булып тора.

БЛИЦ-ӘҢГӘМӘ:

МИНТИМЕР МИНҺАҖЕВ

УЗЫП БАРУЧЫ ЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ ҺӘМ «ВАМИН» КОМПАНИЯЛӘР ТӨРКЕМЕНЕҢ ПЛАННАРЫ ТУРЫНДА

Узган елдан канәгатьме сез?
Ел җиңелләрдән түгел иде, әмма без моңа күнеккән инде. Гомумән алганда, вазгыятьне исәпкә алып, куелган максатларга таба ничек барырга кирәклеге аңлашыла. Үтеп чыга алмастай киртәләр юклыгын беләбез.

Аеруча катлаулысы һәм фаразларга буйсынмаганы нәрсә булды?
Сөткә бәя арту һәм өстәмә маркировкалау. Корылыклы җәй аркасында терлек азыгының кыйммәтләнүе.

Ассортиментны баеткан яңа товарларыгыз бармы?
Быел без ребрендинг ясадык, продукциябезнең – сыр һәм майның төргәген, тышлыгын яңарттык. Ассортимент матрицасына кисәкләп төрелгән «Балтасинский мраморный» һәм «Фермерский» сырларын керттек.
Кызганыч, теләгәннең барысын да тормышка ашыра алмадык. Бу юнәлештә эшлибез. Командага анык бурычлар куелды. 2022 елда җиң сызганып эшлисе өлкәләр бар әле.

Ассортиментка хәләл сертификацияле продукция кертү планнарыгыз бармы?
Мондый мөмкинлекне өйрәнәбез. Минемчә, моны гамәлгә ашырырга була. Барысын да исәпләргә һәм бәяләргә кирәк.

Компанияне алга таба үстерү ниятләре бармы?
2022 елга планда түгел, анысы анык. Киләсе елның нәтиҗәләре нинди булачагын карарбыз. Ә аннары команда белән карар кабул итәрбез.

Бүген «Вамин»ның ассортиментында күпме сыр бар?
16 төр сыр. Алардан кала, 72,5% майлылыклы атланмай, эремчек суы һәм майсыз коры сөт тә бар.

Сезнең карашка, хәзерге заман сатып алучысы җитештерүчедән иң элек нәрсә таләп итә?
Әлбәттә, сыйфат! Ә яхшы продуктны бары тик сыйфатлы чималдан, санитар нормаларны һәм җитештерү технологияләрен төгәл үтәгәндә генә ясап була.

Тәмле һәм сыйфатлы сыр сайлаганда нәрсәгә игътибар бирергә киңәш итәсез?
Һәркемнең үз зәвыгы. Ә гомумиләштерелгән сыйфат күрсәткече ул – продукциянең составы, стандартларга туры килүе, һәм мин, һичшиксез, бәяне дә билгеләп үтәр идем.

Сыйфатлы продуктка бәя нинди булырга тиеш?
Бер килограмм сыр җитештерү өчен 11 литрга якын сөт кирәк. Шуңа транспорт, электр энергиясе, су, әчеткегә киткән чыгымнарны, хезмәткәрләрнең хезмәт хакын, кибетнең арттырып сату бәясен өстәгез... Сыйфатлы сыр арзан була алмый. Май турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Узып барган елда проектларыгыз сез уйлаган темплар белән үстерелдеме?
«Вамин» Компанияләр төркеменең үсеш перспективаларын, нигездә, планлы рәвештә Россия базарына чыгу белән бәйлим.
Ниятебез – сыр җитештерү күләмен арттыру. Җитештерү мәйданчыкларыбызның берсе булган Арча сөт комбинатында («Арча» ҖЧҖ) бүген модернизацияләү эше төгәлләнеп килә.
Яңа сыр линиясен урнаштырабыз. Куәте – тәүлегенә 38 тонна сыр. 2022 елга календарьны тулаем планлаштырган чакта, без киләчәкне кайгыртып эш итәбез.

Киләсе елдан нәрсә көтәсез?
Алга куелган планнарның тормышка ашырылуын. Коллективның бергә көйле эш алып баруын.
Арчадагы заводның реконструкциядән соң эшләтеп җибәрелүен түземсезлек белән көтәм.

Укучыларыбызга Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре алдыннан нинди теләкләр җиткерер идегез?
Беренче чиратта,барыгызга да нык сәламәтлек телим! Саулык һәрвакыт мөһим, әмма хәзер – бигрәк тә. Бөтенебезгә дә коронавирусны җиңеп чыгарга язсын.
Барлык укучыларга чын күңелдән теләгем: һәртөрле катлаулы хәлләрдә дә яңа мөмкинлекләр таба алсыннар!

Фото «Вамин Татарстан» КТ тарафыннан бирелде. Реклама

ВАМИН
ВАМИН
ЭДАМ
сыр полутвёрдый
ВАМИН
ГОЛЛАНДСКИЙ
сыр полутвёрдый
ВАМИН
БАЛТАСИНСКИЙ МРАМОРНЫЙ
сыр полутвёрдый
ВАМИН
ФЕРМЕРСКИЙ
сыр полутвёрдый
Реклама
С любовью, к вашему столу
vamintatarstan

АК ҮГЕЗ ЕЛЫН ОЗАТЫП

Россия Федерациясенең яңа азык-төлек иминлеге доктринасына ярашлы рәвештә, россиялеләрнең ит һәм ит продуктлары белән үз-үзләрен тәэмин итү дәрәҗәсе 85% тан да ким булмаска тиеш. Азык-төлек өлкәсендәге куркынычсызлык нигезендә авыл хуҗалыгының фәнни базасын киңәйтү, үсемлекчелек һәм терлекчелектәге селекция ята.

Ит терлекчелеген үстерүнең тиз үсештәге һәм табышлы юнәлешләреннән берсе – кроссбридинг технологияләре. Гади тел белән әйткәндә, генетик яктан ярашмаган сорт, линия һәм токым вәкилләрен кушу.

Россиядә ит терлекчелеген үстерү перспективалары күбесенчә ак-зәңгәр Бельгия токымлы мөгезле эре терлекнең генетик материалын куллану белән бәйле. Илебездә әлеге токым орлыгы белән эксклюзив рәвештә тәэмин итеп торган ширкәт – «МИРОВЕТ» ҖЧҖ. Бүген ул Татарстан Республикасында нәселле продукция җитештерү һәм аны китереп бирә торган эре төбәк оешмасы белән тыгыз хезмәттәшлек итә.

Төрле токым кушылган хайваннарның төп өстенлеге – асрау һәм ашату шартларына талымсызлык, авыруларга чыдамлык һәм, иң мөһиме, җитештерелә торган итнең югары сыйфатлылыгы. Бу терлекләрнең итләре майлы түгел, диетик, тәмле һәм кеше сәламәтлеге өчен файдалы.

Моннан тыш, катнаш токымлы яшь ярымлык тана һәм үгезләрнең тере авырлыгы 680–720 кг га җитә һәм шул ук яштәге гадәти терлекнекеннән 100–200 кг га артып китә. Бу исә авыл хуҗалыгы җитештерүчесенә терлек азыгының югары конверсиясе хисабына гадәти рационда 20–50 мең сум күләмендә өстәмә табыш китерә. Әлеге токым орлыкларын еш кына сөт сыерлары көтүендә берничә тапкыр гади орлык белән уңышсыз аталандыру очрагында кулланалар.

«МИРОВЕТ» компаниясе шулай ук терлекчелек хуҗалыкларын төрле чирләрдән дәвалауның инновацияле системасын, сыерларның баш санын арттыруны стимуллаштыру һәм репродуктив сыйфатларын торгызу алымнарын, антибиотиклар куллануны күздә тотмаган, үз илебездә җитештерелгән нәтиҗәле дәвалау-профилактика препаратларын тәкъдим итә.

– Кайбер кулланучылар ак-зәңгәр Бельгия токымы итенең табигыйлегенә шикләнә, гормоннар һәм стероидлар ярдәмендә генә җитештерүчәнлекнең шаккатыргыч нәтиҗәләренә ирешергә мөмкин, дип ялгыша, – ди «МИРОВЕТ» ширкәтенең Татарстан һәм Башкортостан Республикаларындагы вәкиле Рәсүл Саттаров. – Белешмә өчен: ит сәнәгатендә гормоннар куллану Европада 1996 елда ук тыелган. Ул чакта мондый мускулатура каян соң? Бар сер йөзьеллык селекциядә яшеренгән. Генетик сайлап алу нәтиҗәсе бүгенге кебек терлек барлыкка килүгә мөмкинлек биргәнче, бинаһа күп вакыт уза.

«МИРОВЕТ» ҖЧҖ белгечләре фикеренчә, җитештерүнең нәтиҗәлелеге һәм продукция сыйфаты терлек үстергәндә кулланыла торган азык һәм су сыйфатына гына түгел, малтуарны дәвалаганда препаратларны дөрес һәм профессиональ дәрәҗәдә файдалануга да бәйле. Бүген компания кейсында тиңе булмаган шундый берничә препарат һәм вакцина бар. Әйтик, Туканолин, Ваколин, Ниацид-К, Олин кебекләрнең тәэсир итү дәрәҗәсе бик югары. Аларның нәтиҗәлелеге фәнни тикшеренүләрдә һәм тормышта күп тапкырлар исбатланган. Компания тәэмин иткән орлык материалына һәм дәвалау препаратларына карата җитештерүче терлекчеләрдән мактау сүзләре ишетү рәхмәт белдерүнең иң яхшы рәвеше ул, дип саный Рәсүл Саттаров:

– «МИРОВЕТ» ҖЧҖ белән хезмәттәшлек итә башлаганнардан күбесенең соңыннан да партнерларыбыз булып калуы бик күңелле. Бүген без гамәлгә ашыра торган проект авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын җайга салуны күздә тоткан дәүләт программасына туры килә, россиялеләрнең сыйфатлы һәм экологик яктан чиста азык-төлек продуктларына ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерүгә һәм кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән. Бу киләчәк проекты түгелмени?

P.S. «МИРОВЕТ» ҖЧҖ кроссбридинг технологиясе ярдәмендә чыгарылган 2 атналык, 6 айлык, 1,5 яшьлек үгез һәм таналарны базар бәясеннән югарырак хакка сатып алырга әзер.

Компаниянең сайты: bbb.moskow
E-mail: bbg-bbb@bk.ru
Адресы: 141201, Мәскәү өлкәсе, Пушкино шәһәре, Соколовская ур., 23 нче корылма, 1 нче бина.
Үсеш директоры– Шайбель Алексей Яковлевич, тел.: 8-965-136-13-36
«МИРОВЕТ» ҖЧҖнең ТР һәм БРдагы вәкиле – Рәсүл Саттаров, тел.: 8-937-488-80-50

Фотолар «Мировет» компаниясеннән алынды. Реклама.


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Милләтләр арасында татулык юлын сайлау – иң нәтиҗәлесе
Балалар йортының әнисе
Мачетле Олы Елга

Реклама 16+

ХОКУКЫЙ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ НӘТИҖӘЛЕ ФОРМАСЫ

Быел «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль закон кабул ителүгә ун ел тула. Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Заһидуллин республика халкына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында сөйләде һәм башка сорауларга җавап бирде.

– Рөстәм Илдусович, квалификацияле юристлар тарафыннан юридик ярдәм алуга ихтыяҗ ел саен арта бара. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының бу юнәлештә бурычлары нинди?

– Түләүсез юридик ярдәм турында федераль һәм республика законнары халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтү системасын формалаштырды. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы республикада гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле орган итеп билгеләнде.

Түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар исемлеге федераль закон белән билгеләнгән. Татарстан Республикасы законы белән әлеге исемлек киңәйтелде, аңа шулай ук реабилитацияләнгән гражданнар да кертелде.

– Сез Юстиция министрлыгы вәкаләтле орган дип әйтәсез, димәк, түләүсез юридик ярдәмне Юстиция министрлыгы гына күрсәтә аламы?

– Юк, түләүсез юридик ярдәм дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар тарафыннан күрсәтелә, шул ук вакытта дәүләт системасына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм аларга караган учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары, шулай ук адвокатлар керә.

Республика башкарма хакимиятенең һәр органында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, гражданнарны кабул итү көннәре һәм вакыты өчен җаваплы затлар билгеләнде. Рәсми сайтларда «Түләүсез юридик ярдәм» бүлекләре бар, анда гражданнар мондый ярдәмне алу тәртибе белән таныша ала, бу исә гражданнарга мәгълүмати ярдәм күрсәтүнең һәм аларга хокукый белем бирүнең нәтиҗәле формасы булып тора.

Дәүләтнеке булмаган система иреклe башлангычларда формалаша, анда юридик клиникалар һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләре катнаша.

– Түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар турында тулырак сөйләгез әле: түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдә адвокатлар һәм юридик клиникалар нинди роль уйный?

– Адвокатлар дәүләт системасының төп катнашучылары булып тора. Ел саен министрлык һәм Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы белән түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында килешү төзелә.

Хәзерге вакытта Адвокатлар палатасының 150 дән артык әгъзасы Татарстан Республикасының бөтен территориясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә: гражданнарга шикаятьләр һәм гаризалар әзерләүдә булыша, телдән һәм язма консультацияләр үткәрә, дәүләт хакимияте органнарында һәм судларда аларның мәнфәгатьләрен яклый.

Закон тарафыннан юридик клиникаларга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдә катнашу каралган. Бүгенге көндә республикада югары уку йортлары базасында 6 юридик клиника эшли, шуларның 5 се белән министрлык тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында килешү төзелде. Килешү хезмәттәшлек һәм мәгълүмат алмашуны, шулай ук белешмә-методик ярдәм күрсәтүне күздә тота. Бу үзара хезмәттәшлек түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең сыйфатына уңай йогынты ясый.

2021 елда юридик клиникалар республиканың 220дән артык кешесенә түләүсез хокукый ярдәм күрсәтте.

– Рөстәм Илдусович, аңлатып китсәгез иде, гражданның түләүсез юридик ярдәм алуга ихтыяҗы туганда, аңа нишләргә?

– Юстиция министрлыгында 8 (843) 222-60-60 «кайнар линия» телефоны эшли, аның буенча 2019 елда ачылган Түләүсез юридик ярдәм үзәгенә мөрәҗәгать итәргә һәм кабул итүгә язылырга мөмкин. Үзәк эшендә министрлык белгечләре, адвокатлар һәм тармак ведомстволары вәкилләре катнаша. Гражданнарны атнага ике тапкыр: һәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә кабул итәләр. Үзәк булдырылганнан бирле анда 370 гражданга 586 мәсьәлә буенча консультация бирелде,түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында адвокатлар тарафыннан 38 килешү төзелде.

Моннан тыш, түләүсез хокукый ярдәм алырга теләгән һәркем реаль вакыт режимында Татарстанның интерактив картасында (ТР геопорталы https://minjust.tatarstan.ru/besplatnaya-yuridicheskaya-pomoshch/map) түләүсез юридик ярдәм күрсәтү системасында катнашучылар турында мәгълүматны белә ала. Анда түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдә катнашучыларның адресы, телефоны һәм кабул итү сәгатьләре турында мәгълүмат күрсәтелгән. Хәзерге вакытта картада 187 урын билгеләнгән.

Республиканың ерак районнарында яшәүче халыкка министрлык тарафыннан, шул исәптән татар телендә дә, түләүсез юридик ярдәм ерак элемтә каналлары аша күрсәтелә. Булачак барлык чаралар да министрлыкның рәсми сайтында һәм социаль челтәрләрендә анонслана.

2021 елда мондый ярдәм Әгерҗе, Чүпрәле һәм Арча муниципаль районнарында яшәүчеләргә онлайн форматта күрсәтелде.

– Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү системасында катнашучыларга ешрак нинди сораулар белән очрашырга туры килә?

– Гражданнар мөрәҗәгатьләре тематикасы төрле: бу торак һәм җир мәсьәләләре, социаль-пенсия тәэминаты, алимент-лар түләттерү, хезмәт законнарын бозу, мирас хокукы мөнәсәбәтләре, кулланучылар хокукларын яклау, суд эшләре мәсьәләләре, гаризалар, хокукый документлар төзү һәм башкалар.

– Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов 2022 елны цифрлаштыру елы дип игълан итте, сөйләшүебез ахырында министрлыкның әлеге темага кагылышлы планнары белән уртаклашсагыз иде.

– Әйе, министрлык цифрлы технологияләрне актив рәвештә үз эшчәнлегенә кертә, мәсәлән, 2020 елдан түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең электрон формасына күчү юлы белән түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм аны алу тәртибе гадиләштерелде.

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы быел Хокукый белем бирү һәм түләүсез юридик ярдәмнең бердәм дәүләт порталын булдыру эшен башлап җибәрде. Татарстан Республикасы порталның төбәк сегментында беренче итеп билгеләнде. Проект гражданнарны системалы, актуаль, дөрес һәм кабул итү өчен уңайлы, югары дәрәҗәдә күзаллауга һәм гади эзләү сценарийларына ия булган хокукый мәгълүмат белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

2022 елда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү технологияләрен видео һәм аудио кабул итүләр һәм чат-бот сервислары буларак кертү планлаштырыла. Проектны тормышка ашыру түләүсез юридик ярдәм күрсәтү процессының цифрлы трансформациясен, аның ачыклыгын, сыйфатлы һәм оператив булуын тәэмин итәчәк.

Диана Паскарь **әңгәмәсе**

ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫНДА 8 (843) 222-60-60 «КАЙНАР ЛИНИЯ» ТЕЛЕФОНЫ ЭШЛИ, АНЫҢ БУЕНЧА 2019 ЕЛДА АЧЫЛГАН ТҮЛӘҮСЕЗ ЮРИДИК ЯРДӘМ ҮЗӘГЕНӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ ҺӘМ КАБУЛ ИТҮГӘ ЯЗЫЛЫРГА МӨМКИН. Үзәк эшендә министрлык белгечләре, адвокатлар һәм тармак ведомстволары вәкилләре катнаша. Гражданнарны атнага ике тапкыр: һәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә кабул итәләр.

ГАЛИМҖАН БАРУДИ

Автор: Илдус Заһидуллин

XIX–XX гасырлар чигендә татар җәмгыятенең яңарышы нигездә шәһәрдә күзәтелгән. Иҗтимагый фикер үсешендә ике чорны: 1905 елга кадәрге һәм аннан соңгы, ягъни Россиядә Беренче инкыйлаб елларын аерып күрсәтергә мөмкин. Казан каласында татарларның фикер көрәшендә ике төркем – «Галиев партиясе» һәм искелек яклылар аерылып тора. Көрәштә «Галиев партиясе»нең күпсанлы кечкенә китаплар бастырып, искелек яклыларны идеологик планда җиңә башлавы күренә. «Галиев партиясе» дип хакимият Казан мулласы Галимҗан Барудины һәм аның тарафдарларын атый.

БЕЛЕМ ЭСТӘҮ, ЯКИ 40 ПОТ КУЛЪЯЗМА КИТАП ТУПЛАУ

Галимҗан Баруди солдат хезмәтеннән кайтып сәүдә эшенә керешкән Мөхәммәтҗан Галиев (1832–1908) гаиләсендә 1857 елның 5 февралендә дөньяга килә. Әтисе 1859 елны авылдан Баруди бистәсенә күченеп, бер елдан гаиләсен дә Казанга урнаштыра.

Яшьтәшләре урамда җил куып, әүмәкләшеп уйнап йөргәндә өйдә утырган оялчан табигатьле Галимҗаннан сәүдәгәр чыкмасын күргән Мөхәммәтҗан биш яшьлек улын 1862 елда икенче мәхәлләдәге Күл буе мәдрәсәсенә, Нургали хәлфәгә укырга бирә. Галимҗан, чыннан да, яхшы укуы белән сөендереп, өлкән шәкерт булгач, үзе дә дәресләр бирә. Хәлфәсеннән үрнәк алып, акчасы булган саен китап алу гадәте Галимҗанда үсмер вакытында ук барлыкка килә.

Әтисеннән фатиха алып, 18 яшендә Баруди энекәше Салихҗан белән ерак сәфәргә кузгала, Бохараның Шиһабетдин Мәрҗани укыган атаклы «Мир араб» мәдрәсәсенә урнашып, 7 ел максатчан рәвештә шәһәр голәмәләреннән белем туплый. Соңрак Бохарада яшәгән елларын тормышының иң якты, гүзәл мизгелләре буларак искә алып, Галимҗан бервдә укуының максатын болай аңлата: «Бәндә өчен иң олыг сәгадәт – ватаныма хезмәт итү вә ул милләтең сәгадәтенә ярдәм итү булганлыктан, гыйлемем илә милләттәшләремне файдаландырмак хыялы мине дәртләндерә, вә ул уйлаган саен тырышлыгымны арттыра иде. Аллаһның татар дигән бәндәләрен гыйлем вә дин юлына уятам, кирәклеген аңлатам вә бу рәвешле бәхетле итәм вә шул хезмәт белән шәрәфәтендә Аллаһының ризалыгын табып, мәңгелек сәгадәткә ирешәм дигән өмет миндә бик куәтле иде. Табигый, минем бу өметемне яшьлегем, тәҗрибәсезлегем куәтләгәндер... »

Бертуган Барудилар укуларын Әфганстанда – Кабулда дәвам итәргә уйласалар да, әтиләренең сәламәтлеге какшап торганны ишетеп, Бохарада сатып алган 40 пот дини кулъязма китапны дөяләргә төяп, 1882 елда Казанга әйләнеп кайталар.

Мөхәммәтҗан бай шул ук елны, туйлар ясап, Галимҗанны – дусты һәм мәсләктәше сәүдәгәр Исхак Үтәмешевнең Бибимаһруй исемле кызына, Салихҗанны Бибинәгыймә исемле кыз туганына өйләндереп башлы-күзле итә. Галимҗанга атап, шул ук 1882 елда кирпечтән иңе 8 метр, озынлыгы 16 метр булган мәдрәсә бинасы төзеп бирә. Яңа уку йорты төзүче-иганәче исеме белән белән «Мөхәммәдия» дип атала башлый.

Галимҗан 1883 елда Казанның 5 нче мәчетендә имамлык һәм мөгаллимлек итәргә указ ала. 1886 елда хаҗ кылып кайта, Мисыр, Истанбул, Хиҗазга сәяхәт кыла.

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ МӨДИРЕ ҺӘМ ИДЕОЛОГЫ

Галимҗан Баруди Бохарада укыган елларында да, чит илләргә сәяхәте вакытында да дини

Фотолар автордан алынды

үзәкләрдәге белем бирү системасын ныклап өйрәнә, күзәтә, аның кимчелекләрен дә, өстенлекле якларын да хәтеренә беркетеп куеп, үз мәдрәсәсен булдыру турында уйлый.

Мәдрәсәдә шәкертләр саны арткач, Галимҗан, бинаның аскы катына тәрәзәләр уйдырып, уку мәйданын зурайта. 1886 елда Казан сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев бинага өченче кат төзеп бирә. Бу уку мәйданы да җитми башлагач, 1894 елда Үтәмешев 4 мең сум, Барудиның хатыны Бибимаһруй 2 мең сум иганә итеп, янәшәдә ике катлы агач бина күтәрәләр. Кызганыч, 1898 елда яңа бина янып юкка чыга.

1870 елда һәр яңа мәдрәсә фәкать рус сыйныфы булганда гына ачылырга тиеш дигән канун кертелгән була. Шул сәбәпле галия, ягъни югары сыйныфта укучылар өчен бина төзергә рөхсәт алу мәсьәләсе фәкать 1901 елда гына уңай хәл ителә. Казан байлары җыелышып, таштан өч катлы, заманча, үзәктән ягып җылытыла торган яңа уку бинасы күтәртәләр, шул рәвешле бүгенге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе татар сәүдәгәрләренең милләт өчен гыйлемле руханилар хәзерләү иганәчелегенә һәйкәл булып тора. Ике бина да санитария һәм уку-укыту таләпләренә туры китереп, заманча җиһазландырыла. Гомумән, Галимҗан Баруди үзен оста оештыручы, тирән белемле дин галиме итеп таныта.

Әйтергә кирәк, мәдрәсәгә терәлеп үк Йосыф хәзрәтнең мәктәбе эшләп килә. 1909 елда аның вафатыннан соң бу мәктәп бинасы да «Мөхәммәдия»гә кушыла. «Мөхәммәдия»нең уку-укыту комплексы әле моның белән генә чикләнми. Янәшәдә урнашкан 5 нче мәчетнең беренче катындагы ике бүлмәдә ярлы һәм ятим балалар өчен фәкыйрьләр мәктәбе эшли. Аларга кием-салым һәм уку әсбаблары бушка бирелә. Бу төркем балаларны урамда хәер сорашып йөрүдән биздерү өчен, беркадәр акча да түләнә. Шул рәвешле, фәкыйрьләр мәктәбе ятим балаларны тәрбияләү-укытуга бәйле мөһим социаль мәсьәләне дә хәл итүне үз өстенә ала. Мәктәпне тәмамлаган балаларны, гадәттә, татар байлары өйрәнчек итеп эшкә урнаштыралар, мәдрәсәнең төп сыйныфларына кабул ителгәннәре дә була.

1913 елда Баруди йортының бер бүлмәсендә 3 мең китап тупланган коллекция нигезендә «Мөхәммәдия» шәкертләре файдалана торган шәхси китапханә ачыла. Бүгенге көндә ул китапларның бер өлеше Казан университеты фәнни китапханәсендә саклана.

Мәдрәсәнең 1918 елга кадәрге 35 еллык тарихында берничә этап бик төгәл күренеп тора:

1882–1889 еллар – шәкертләр җыю һәм реформалар ясарга әзерләнү вакыты;

1890–1904 еллар – башлангыч мәктәптә аваз ысулы белән укыту, дөньяви фәннәр кертелү, ә мәдрәсәдә белем бирүнең кадимчә дәвам итүе;

1905–1908 еллар – шәкертләр таләбе буенча яңа, дөньяви фәннәр кертелү, яңа укытучылар

1 «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе.

чакыртылу, ләкин әле укыту программаларында тотрыклылык юк.

1908–1912 еллар – дамелла Галимҗан Барудиның сөргендәге вакыты, бу елларда мәдрәсәне энекәше, гарәп теле укытучысы Габдрахман җитәкли.

1912–1918 еллар – мәдрәсәнең гөрләп эшләгән вакыты, «Мөхәммәдия», Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе белән беррәттән, милли кадрлар әзерләү бурычын уңышлы үти.

«Мөхәммәдия»дә төрле елларда Газиз Гобәйдуллин, Борһан Шәрәф, Шәһәр Шәрәф, Йосыф Акчура, Кәшшаф Тәрҗемани, Габдулла Апанаев, Хуҗа Бәдигый һ.б. интеллектуаллар укыта.

1887 елда мәдрәсәдә 57 шәкерт белем алса, 1894 елга аларның саны 121 гә җитә, 1908 елда 344 була, соңрак 500 гә әйләнә.

«Мөхәммәдия» дүрт сыйныфны берләштергән, 12 ел укый торган күп баскычлы мәдрәсә булып җитешә. 1913–1914 уку елында программа 14 еллык итеп үзгәртелә. Анда башлангыч – 5 ел, урта сыйныф – 6 ел, югары сыйныф – 3 ел һәм төп курска кермәгән әзерлек сыйныфы (1 ел) була. Башлангычта атналык дәресләрнең 39 сәгате – дин тәгълиматына, 11 сәгате дөньяви фәннәргә бирелә, урта сыйныфларда аларның чагыштырмасы 1:3не тәшкил итә – дөньяви фәннәргә өстенлек бирелә. Галия сыйныфы рухани әзерләүне максат итеп куя. Биредә нигездә дини фәннәр укытыла. Бер сүз белән әйткәндә, «Мөхәммәдия»дә рус–Европа гомуми белем бирү мәктәпләрендәге барлык фәннәр дә укытылган. Шул сәбәпле Совет хөкүмәте һәм ВКП (б) ҮКның 1948 елның 10 февралендәге карары нигезендә «Мөхәммәдия»дә укыган кешеләрнең белеме педагогик училищега тиңләштерелә.

МАҺРУЙ АБЫСТАЙ МӘКТӘБЕ

Иреннән дәресләр алып белемен камилләштергәч, Бибимаһруй абыстай 1889 елдан берничә кыз баланы укыта башлый. 1890 елда хәзерге Париж Коммунасы һәм Тукай урамнары

2

Сулдан уңга: Габдулла Апанаев, Салихҗан һәм Галимҗан Барудилар, Габделхәмит Казаков. Вологда шәһәре, 1908 ел.

кисешкән почмактагы йортта Казанда беренче җәдитчә укыта торган кызлар мәктәбе ача. Бибимаһруй мәктәбендә яңа ысул белән укыту тәртибен өйрәнгән кызлар соңрак үзләре дә мөгаллимлек эшенә алынганнар.

Бибимаһруй абыстай, 1893 елда түбән өйләренең бер бүлмәсендә тагын бер мәктәп ачып, махсус мөгаллимнәр билгеләп, ел саен урамда хәер сорашып йөрүче фәкыйрь кыз балаларны укытуны оештыра. 5-6 кешелек тулай торак ачып, үз хисабына анда яшәгән кызларны ризык һәм урын-җир белән тәэмин итә. Барудиларның үз балалары булмый.

Шулай ук Бибимаһруйның бу йортына сәүдәгәр хатыннары һәм олы яшьтәге ханымнар җыелып, Коръән укырга өйрәнә башлый. 1896 елда Бибимаһруй уку-укыту эшләренә ярдәмче итеп киләчәктә үзе хатын-кызлар мәктәбе ачачак Ләбибә ханымны чакыра.

Бирнә һәм этисеннән калган мирас акчасын Бибимаһруй, нигездә, мәгарифне үстерүгә сарыф итә. Сәүдәгәр кызының хисап кәгазьләреннән күренгәнчә, ул даими рәвештә «Мөхәммәдия» шәкертләренә уку китаплары сатып алып бүләк иткән, яхшы укучы балаларга матди ярдәм күрсәткән, мәдрәсәнең дүрт мөгаллименә Госманлы дәүләте уку йортларында белемнәрен тирәнәйтү мөмкинлеге тудырган, берничә авылда мәктәпләр төзеткән. 1904 елда Бибимаһруй вафатыннан соң аның васыять акчасына галим Таһир Ильяси Каһирә һәм Хиҗаз шәһәрләрендә 3-4 ел укып кайта, «Мөхәммәдия» файдасына 8 мең сум иганә керә.

Шул ук елны Галимҗан Баруди Гайшә Сәетшакуловага өйләнә. Бу никахтан да балалар булмый.

«ӘД-ДИН ВӘ ӘЛ-ӘДӘБ» ЖУРНАЛЫ МӨХӘРРИРЕ

1905 ел 17 октябрь манифесты игълан иткән дин иреге турындагы хәбәр Россиянең төрле төбәкләрендә татар вакытлы матбугаты барлыкка килүгә хокукый нигез була. Дин мәсьәләләренә багышланган берничә журнал басыла. Алар арасында – кадимчеләр рупоры булган «Дин вә мәгыйшәт» (Оренбург), Риза Фәхретдин мөхәррирлегендә басылган «Шура» (Оренбург) һәм Казанда Галимҗан Баруди нәшер иткән «Әд-Дин вә әл-Әдәб» басмасы да бар.

Журнал 1906–1908 һәм 1913–1917 елларда нәшер ителә. Ике атнага бер тапкыр чыгару планлаштырылса да, андый даимилек сакланмый. Укучы кулына да шактый өзеклекләр белән генә барып ирешә.

1907 елның май ае башында «Мөхәммәдия» каршында татар укытучылары әзерләү курслары ачыла. Илнең төрле төбәкләреннән җыелган 60лап кеше өч атна чамасы, полиция куып таратканчы, дәрес алырга өлгереп кала. 1908 елның маенда курсларны оештыруда инициатива күрсәткән бертуган Галимҗан һәм Салихҗан Барудиларны, Габдулла мулла Апанаевны һәм сәүдәгәр Габделхәмит Казаковны хакимият Вологда губернасына сөргенгә җибәрә. Вологдага барып җитмәс борын, хөкүмәттән рөхсәт алып, сөрелгәннәр төрле чит илләргә китеп бара. Галимҗан хәзрәт хаҗ кылырга юнәлә, Мәккә, Мәдинә, Каһирә, Дәмәшкъ, Истанбул, Берлин калаларында була. Аларның дүртесе дә вакытыннан алда, 1910 елның мартында Казанга кайтып җитә. Баруди полиция күзәтүендә яши. 1913 елда «Әд-Дин вә әл-Әдәб»не кабат бастыра башлый.

Басма материалларының яртысына якыны дини мәсьәләләргә багышланган булып, күбесенең авторы мөхәррир Галимҗан Баруди икәнлекне дә әйтергә кирәк. Һәр санда диярлек Коръән сурәләре, тәфсирләр, хәдисләр шәрехенә багышланган мәкаләләр урнаштырыла, дини бәйрәмнәр, халыктан килгән дингә кагылышлы сорауларга җаваплар, милли мәгариф алдында торган проблемалар, «Мөхәммәдия»дә укыту тәртибенә каршы чыккан, баш күтәргән шәкертләргә үгет-нәсихәтләр, галимнең педагогика һәм методика өлкәләренә караган берничә дистә мәкалә-язмасы да шушы басмада дөнья күрә. Гомумән алганда, дамелланың ислам дине белгече, уку йорты җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче буларак әйткән фикерләре журналда тупланган.

Беренче рус инкыйлабы елларында Баруди фигурасы мөселманнарның иҗтимагый хәрәкәтендә ачык күренә. Ул 1905

елның 10–15 апрель көннәрендә Уфада узган руханилар корылтаенда Мәхкәмәи шәргыянең яңа уставын төзүгә өлеш кертә, Икенче һәм Өченче Бөтенроссия мөселман съездларында (1906 ел, Санкт-Петербург һәм Түбән Новгород) катнаша, соңгысында дингә кагылышлы карар проектын әзерли, «Иттифак әл-Мөслимин» партиясенең Үзәк комитетына сайлана.

БАРУДИ ЯЗГАН УКУ ӘСБАПЛАРЫ

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар мәктәпләре өчен уку китапларына булган кытлык күп генә татар зыялыларын шушы өлкәдә эшләргә этәрә. Җәдиди мәдрәсәдә 1–2 ай эчендә укырга-язарга өйрәнгәч, вакытны файдалы итеп уздыру, яңа фәннәр өйрәнү өчен укыту сәгатьләре артып кала. Бер үк вакытта җәдиди мәктәпләрдә дин белеме укытуның сыйфатын яхшырту, кадими мәдрәсәләрдәге үзләштерү өчен авыр саналган фикъһе, гакыйдә, хәдис буенча уку материалларын яңарту һәм халык телендә язып җиңеләйтү мөһим бурыч булып тора.

Шушы четерекле мәсьәләне хәл итү йөзеннән, Баруди 1890 нчы елларда «Мәгарифел ислямия» исеме белән тугыз китапчык әзерләп бастыра, алар дистә тапкыр һәм аннан да күбрәк нәшер ителеп, бөтен ил буенча тарала. Сериянең тәүге басмасын «Сәвад хан» («Белемле бала») исемле әлифба тәшкил иткән. Ул Исмәгыйль Гаспралының кырымтатар телендә бастырылган әлифбасыннан Идел төбәге татар балалары өчен атап язылуы һәм аларның тел үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнгән булуы белән аерылып торган. Аннан соңгы китапларда намазны дөрес уку, догалар, гакыйдә, чисталык-гигиена кагыйдәләре, намазда укыла торган зекерләр, намаз төрләре, мәчеткә керү әдәпләре һ.б. мәгълүмат урнаштырылган.

Галимҗан Барудиның дәреслекләр язуда тагын бер юнәлеше – Коръән телен тирәнтен үзләштерүне күздә тотып язылган әсбаблары. Бу өлкәдә дә Баруди, К.Насыйри, Г.Буби, Х.Госманов, Ә.Максуди кебек, тел галимнәре белән янәшә эшли, гарәп теле синтаксисы (1891), морфологиясе һәм грамматикасы дәреслекләре авторы буларак таныла. Ул шулай ук урта мәктәпнең беренче сыйныф шәкертләренә атап гарәп теленә дә, хәдис белеменә дә караган дәреслек иҗат итә.

Шулай да мөдәррис методика өлкәсендә төп игътибарны башлангыч мәктәпкә бирә. 1891 елда башлангыч мәктәп өчен гади телдә язылган арифметика китабын нәшер итә. 1899 елда «Тарих әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») исемле пәйгамбәрләр тормышыннан кыйссалар, хикәяләр, гыйбрәтле хәлләрне туплаган уку китабы әзерләп бастыра.

1908 елда Баруди шулай ук Казанда «Милләт» исемле нәшриятны оештыручыларның берсе була. Биредә 1917 елга кадәр 1376 мең данәдә 256 исемдәге китап басыла.

Йосыф Акчура Галимҗан Барудига язган хатында болай ди: «Сез милләтегезнең иң Аллаһка ышанган, галим кешеседер; милләтегез көчле булсын, башка милләтләрдән артта калмасын өчен, максатыгызга ирешү өчен күп каршылыклар күрдегез, ләкин сез бүген зур бер «мәктәп» җитәкчесе».

САЙЛАНГАН МӨФТИ

1917 елның 1–11 май көннәрендә Мәскәүдә узган Беренче бөтенроссия корылтаенда Галимҗан Баруди Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мөфтие итеп сайлана. 1917 елның июлендә Казанда булган корылтай Милли идарәне игълан итә.

Ноябрь аенда Баруди Милли идарәнең Диния нәзарәте рәисе итеп сайлана. 1918 елның язында большевиклар Милли идарәне куып тараткач, Милли идарә әгъзалары белән Кызылъяр шәһәренә китә. 1919 елның мартында Уфаны аклар алгач, шәһәргә кайта. Ләкин бераздан шәһәр большевиклар кулына күчкәч тә мөфтилеген ташламый: сайланган мөфти буларак, дини вазыйфаларын үтәүне дәвам итә.

Барудига яңа хакимият белән хезмәттәшлек итәргә, дин кардәшләренең һәм ислам институтларының хокукларын якларга туры килә.

1921 елда илдә ачлык башлангач, Баруди, 4–6 июль көннәрендә Уфа губернасы Бәләбәй һәм Стәрлетамак өязләре авылларында йөреп, корылыктан интегүче халык белән очраша. Уфага кайткач, Совет хөкүмәте җитәкчесе Владимир Ленинга, милләтләр эшләре буенча халык комиссары Иосиф Сталинга һ.б. түрәләргә атап, ачлыктан интегүче халыкка дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать яза һәм башкалага юллый. Көз-кыш айларында даими рәвештә ярдәм сорап, Мәскәү – Казан арасын таптый. Мәскәүдә ачлыктан интегүче мөселманнарга ярдәм итү фонды оештыра. Эшчәнлеген «Ачларга ярдәм итү комитеты» әгъзасы буларак киң җәелдерә. Шушы эшләр белән шөгыльләнгәндә Мәскәүдә 1921 елның декабрендә вафат була, Казанда җирләнә.

3

Г. Баруди Икенче Бөтенроссия мөселман съездында катнашучылар арасында. Икенче рәттә, сулдан алтынчы. Санкт-Петербург, 1906 елның гыйнвар ае.

«ШУНДЫЙ ЯКЫН МИҢА БАР КЕШЕЛӘР, ТУГАН ЯГЫМ КЕБЕК КИҢ ҖИҺАН»*

Тормышыбызның совет чорын искә алу шагыйрь һәм язучылардан башка тулы булмас иде. Ул елларда язылган, шул чорны сурәтләгән әдәби әсәрләр СССРда туып-үскән кешеләрдә тормышларының төрле мизгелләрен яңарта. Ә аннан соңгы чорда туганнарга совет кешесенең нинди булганлыгын аңларга ярдәм итә. Бүген «Татарстан» журналында кунакта - Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының халык шагыйре Разил Вәлиев. Сезгә аның балачагы, яшьлеге турындагы хатирәләрен тәкъдим итәбез.

Мәдинә Мөхтәсимова фотосы

* «Бәхет» шигыреннән

Разил Вәлиев

БЕРЕНЧЕ КАТ КҮККӘ АШУ

Башлангыч мәктәптә без үзебезнең авылда элеккеге мәчет бинасында укыдык. Бу агач мәчет 1921 елда ук салынган булса да, бер якка да кыйшаймаган, таушалмаган, бары тик манарасы гына җил-давыл искән көннәрне, үз язмышыннан сыкранган сыман, ыңгырашып-ыңгырашып куя. Казан өчен, Татарстан, бөтен татар халкы өчен Сөембикә манарасы нинди мәгънәгә ия булса, безнең манаралы мәчет бинасы авылыбыз халкы өчен шул дәрәҗәдә кадерле, изге иде. Егерме беренче ачлык елында авылдашларыбыз аны ничек торгыза алганнардыр, бу могҗиза миңа бүгенге көнгә кадәр ачылмаган сер булып кала бирә. Ә инде аның ыспайлыгына, төзелеш мөкәммәллегенә, архитектура камиллегенә сокланмаган кеше булмагандыр. Каян килгән гап-гади авыл агайларына, мәдрәсә белемле балта осталарына андый маһирлык! Хәзер дә авыл саен мәчет салалар. Татарстанда аларның саны бер мең өч йөздән артып китте бугай инде. Әмма аларның күбесе, Аллаһ йортыннан битәр, түбәсенә манара торгызган гап-гади йорттан әллә ни аерылып тормый. Манаралары да бинасына ятышсыз, йә ул иләмсез юан һәм тәбәнәк-тупыйк була, йә завод торбасы сыман чамасыз биек һәм нәзек итеп эшләнә. Төзүчеләргә архитектураның асыл кагыйдәсе – пропорция саклый белү сәләте, гармония камиллеге җитмәү аркасында, халыктан тиенләп җыелган акчалар шундый зәвыксыз мәчетләр төзүгә сарыф ителә.

Әйткәнемчә, безнең авыл мәчете агач архитектурасының гүзәл үрнәкләреннән саналып, дәүләт тарафыннан саклана торган тарихи һәйкәлләр исемлегенә кертелгән иде.

Мәктәптә укыганда, минем иң зур хыялларымның берсе мәчет манарасының иң очына менеп, тирә-юньне күзәтү иде. Манара ике балконлы булып, өстәге балконга кадәр бормалы баскычтан менеп була. Әмма бу әле манараның өчтән ике өлеше генә, очлаеп килеп, кайчандыр түбәсенә көмеш төстәге ай кунаклаган конуссыман өлешендә баскыч-мазар юк, анда күгәрченнәр патшалык итә. Күгәрченнәргә кереп-чыгып йөрү өчен иң югарыда кеше башы сыярлык кына тәрәзә дә бар. Минем хыял ничек тә шул ай янына кадәр менеп, элеге тәрәзәдән дөньяга күз салу иде. Аның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Берчакны мин әнкәйдән: «Мәчеткә манара нигә кирәк?» – дип сораган идем. Ул миңа: «Манарага менеп мәзин азан әйтсен өченгә, улым. Аннары... манарага менгәч, бөтен авыл күренә, тавыш та ераккарак ишетелә. Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная», – дип җавап бирде. Бу сүзләр минем күңелемә гомерлеккә уелып калды. Манарага менеп элеге күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карасам, миңа күрше авыллар гына түгел, Казан һәм Мәскәү калалары, бөтен дөнья, хәтта Ходай Тәгалә үзе дә күренер сыман иде.

Дүртенчедә укыганда, барыбер мендем мин ул манара очына. Калай астындагы

черек такталарны сындыра-сындыра, кул-аякларны каната-каната булса да, иң өскә үрмәләдем. Күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карагач, әллә инде алдымда беренче мәртәбә шундый иркен манзара ачылудан, әллә инде манара чайкалудан күз алларым томаланып, башым әйләнеп китте, күңелгә шом керде. Әйтерсең Ходай Тәгалә рөхсәтсез-нисез үз биләмәләренә кергән өчен шулай акылымны томалый иде. Билгеле инде, мондый нәтиҗәләрне мин соңрак, бераз үскәчрәк ясадым, ә ул чакта кабаланакабалана манарадан төшкәнем генә истә калган.

Үзебезнең авылда – башлангыч, күрше Шәңгәлчедә – сигезьеллык, Түбән Камада урта мәктәп тәмамлаганнан соң, мин башта – Казанга, аннары Мәскәүгә укырга китеп бардым. Авылга кайткан саен, әллә каян ук иң беренче булып мине мәчет манарасы каршылый торган иде. Әмма ул елдан-ел таушалып, әкренләп бер якка янтаеп бара. Бер кайтуымда аның инде калайларын җил каерып аткан, ае да менә-менә егылып төшәм дип кыйшайган иде. Минем яңа китабым чыгып, ярыйсы гына гонорар алган чак, Казаннан реставратор егетләр алып кайтып, 1979 елның көзендә мәчет манарасын сипләргә тотындык. Ул вакытта район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән яшьлек дустым Рифкать Муллин да ярдәм кулы сузды, авылдашлар да хәлдән килгәнчә булыштылар. Шулай итеп бергәләп манараны торгызып та куйдык. Ай күтәргән көнне бөтен тирә-юнь авыллар җыелышып көч-куәт биреп торганны күрү минем өчен әйтеп бетерә алмаслык рәхәтлек иде. Дөрес, Казанга кайтуга башта ВЛКСМ өлкә комитетына, аннары партия өлкә комитетына чакырып, утлы табада кыздырдылар, идеологик яктан өлгермәгән кеше икәнлегемне, балаларны коммунистик рухта тәрбияләргә тиешле «Ялкын» журналында эшләргә әзер булмавымны искәрттеләр.

Мәчетебез никадәр матур булса да, рәхимсез еллар барыбер үзенекен итте, агач бина әкренләп тузып, берзаман ярым җимерек хәлгә килде. Аны сүтүдән башка чара калмаган иде. Әмма сүткәнче, авыл осталары, аның барлык үлчәмнәрен алып, бизәкләрен фотога төшереп, нәкъ шундый ук кыяфәттәге таш мәчет салырга вәгъдә бирделәр. Озак еллар төзелештә прораб булып эшләгән энекәшем бу эштә башлап йөрүче булды, финанс мәсьәләләре күбрәк минем өскә төште, авылыбыз эшмәкәрләре дә кулдан килгән ярдәмне күрсәтте.

Бүгенге көндә авылыбыз мәчете, элеккесеннән дә матуррак, мәһабәтрәк булып, дистәләгән чакрымнан балкып тора. Балчыклы урманын чыгуга, минем күз карашым иң беренче булып шул мәчет манарасын эзли башлый. Әгәр манара булмаса, авылымның бөтен яме китәр, хәтта авыл үзе дә бетәр, юкка чыгар кебек тоела миңа. Гомумән, мәчетсез, манарасыз мөселман авылын, татар авылын камил авылга санамыйм мин.

Шушы мәчет манарасы аша иң беренче мәртәбә дөньяның зурлыгын, матурлыгын күрүем, тәүге тапкыр хыялый күккә ашуым бүгенгедәй хәтеремдә, күз алдымда. Ул чакта мин күккә генә ашып калмадым, тәүге кат Аллаһы Тәгаләнең үзе белән очрашкандай булдым. Әле бүген дә колагымда әнкәемнең «Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная» дигән сүзләре яңгырап тора сыман.

МИНЕМ БЕРЕНЧЕ ЭШМӘКӘРЛЕГЕМ

Безнең әткәй озак еллар агроном һәм колхоз рәисе булып эшләде. «Уңыш» колхозының уңышы мул булганга, эшләре яхшы баргангадыр инде, көннәрдән бер көнне аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләделәр. Билгеле, безнең гаилә, безнең авыл өчен генә түгел, бөтен район өчен дә заманында зур вакыйга иде бу. Миңа ул чакта нибары

җиде-сигез яшь кенә булгангадыр инде, әлеге орденның кыйммәтен аңлап бетермәгәнмендер, аны октябрят, пионер значогы кебегрәк бер нәрсә дип уйладым. Әткәйнең дә күкрәгенә орден тагып, кукраеп йөргәнен хәтерләмим. Өйдә апалар, сеңелләр белән без аны уенчык итеп уйный идек. Шулай сигез бала чиратлап уйный торгач, ул каядыр юкка чыкты, күпме эзләп, әлегә кадәр таба алганыбыз юк. Документы калды калуын, шуны күрсәтеп, киләчәктә, бәлки, дубликатын алырбыз дип уйлыйм. Еллар үткән саен, әткәй-әнкәй белән бәйле һәрнәрсәнең кыйммәте арта бара икән...

Ул елларда орденга ияртеп бүләк бирү гадәте дә булган, ахрысы. Көннәрдән бер көнне безнең ишегалдында ялык-йолык килеп торган чыпчын велосипед пәйда булды. Билгеле, минем сөенечнең чиге-чамасы юк, бүген «Мерседес» бүләк итсәләр дә, ул кадәр үк шатлана алмас идем кебек. Авылыбызда моңа кадәр бер-ике генә велосипед булганга күрә, әлеге бүләкне берничек тә бәяләп бетерерлек түгел иде. Шуңа күрә минем үземә бу велосипедны орден өчен түгел, ә орденны велосипедка ияртеп биргәннәрдер кебек тоелды.

Велосипед утыргычына буй җитмәгәнгә күрә, борын каната-каната ике-өч көндә рам астыннан йөрергә өйрәндем. Җыен бәйрәме көннәрендә бөтен авылны шаккатырып авыл башындагы мәйданга велосипедта барырга иде исәп. Бәйрәм җитәргә берничә көн кала, күрше Мәликә апаларга Пермь шәһәреннән кунаклар кайтып төште. Араларында миннән ике-өч яшькә генә өлкәнрәк бер малай да бар иде. Аның белән тиз арада танышып, дуслашып та киттек. Миннән өлкәнрәк булгач, билгеле инде, аның аяклары педальгә җитә, рәхәтләнеп утыргычка утырып йөри ала. Әмма әнкәй: «Велосипедны беркемгә дә бирмә», – дип, колакка киртләп куйган иде. Әнкәй дигәннән, әткәй колхоз рәисе, коеп куйган коммунист булса да, әнкәй авылның заманында «кулак» дип аталган хәлле кешеләр нәселеннән иде. Шушы нәсел каны уйнагандырмы, белмим, кинәт кенә миндә алыш-биреш итү теләге уянгандай булды. Ә моның өчен бик кулай сәбәбе дә бар иде. Кайткан көнне үк теге малай (исемен онытканмын инде) кесәсеннән пистолетка охшатып ясалган зажигалка чыгарып күрсәтте. Пистолетын безгә төбәп «черт» итүгә, көпшәсендә ут кабынды. Велосипед шәп нәрсә булса да, мондый хикмәтне исә без – авыл малайларының моңа кадәр төшендә дә күргәне булмагандыр әле. Малай пистолетын чертләткән саен, минем күңелдә дә ут кабына, ул ялкын, көннән-көн көчәеп, бөтен тәнемә йөгерә иде. Рам астыннан йөрү шактый җайсыз булгангамы, мин инде бераз ялыктыра башлаган велосипедны әлеге пистолет-зажигалкага алыштырырга ният иттем. Ниятемне кунак малайга әйткәч, ул артык сатулашып тормады, зажигалкасын кулыма тоттырды да үзе велосипедка атланып, урам буйлап китеп барды.

Билгеле, бу «бик тә отышлы» алыш-биреш хакында мин өйдәгеләргә әйтмәдем. Велосипедны әткәй миңа бирде бит, димәк, мин аның белән теләсә нәрсә эшли алам дип уйладым. Пистолетны чертләтеп, малайларны да куркыткан булдым, чыпчыкларга да төбәп атып карадым. Шулай көне буе туйганчы уйнадым мин аның белән, кич, арып-талып, пистолетны кочаклап йокыга талдым.

Иртә таңнан торган әнкәй, минем кочактагы пистолетны күргәч, башта куркып калган. Әткәйне чакырып күрсәткәч кенә, аның чын пистолет булмаганын аңлаганнар. Билгеле инде, моның өчен миңа әткәйдән шактый ук әләкте. Зажигалканы кире биреп, велосипедны үзебезгә алып кайтырга туры килде. Шулай итеп, минем тәүге эшмәкәрлегем, алыш-бирешем уңышсыз тәмамланды. Әмма моңа һич кенә дә үкенмим, әгәр әткәй-әнкәй ул чакта мине хуплаган булса, бәлки, кемнәрдер кебек гомер буе шулай алтыга алып, бишкә сатып сәүдә кылып йөрер идем әле.

СҮЗ УҢАЕННАН

2022 елның гыйнварында Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевка 75 яшь тула. Юбилей уңаеннан Бакуның Халыкара яшь төрки телле язучылары ассоциациясе инициативасы белән Баку нәшрияты шагыйрьнең «Көзге яңгыр» дип аталган шигырьләр җыентыгын бастырды.

«Ул үзенең шигырьләрендә, тематикага бәйсез рәвештә, үз республикасын һәм үз халкын гаять бай төсмерләрдә чагылдыра. Аның иҗатының төп үзенчәлеге шунда: шагыйрьнең социаль лирикасында без мондый төр шигъриятькә хас булган пафослы өндәү-чакыруларны очратмыйбыз, өстенлек образлы, фәлсәфи һәм шигъри яктан нечкә, тирән уйлануларга бирелә», – дип яза китап турында Азәрбайҗан Фәннәр академиясе вице-президенты, Н. Гәнҗәви исемендәге Әдәбият институты директоры, академик Иса Габиббейли.

Җыентыкта шигырьләрнең азәрбайҗан теленә тәрҗемәсе аларның татарчасы белән бергә бирелгән.

КӨНДЕЗ – УКЫТЫРГА, КИЧЕН – РЕПЕТИЦИЯГӘ!

Автор:
Руфия Фазылова

Казанның Гадел Кутуй урамында үзенчәлекле уку йорты бар – Инженерлык лицее. Рәсми рәвештә бу исемдә эшли башлавына биш кенә ел әле. Заманча җиһазландырылган, зур булмаган уку йорты ул. Исеменнән үк күренгәнчә, биредә физика, химия, математика кебек фәннәргә өстенлек бирелә. Иң гаҗәбе – беренче карашка иҗаттан ерак кебек саналган уку йортында «Сәйяр» исемле Халык театры эшли. Гастрольләр белән чит илләрдә, шулай ук Россиянең иң ерак шәһәрләрендә булганнар.

Фотолар «Сәйяр» Халык театрыннан алынды.

ӘНИ ИСТӘЛЕГЕ...

Театрның режиссеры Раил Мөхетдинов белән лицейның актлар залына кердек. Биредә театр фойеларындагы кебек стенага артистларның фотосурәтләре эленгән. Режиссер һәр артист турында кыскача белешмә бирде. «Бик кызганыч, труппабызның ике артисты кисәк кенә мәрхүм булды. Бик юксынабыз үзләрен», - дип куйды.

Актлар залында репетиция бара иде, Туфан Миңнуллинның «Кырларым, тугайларым» пьесасын сәхнәләштерергә уйлаганнар. Бу юлы аеруча бер дулкынлану белән эшкә алынганнар, чөнки театрның юбилей елы – ун яшь тула! (Сәйярлеләр елга бер спектакль чыгара.)

– Репетицияләргә көн саен җыеласызмы? – дим режиссерга.

– Шулай дияргә була, бигрәк тә спектакль куяр алдыннан. Кичке тугызларга кадәр монда без.

«Сәйяр» труппасы оешуның тарихы көтелмәгән була. Бер очрашкач, мәктәп директоры Венера Хәйретдинова танышы Раил Мөхетдиновка тәкъдим итә:

– Әнием гомер буе театрга мөкиббән иде. Ана сөте белән бирелгәндер – татар театры күңелемнең иң нечкә кылларына үтеп керә. Хыялым – мәктәбебездә театр студиясе булдыру. Алынасыңмы?

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлаган, Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында эшләгән Раил Мөхетдинов озак уйлап тормый – ризалаша. Тиз арада укытучылар коллективы белән очраша. Татарча камил белгән, иҗатка тартылган ир-ат, хатын-кызларны барлый.

– Әлбәттә, сәхнәгә менү өчен татарча белү генә җитми, – ди режиссер. – Шулкадәр татарча әйбәт белүчеләр бар, ләкин Аллаһы Тәгалә тарафыннан аларга сәләт бирелмәгән. Һәр кеше дә актер була алмый, бу аңлашыла. Алай гына да түгел, алар мең кешегә берәү генә туры килә дияр идем. Артист өчен иң мөһиме – рольне, образны аңлау...

Режиссер яшерми – иҗат эше җиңел түгел, фикер каршылыклары белән дә очрашырга туры килә. Шуңа күрә труппадан киткән артистлар да булгалаган. Берәүләр бирелгән роле белән килешми, ә икенчеләре вакыт таба алмый. Соңгысы гаҗәп тә түгел – дәресләр беткәч, өйгә кайтып китәсе урынга (ә без беләбез – укытучының эше дәрес бирү белән генә тәмамланмый), сәйярлеләр кичке сигез-тугызга кадәр репетициядә була.

РОЛЬНЕҢ ЕРТЫГЫ БАРМЫ?

Алда әйтеп узган идем – Инженерлык лицееna биш кенә ел, ә мәктәп базасында эшли башлаган театрга ун ел була. Эш шунда ки, әлеге коллектив башта 178 нче мәгариф үзәгенә караган. Аннан соң инде аерым уку йорты булып бүленеп чыкканнар. Иң кызыгы – театрда уйнаучы укытучы-артистлар да бергә күчкән.

2015 елда «Сәйяр» төркеменә Халык театры исеме бирелә. Әлбәттә, моның өчен труппага үзен чын профессионал итеп күрсәтергә туры килә. Мәртәбәле комиссия труппа куйган спектакльләргә карап нәтиҗә чыгара.

– Үзешчән театр белән халык театрның аермасы шунда: беренчесендә сүзне ятлыйлар да, шуны сәхнәгә чыгып сөйлиләр, – дип аңлатты Раил Мөхетдинов. – Икенчесендә исә башта образны өйрәнәләр, аннан соң гына сүзгә күчәләр. Мисал өчен, Газинур абыебыз бар. Аның өчен иң беренче адым – героен өйрәнү. «Син миңа

бу рольне аңлат», – дип яннан китми ул. Шунсыз рольгә алынмый. Без башта һәр образга биография төзибез.

Инде артистлар белән танышабыз – берсе математика, икенчесе татар теле, өченчесе тарих, дүртенчесе физкультура укытучысы... Балаларга белем, тәрбия бирүдән тыш, аларны актерлык осталыгы, сәхнәгә булган мәхәббәт берләштерә.

– Күмәк репетициягә кадәр, башта спектакльне өлешләргә бүлеп өйрәнәбез, ягъни актлар залында бер көнне ике-өч кенә кеше була, – диде сәйярләр.

Танышуны яшь артисттан башладык – Сирин Гасыймов лицейда физкультура, ТИН дәресләрен укыта. Театр студиясенә килгән көнен ул бүгенгедәй хәтерли:

– Раил Кашифович мине мәктәп коридорында туктатты. Ул вакытта 178 нче мәгариф үзәгендә эшли идек. «Сине татарча яхшы беләсең дип әйттеләр. Спектакль кую нияте бар, теләгең юкмы?», – диде. Мин озак уйлап тормадым, ризалаштым. Әйе, татарчам яхшы, Сабада туып-үскән егет бит. Шулай итеп тиз арада Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасын сәхнәләштерә башладык.

– Әлбәттә, Сиринне башта сынап карадым, – дип сүзгә кушылды режиссер. – Мәктәп коридорында торган һәр укытучы безнең труппага эләкмәде. Сириндә актерлык осталыгы бар, бу бәхәссез.

– Аеруча яраткан ролең бармы? – дим Сирингә.

– Яратмаганы бар. Берничә ел элек Айгөл Әхмәтгалиеваның «Күз нурларым» спектаклендә юлдан язган егетне уйнадым. Әйе, бик шәп спектакль иде, халык бик яратты. Ләкин мин анда эти-әнисенә карата мәрхәмәтсез булган егетне уйнадым. Газиз кешеләренә карата ул шундый каты сүзләр әйтә... Минем өчен иң авыры бу спектакльне Сабада – эти-әнием алдында уйнау булды. Шуңа күрә дә мин аларны алдан кисәтеп куйдым: «Бу фәкать роль генә. Ә мин сезне бик хөрмәт итәм, яратам». Спектакльдән соң эти белән әнинең күзенә карарга кыенсындым, югыйсә сәхнәдәге образ икәнен генә аңлыйм... Без бит бүтәнчә тәрбияләнгән буын. Менә шулай үземне җиңәргә туры килде.

– Спектакльдән соң эти-әниең нәрсә диде соң?

– Әни эндәшмәде. Ә менә туган тиешле апабыз спектакльдән соң барлык артистларга чәчәк бүләк итте. Минем янга килеп җиткәч: «Синә бу чәчәкне бирергәме, юкмы икән?» – диде. Кыскасы, якыннарым рольне авыр кабул итте.

МАТЕМАТИК ЛИРИК БУЛАМЫ?

Театрның репертуарына күбрәк драмалар кергән. Ә менә 2019 елда Айгөл Әхмәтгалиева әсәре буенча «Син кайда?» спектаклен чыгарганнар. Бик көлкеле, кызык килеп чыккан ул. Җәй буена афиша да булган, тик пандемия сәбәпле, гастрольләр өзелгән.

Лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучы Гөлназ Гыйләҗетдинова труппа оешкан көннәрдән башлап сәйярлеләр рәтендә. Ун ел эчендә төрле рольләрне уйнаган.

– Узган ел миңа роль бирелмәде, – диде Гөлназ ханым. – Дөресен әйтим, шундый авыр булды. Хәтта яңа спектакль премьерасына да килмәдем. Ничә еллар сәхнәдә уйнаганнан соң, тамашачы ролендә калу бик читен икән, аңлатып булмый торган бер халәт бу... Быел исә сөенечем зур – төп рольләрнең берсен бирделәр. Яшермим, якыннарым минем кебек сөенми – өйгә йокларга гына кайтам бит. Аның каруы хәзер очып йөрим!

Математика укытучысы Гүзәл Чернова исә гомер буе актриса булырга хыялланган. Мәктәп сәхнәләрендә спектакльләр куеп үскән кыз ул. Тик, җырлый белмәве аркасында, театр училищесына барырга кыюлыгы җитмәгән.

– Кем уйлаган, гомер уртасына җиткәндә, чит илләргә барып спектакльләр куеп йөрермен дип, - диде Гүзәл ханым. – Чынлап хыяллансаң, тормышка аша икән ул. Сәхнәдә мин бөтенләй икенче кеше – үземә канат куйгандай хис итәм. Шуңа да беркайчан репетицияләргә баруны авырлыкка санамыйм. Өстемдә тау кадәр эш торса да, актлар залына йөгерәм...

Газинур Җиһаншинны исә труппаның иң җаваплы артисты, диделәр. Сәхнә костюмнарын да үзе сайлый. Гомумән, һәр роленә бик зур игътибар бирә, башта кат-кат өйрәнә. Математика укытучысы булгангамы, төгәллекне ярата.

– Театр икенче дөнья инде ул, – ди мөгаллим. – Сәхнәдә гадәти тормыш онытыла, син шунда яши башлыйсың. Иң кызыгы, спектакльне куйдың да оныттың түгел – ел буе шуның белән янасың. Труппадагы артистлар белән кайчан очрашсак та, пьесалар турында сөйләшәбез.

– Хатын-кыз артистлар белән сөйләшкәч, шунысы аңлашылды: хәләл җефетләре болай спектакль куеп йөрүне бик хупламый икән. Сезнең җәмәгатегез нинди мөнәсәбәттә?

– Бик хуплый. Хатыным, кызым да укытучы. Мин уйнаган спектакльләрнең берсен дә калдырмыйлар. Гомумән, без театрны бик яратабыз, гаилә белән дә йөрибез. Казанга килгәннән бирле бер генә премьераны да калдырганым юк. Студент вакытта ук Казандагы бер мәдәният үзәгендә театр студиясенә йөрдем. Шулай ук гастрольләргә дә чыга идек. Кыскасы, гомернең күп өлеше сәхнәдә узды.

ГАСТРОЛЬЛӘР...

Республика буенча гастрольләр күбрәк атна азагына туры килә. Төшкә кадәр балаларга белем биргән мөгаллимнәр кичке якта артистка әйләнә. Мәктәп автобусына төялеп, берәр районга чыгып китәләр. Татарстанның һәр районында диярлек булганнары бар, Баулы кебек ерак төбәкләр генә калган. Алга таба анда да барырга ниятлиләр. Санкт-Петербург шәһәре, Краснодар өлкәсе, Кыргызстан... Кайда гына булмаганнар!

СӘХНӘЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЬЕСАЛАР:

1. **Туфан Миңнуллин** «Ай булмаса, йолдыз бар» – 2012
2. **Узеир Гаджибеков** «Аршин мал алан» – 2013
3. **Илдар Юзеев** «Гашыйклар тавы» – 2014
4. **Илдар Юзеев** «Кыр казлары артыннан» – 2015
5. **Айгөл Әхмәтгалиева** «Күз нурларым» – 2016
6. **Данил Сабиров** «Микулай дәдәйнең бөер ташы» – 2017
7. **Исламия Мәхмүтова** «Күрәсем килгән иде» – 2018
8. **Айгөл Әхмәтгалиева** «Син кайда идең?» – 2019
9. **Кәрим Тинчурин** «Йосыф вә Зөләйха» – 2020

– Әле 2017 елда Берлинга да спектакль алып бардык, – дип шаккатырды сәйярлеләр. – Айгөл Әхмәтгалиеваның «Күз нурларым» әсәрен сәхнәләштердек. Елап, шешенеп бетеп карадылар.

Франкфурт сәхнәсендә дә спектакль шундый ук зур аншлаг белән узган. Быелга кадәр шунда яшәүче милләттәшләрдән хатлар килеп тора икән. «Сезне тагын чакырабыз, зинһар, килегез, көтәбез. Бүгенге көнгә кадәр спектакльдән алган тәэсирләр белән яшибез», – дип язалар.

– Франкфуртта татар диаспорасы бик зур, бердәм. Андагы милләттәшләрне тагын бер барып күрү хыялы бар, – ди Раил Мөхетдинов.

– Спектакльгә хәтта татарча аңламаган чын немецлар да килгән иде,– дип сүзгә кушылды Гүзәл Чернова. – Аларның кайсының хатыны, ире татар. Эчтәлеген хәләл җефетләренә немец теленә тәрҗемә итеп утырдылар. Бик көчле спектакль иде ул, аны бер илле тапкыр куйганбыздыр. Бөтен җирдә сорадылар. Галиәсгар Камал театрының кече залында да куйдык без аны.

Исламия Мәхмүтованың «Күрәсем килгән иде» спектаклен исә 2019 елда Кырымга алып барганнар. Шулай ук зур тәэсирләр белән кайтканнар.

– Симферопольгә баргач, безгә дәүләт театры бинасын бирделәр, – диде Раил Мөхетдинов. – Анда шундый күп милләттәшләребез җыелды. Иң тәэсирләндергәне – спектакль сәгать тә кырык минут барса, безне сәхнәдән сәгать тә илле минут җибәрми тордылар. Алкышлар, бергәләп фотога төшүләр, кочаклашулар...

Спектакльдән соң артистлар янына сигез дистәсен тутырган бер бабай килә. Елый-елый рәхмәт әйтә: «Сез минем балачагымны күрсәттегез»,– ди. Бактың исә, Ленинград блокадасы вакытында этиәнисен югалткан була ул. Аны бер татар гаиләсе тәрбиягә алып, аякка бастыра. Ул менә шул эти-әнисенә бик рәхмәтле була. «Балачагым күз алдымнан узды», – дип, барлык артистларны кочаклап чыга.

...Үз эшен яратып башкарган кешеләрне фанат диләр. Сәйярлеләргә карата да бу сүзне кулланырга була. Көне буе балалар укытканнан соң, кичкә кадәр репетицияләр, костюмнар сайлау. Фанат кына түгел, монда җенләнү дигән сүз урынлырак булыр, мөгаен...

Сәйярлеләргә иҗат уңышлары теләп калабыз. Егерме, утыз еллык юбилейларны да шулай каршыларга язсын. Сез – гаҗәп!

«Татар театры 90 ел элек үк дөньяга килгән. Ул – Коләхмәтов, Тукай, Әмирхан, Кудашев-Ашказарский, Кариев, Камаллар тырышлыгы, заман таләбе белән туган. Хикмәт шундадыр: безнең театр тормышның, халыкның үзәгеннән чыккан. Һәм 90 ел буена без шушы халыкчанлыкны саклап киләбез.
Әйе, «авырып» алган, тамашачы азрак йөргән чорлар да булгандыр, әмма театрыбызның кыйбласы үзгәрмәде.
Театр, драматург, тамашачы – бу иң зур өч хасият. Әлбәттә, беркайчан да, бер театр да, бер режиссер да: «Драматургия белән йөз процентка канәгать», – дия алмый. Алай булмый. Әйтик, атаклы МХАТ өчен Чеховлар, Горькийлар, Булгаковлар язганда да Станиславский белән Немирович-Данченко репертуардан канәгать булмый. Бу табигый, театр яңа үрләргә омтылмый икән, аның киләчәге юк.
Безнең үз милли үзенчәлегебез. Мәсәлән, периферияләге рус театрлары Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б. калаларда куелган спектакльләргә йөз тотсалар, безнең драматургия үзебездә туа».

Марсель Сәлимҗанов, 1996 ел.

АВЫЛЛАРЫ

ОЛЫ ЙӨРӘКЛЕ ТҮБӘН ӘЛКИ

Автор: Руфия Фазылова

Яңа ел алдыннан иң тугры укучыларыбыз янына – Әлки районына барырга булдык. Күптәнге дуслык безнең – «Татарстан» журналын биредә укыйлар, яраталар. Районның иң зур авылларыннан берсе – Түбән Әлкигә юл тоттык.

Фото: Александр Ефремов

ТҮБӘН ӘЛКИ



ХАТ ТАШУЧЫ ЮК

1920 нче елларда Түбән Әлки волость үзәге булып торган. Районга Әлки атамасы бирелүне шуңа бәйлиләр. Ә 1937 елда район үзәге Базарлы Матакка күчерелә.

Түбән Әлки җирлегенә дүрт авыл керә – Югары Әлки, Урта Әлки, Татар Суыксуы һәм Түбән Әлки. Соңгысы админстратив үзәк булып тора. Биредә 1103 кеше яши, 275 йорт бар.

Без килгәндә авыл җирлеге идарәсе бинасында ремонт бара иде. Ул чынлап та начар хәлдә. Ә менә шул ук бинада урнашкан китапханәгә узган ел косметик ремонт ясаганнар.

– Ремонтны авыл кешеләре, үзәк китапханә ярдәме белән башкарып чыктык, – диде китапханә мөдире Рамилә Гайнетдинова.

Авыл җирлеге идарәсе урнашкан бинадан кала, Түбән Әлкинең мәдәният йорты да аяныч хәлдә. Дөресен генә әйткәндә, шундый зур авылда халык өчен кирәкле урыннарның мондый хәлдә булуына бераз аптырадык та. Кечкенә авылларда да күпфункцияле заманча үзәкләр төзиләр, ә монда...

– Без дә яңа бина булыр дип көтәбез, һәрхәлдә, программага кердек инде, – диде Түбән Әлки авыл җирлеге башлыгы Фәрит Садриев.

Халык өчен мөһим социаль биналар капиталь төзекләндерүгә мохтаҗ булса да, Түбән Әлкидә бик яхшы урта мәктәп бар. 113 укучысы булган, данлыклы белем үзәге ул. Тагын сөендергәне – авылда йортлар берсеннән-берсе матур, кеше яшәми торган ташландык нигезләр юк диярлек. Дүрт кибет, яңа ФАП – кыскасы, болары күңелне җылытты.

Ремонт барган авыл җирлеге бинасына Илдус абый Мусинны чакырганнар иде. Түбән Әлкидә туып, Чаллы шәһәрендә укытучы булып эшләгән, хәзер инде туган авылында гомер итүче мөхтәрәм кеше икән.

– Түбән Әлкигә кайтканыма ун елдан артык, – диде ул. – Әнием 101 яшькә кадәр гомер кичерде. Аңа туксан тулгач, төп йортка күченеп кайткан идем. Шуннан бирле рәхәт

1

– Бездә халык ачык, гади, – диде китапханәче Рамилә Гайнетдинова.

2

– Шундый зур авылда почта таратырга кеше табып булмый, – ди җирлек башлыгы Фәрит Садриев.

яшим – умарта тотам, бакча, тавык-чебеш... Әни йөз яшенә кадәр бал кортларын карарга булышты.

– Сез үскәндә авыл зур идеме?

– Зур. Хәер, ул хәзер дә кечкенә түгел. Тик безнең чакта балалар күп иде. Мисал өчен, 1976 елны ун классны тәмамладык. Җитмеш алты укучы чыктык. Үзе бер мәктәп бит. Без үскәндә өчәр параллель сыйныф – икесе татар, берсе рус классы була иде.

– Авылда татарлар гына яшәмәдемени?

– Татарлар, тик кайбер ата-аналар, балаларын русча укытасы килеп, күрше авылга йөртә иде. Шуңа күрә 1967 елда рус сыйныфлары ачылды.

1970 нче елларда Түбән Әлкидә «Сельхозтехника» оешкан. Әлеге оешмага бөтен тирә-яктан эшкә килгәннәр. Нәтиҗәдә, аларның кайберләре авылда яшәргә төпләнеп калган. Шулай ук биредә машина-трактор, комбайннар ремонтлау паркы да эшләгән.

1990 нчы еллар башында «Сельхозтехника» җитәкчесе Мөдәррис Хәйретдинов эшчеләр өчен йортлар салдырган. Алты-җиде ел эчендә Түбән Әлкидә дүрт зур яңа урам барлыкка килгән. Бирегә күбрәк күрше авыллардан килеп урнашканнар.

– Яңа урамга килүчеләрне җирле халык ничек кабул итте? – дим.

– Бик әйбәт кабул итте, – ди китапханәче **Рамилә Гайнетдинова**. – Бездә халык ачык, гади. Өстәвенә, килүче гаиләләр ят кешеләр түгел иде – ире, яки хатыны «Сельхозтехника» хезмәткәре. Без аларны бүлмәдек, беренче көннән үк үзебезнекеләрдәй якын иттек.

Түбән Әлки авыл җирлегендә бер хәбәр әйтеп шаккатырдылар – шундый зур салада почта таратучы юк икән! Алай гына да түгел, почта җитәкчесе дә булмый торган.

– Инде почта җитәкчесенә кеше таптык. Бер хатын-кызны да почта таратырга күндердек, моңа бик сөендек, – диде җирлек башлыгы **Фәрит Садриев**. – Шундый зур авылда бу эшкә кеше табып булмый. Хәер, сәбәбен барыбыз да беләбез – хезмәт хаклары аз. Почта таратырга ике кеше кирәк, әле менә берсен генә таптык. Икенчесен эзләү белән мәшгульбез. Хәлдән килгәнчә үзебез дә ярдәм итәрбез, дип әйтеп карыйбыз, тик ризалашучы юк әлегә...

АВЫЛ ЭЧЕНДӘГЕ БИСТӘ

«Сельхозтехника» гөрләп эшләгән чорда салынган дүрт урамны да карап килергә булдык. Җирле халык аны «бистә» дип йөри. Югыйсә күрше урам гына ул. Кирпечтән салынган ике яклы йортлар икән. Дөрес, аларны хәзер матурлап тышлап та куйганнар. Капкалар да төрле итеп ясалган, төсле, бизәкле. Күңелгә хуш килгәне – урамнары киң, юллар төзек. Йортларның яше бер тирә, шуңа да монда иске, яңалары юк, бертуганнар кебек, «күлмәкләре» генә төрле.

Әлеге йортларның берсендә яшәүче **Гөлүсә Фассахова** янына кердек. Беренчедән, йортларның эчен күрәсе килде, икенчедән, хуҗабикәне бик уңган, диделәр.

– Гөбәдия, бәлешләрем пеште, әйдәгез, әйдә, – дип елмаеп каршы алды Гөлүсә апа.

Йорт тулы гөлләр, бәйләнгән урындык, карават япмалары – барысы да Гөлүсә апаның матурлык яратуы турында сөйли. Хәтта Коръән китабына да тышлык бәйләгән ул.

Хуҗабикә ире Әмир абый белән ике ул үстергән. Олы уллары хәрби юлны сайлаган – бүген гаиләсе белән Абхазиядә яшиләр. Кече уллары да башлы-күзле булган. Узган ел килен төшергәннәр.

– Гомер буе диярлек кибетче булып эшләдем, – диде Гөлүсә апа. – Хәзер инде өйдә генә, Әмир эшләп йөри әле. Мал-туар ас-

рыйбыз, кош-корт тотабыз, эш җитә, Аллаһка шөкер. Катыгын, кортын ясыйм. Менә сезгә дә әзерләп куйдым әле, авыз итәрсез.

Гөлүсә апаның кул эшләрен күреп шаккаттык. Шәл, арка җылысы, башмак, бияләйләр – әллә нинди матур үрнәкләр белән бәйләнгән.

– Болай бәйләргә кайчан өйрәндегез? – дим.

– Бәйләүне мин бала вакыттан ук яраттым. Ыргак белән бәйләүгә гел кызыга идем. Кеше күрмәгәндә чорма башына менеп, иске ыргак белән бәйли идем. Күрсәләр, җепне әрәм итәсең, дип әйтүләреннән курыктым. Зур ыргак сорау турында сүз дә юк. Шулай да әни берсендә минем бәйләүне күрде. Кызым, күзләрен арттырып барырга кирәк, дип, эш тәртибен аңлатты. Ә эти яңа ыргак ясап бирде. Шулай итеп алты-җиде яшьләремнән чынлап торып бәйли башладым. Ул чакта күбрәк оекбаш, бияләй, идәнгә җәймә бәйли идем.

Гөлүсә апа күңелендә бүген дә бер хатирә яши. Математика укытучысы дәрескә бик матур бизәкле жилет-арка җылысы киеп керә. Ул көнне кызның күзенә ак-кара күренми, игътибары фәкать теге киемдә була – бизәкләрен өйрәнә. Үзенә дә шундый матур жилет бәйләп киясе килә!

– Без җиде бала, мин бишенчесе, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – Сеңлем, кияүгә чыкмый тор, аннары безгә бәйли алмассың, диләр иде. Әти-әниләр, барлык туганнарны бияләй, оекбашлы иттем. Бармаклы бияләйләргә исемнәр яза идем. Балалар үскәндә дә калын кофталар, арка җылылары – барысын да бәйләдем. Кулга инә тотмаган көннәр сирәк булды. Хәзер дә шулай. Әле менә, Аллаһ боерса, туачак оныкчыгыма комбинезон бәйлим.

«Сельхозтехника» салган йортлар дигән идем бит. Бактың исә, мондый йортлар бирелүенә халык бик сөенгән. Суы, газы кергән, бик заманча торак саналган ул. Шунда ук мал асрар өчен сарае да булган, тугыз сутый бакча, кыскасы, тормыш алып бару өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Тора-бара халык бу йортка янкорма да салып куйган. Нәтиҗәдә, аш бүлмәсе, бәдрәф өчен яңа урын барлыкка килгән.

– Без монда 1991 елда күчендек, – дип сөйләде Гөлүсә Фассахова. – Ирем Урта Әлкинеке, без башта шунда яшәдек. Ул «Сельхозтехника»да эшләде. Туксанынчы елларда тормыш авырайды, ә биредә барысы да элеккечә калды. Бик күңелле яшәдек без, алтмышлап яңа йорт иде, йөз егерме гаилә дигән сүз бу. Барыбызның да балалар бер тирә яшьтә иде. Урам тулы бала-чага, бергә уйнадылар, мәктәпкә бардылар. Түбән Әлкине бик яраттым, эше дә булды, урта мәктәпне дә гөрләп эшләде. Безне монда алып килгән өчен язмышыма бик рәхмәтлемен.

3
Йорт тулы гөлләр, бәйләнгән урындык, карават япмалары – барысы да Гөлүсә Фассахованың матурлык яратуы турында сөйли.

4 5
Шәл, арка җылысы, башмак, бияләйләр – хуҗабикә әллә нинди матур үрнәкләр белән бәйләгән.

6
Шәйхетдиновлар авыл башында чын завод төзеп куйган! Техниканың исәбе-хисабы юк.

7
Эшмәкәр киләсе елга сөт эшкәртү цехы ачарга хыяллана.

8
– Эш төп өч юнәлешкә бүленгән, – ди Дамир Шәйхетдинов.

Гөлүсә апаның өе тулы гөл дигән идем. Җәен бакчасы да шау чәчәктә утыра икән. Аеруча яраннар ярата хуҗабикә. Ул аларның төрен, исәбен дә санамый – бик күп.

– Яраннарны бакчадан казып алам да, идән астына төшереп куям, - диде Гөлүсә апа. – Аның хәтле гөлне тәрәзә төпләренә сыйдырып бетереп булмый.

– Идән астында яраннар корымыймы? – дим.

– Юк. Дөрес, сабаклары нечкә була инде, аннары кояшка чыккач рәтләнә ул. Идән астына ике атнага бер төшеп су сибәм.

ЗАВОД ДИРЕКТОРЫ

Кем әйтмешли, авыллар буенча сәфәрләрдә йөргәндә, төрлесен күргән бар, әмма Түбән Әлкидәге кебек шәхси эшмәкәрне очраткан юк иде әле! Шәйхетдиновлар авыл башында чын завод төзеп куйган. Мондагы корылмаларны күргәч, аптырып, гаҗәпләнеп куясың. Техниканың исәбе-хисабы юк...

Завод хуҗасы – шушы авылда туып-үскән **Дамир Шәйхетдинов.** Эшмәкәр кайчандыр абыйсы Альберт белән эшли башлаган. Дөрес, алар бүген дә бергә, тик исәп-хисап счетларын аерым алып баралар.

– Балалар үсте, аларны да кул арасына кертергә кирәк, – диде Дамир Шәйхетдинов.

Бүген эшмәкәрнең кул астында йөз егермегә якын кеше эшли, шуның яртысы Түбән Әлкинеке, калганнары күрше авыллардан. Абыйсы Альбертта исә җитмешкә якын кеше хезмәт куя икән.

– Эш төп өч юнәлешкә бүленгән, – диде Дамир Шәйхетдинов. – Беренчесе – сөтне халыктан җыеп, заводка җибәрү. Икенчесе – көнбагыш мае җитештерү, өченчесе – цементтан бетон ясау.

Иң гаҗәбе – эшкуар булганына канәгать булып кына утырмый. Киләсе елга сөт эшкәртү цехы ачарга хыяллана. (Проектлар ясалган инде, бинаның бер өлеше әзер.) Шулай ук көнбагыш маен да шешәләргә тутырып кибетләргә чыгара башлаганнар. Әлегә кадәр майны күпләп сатып алучыларга тапшырганнар.

– Сөтне кечкенә машиналар белән халыктан, фермалардан җыябыз да, цехка алып кайтабыз, – диде хуҗа кеше. – Биредә сөттән кызлар анализ ала, махсус лабораториябез бар. Шунда эшләүче кызлар сөтне майлылыгы, антибиотикка һәм башка күрсәткечләре буенча тикшерәләр. Шуның нәтиҗәләре буенча, зур машиналарга төяп, сөтне төрле җирләргә озатабыз. Башкортостанга кадәр китә.

Хуҗа белән цехларны карап чыктык. Көнбагыш маен ясый торган заводта (Әйе, нәкъ шулай, фәлән миллионлык чит ил җиһазлары тора. Беренче җайланма көнбагыш орлыгын кыса, икенчесе барлыкка килгән майны судан арындыра, өченчесе чистарта...) әле дә төзелеш эшләре бара – зурайталар. Сөт це-

хында да үзгәрешләр – анализлар алу өчен якты, заманча кабинетлар. Тик игътибарны, җиһазларга караганда, мондагы чисталык җәлеп итте – тегендә дә, монда да бөтен әйбер ялт иткән. Җитәкче яшерми:

– Чисталык, һәр әйбернең урынында булуы минем өчен беренче урында. Хезмәткәрләремнән дә шуны таләп итәм, – диде.

Ә цементтан бетон ясау эше әлегә туктатылган – салкында моның белән шөгыльләнеп булмый, ягъни бу сезонлы эш.

Шәйхетдиновлар эшне 1998 елны алтыга ун метрлы гади бер гараждан башлаган. Техника ремонтлау белән шөгыльләнгәннәр. Шуннан халыктан сөт җыю эшенә алынганнар. Соңрак КАМАЗлары белән көнбагыш ташый башлыйлар. Нәкъ менә шул вакыт сыек май ясау теләге туа да...

– Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, ике ай бер шәхси оешмада эшләдем. Шунда үземә: «Тукта, Дамир, ни өчен кешегә эшләп йөрисең? Башкалар булдырганны нигә син эшли алмаска тиеш?» – дидем. Әнә шуннан авылга кайтып, абый белән үзебезгә эш башларга карар кылдык. Нәфес ашаганда уяна – төрле өлкәдә эш башлап карадык, һәм базарны дөрес тоемлаганбыз булып чыкты.

Дамир Шәйхетдиновның гаиләсе ишле – ике кыз, бер ул. Алар Казанда яши. Ә ул көн саен диярлек гаиләсе янына башкалага кайтып йөри. Иң кызыгы – абыйсы Альберт та шулай шәһәр белән авыл арасында яши икән. Туганнарның Түбән Әлкидә дә йортлары янәшә, Казанда да.

– Тора-бара авылга бөтенләй кайтырбыз дип уйлыйм, – ди эшкуар. – Алтмыш яшьтә көн саен тегендә-монда йөреп булмас. Хәер, шимбә, яллар, каникуллар – хатын, балалар да монда. Төп нигезгә йорт салдым. Аллага шөкер, әниебез исән-сау, җитмеш биш яшен тутырды. Кайчан кайтып керсәм дә, чәй кайнаган, аш пешкән, бик рәхәт.

...Менә шулай яшәп була бит, дип кайттык Түбән Әлкидән. Горурланып, алар өчен сөенеп. Ни өчен горурлыкмы? Үзебезнең егетләр бит, юктан бар иткәннәр. Сөенечме? Әлбәттә. Гади халык эшсезлектән интекми, монысы бик мөһим.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Илдус Мусин,
лаеклы ялдагы мөгаллим:

– Әлки авылына кайчан нигез салынган дигән сорауга бер генә чыганактан да төгәл җавап тапмадым. Чама белән XVII гасыр дип карарга кирәктер.

Авылның атамасы белән бәйле төрле риваятьләр бар. Шуларның берсе – бабайлар авылга Әлки (Галикәй) исемле кеше нигез салган дип сөйли иде. Без күбрәк шушы вариантка таянабыз. Әлки – борынгы һәм интернациональ исем. Мәсәлән, казахларда Әлкиев фамилиясе, Иделнең уңъяк ярында русча бозып әйтелүче Алкино шәһәрчеге бар.

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 22.10.21 — 20.03.22 кадәр үткәрелә. Гаризалар 21.01.2022 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

Ozon Wildberries

«Татарстан» журналын
сатып алыгыз



«Татарстан»лы Яңа ел белән!

«ТАТМЕДИА» АҖ. АДРЕС: 420066 КАЗАН ., ДЕКАБРИСТЛАР ур., 2. ГРН 1071690057834 РЕКЛАМА 16+